PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 ДЕКАБРЬ № 12

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

КИЛЕН – КАЙНАНА ТУФРАГЫННАН

тату яшәү сере

БАКЫЙ МӘХӘББӘТ

үз ярын кемдер таба, кемдер юк

ИЛСӨЯ БӘДРЕТДИНОВА СЫЙЛЫЙ

«серле тавык»

Гөлназ ГАТИНА:

ТАТАР КЫЗЫ БАШКАЛАРДАН АЕРЫЛЫП ТОРСЫН УЛ...



PRESSA.RU

2018





ГЫЙНВАР

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	31
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	

ФЕВРАЛЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	
2	9	16	23	
3	10	17	24	
4	11	18	25	

МАРТ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	

ИЮЛЬ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

АВГУСТ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	

СЕНТЯБРЬ

	3	10	17	24
	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30

Рәссам Рабис Сәлахов эшләре.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлназ Гатина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 1.12.2017 ел.
Заказ А-3054.
Тираж 5193.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

Илсөяр ИКСАНОВА

* * *

Яңа елның яңа язлары бар,
Ымсындыргыч җылы җәйләре бар.
Яңа елның алтын көзләре бар –
Җиргә төшәр күпме эзләре бар.

Яңа елга якты өметләр бар,
Ышанычлар, уйлар, хыяллар бар.
Күңелләрдә күпме теләкләр бар,
Яңа ел дип типкән йөрәкләр бар.

И Яңа ел!
Ишет йөрәкләрне,
Чынга ашыр гади теләкләрне, –
Илгә-көнгә иминлекләр бирче,
Бәхет елы булып балкып килче!






Фото: Ксения Богданова

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА

Бәсле теләк

Урманнарга керик бәсләр коеп,
Тормасыннар йоклагандай оеп.
«Яңа е-ел!» – дип
аваз салыр җилләр,
Һәм болытлар
йолдыз-карын сибәр...
Җем-җем итәр безнең киемнәрдә!
Тылсым көче бардыр бу көннәрдә –
Уй-хисләрнең иң сафлары калыр,
Киләчәккә безне алып барыр.
Яңа елга бары шундый теләк!
Күрәсезме, бүләкләрен төяп,
Кыш бабай да инде юлга чыкты:
Агачлардан коела ап-ак сыкы.



PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







18 ГӨЛНАЗ
Э. Закирова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8 СУКБАЙЛЫКТАН ҖИНАЯТЬКӘ... БЕР АДЫМ
М. Авзалова





22 СӨЙКЕМЛЕГӘ КҮРӘ СӨЕКЛЕ
А. Юнысова



16 ЯШЕЛ ТҮБӘЛЕ ЧИРМЕШӘН
Э. Закирова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





26 КИЛЕН – КАЙНАНА ТУФРАГЫННАН
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



30

БАКЫЙ МӘХӘББӘТ
Р. Камалетдинова

ЯШӘЕШ 



42

ӨЧ «МИНУС» ҺӘМ УТЫЗ «ПЛЮС»
Л. Гәрәева



50

МОНДЫЙ ДӨНЬЯ ДА БАР ИКӘН...
Л. Тимергалиева

ШУЛАЙ УК: 

38 СИНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР
Х. Ширмән

46 ЯЛГЫШУЛАР – УРМАН...
Г. Сафиуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



60

«СӨЕНЕЧ ХАТЛАРЫ»

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ. ИЛСӨЯР ИКСАНОВА. ЯҢА РУБРИКА.

ҮЛЕП ТЕРЕЛДЕМ. БУЛГАН ХӘЛ.

ҖАНЫМ ЖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА. ЯЗМЫШ.

ШОТЛАНДИЯ – МОГҖИЗАЛАР ТУГАН ҖИР. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



«Теле барның – иле бар. Иле барның – үзе бар», диләр. Татарлар сан буенча Россиядә дә, безнең Оренбург өлкәсендә дә руслардан соң икенче урында тора.

Милләтләр бер-берләреннән нәрсә белән аерыла соң, дигәнгә, һәркем җавап табар: тел, гореф-гадәт, йолалар, белән, дияр. Әгәр дә без хәзер телебезне югалтабыз икән, без үзебезне дә югалтачакбыз.

Тагын бер матур халык мәкале бар бит әле: «Тел дигән дәрья бар, төбендә – энҗе-мәрҗәннәр». Энҗе-мәрҗән дигәне – җырларыбыз, әкиятләребез, бәетләребез, мөнәҗәтләребез... Әгәр телне белмәсәк, бу энҗе-мәрҗәннәргә дә ия була алмыйбыз.

И татарым, борынгы халкым!
Сакла шулай үзеңне.
Сакла илең, телең, йолаң,
Сакла иминлегеңне, – дип яза Оренбургтагы «Татар йорты» милли музее җитәкчесе Гөлйөзем Гайсә кызы Улембекова.

Гөлйөзем ханым безнең авылдан – Яңа Мусаныкы. Югары белем алып, авылыбыз мәктәбендә математика укытты ул. Тормышка чыккач, ире белән Үрнәк бистәсенә урнашып, анда да балаларга белем бирүен дәвам итте.

Кешеләрне язмыш йөртә. Аларның гаиләсе дә тора-бара Оренбургта төпләнә, Гөлйөзем үзе балалар бакчасына эшкә урнашып, сабыйларга милли рухта тәрбия бирүен дәвам итә.
Шул ук вакытта Татар иҗтимагый үзәгенең дә актив әгъзасы була. 2009 елда Оренбургта «Татар йорты» музее ачылганнан бирле, мөдир вазыйфасын башкара. Андагы һәр экспонат халкыбызның шанлы тарихын, белемен, алгарышын, тормыш-көнкүрешен тәфсилләп сөйли. Барысы да җентекләп сайланган һәм киләчәк буыннарга илтеп җиткерү өчен кадерләп саклана.

Музейның ишекләре һәр килгән кунакка ачык. Табында милли ризыкларыбыз – бавырсак, чәкчәк, бәлеш булыр. Бу да үзенә күрә татар халкының бер милли йоласын күрсәтү – кунакларны кайнар чәй белән сыйламыйча чыгарып җибәрмиләр шул бездә.

Гөлйөзем ханым өлкәбездәге татарлар тормышына да битараф түгел. Бөтендөнья татар конгрессы уздырган чараларда делегат булып катнашып, тәҗрибә туплап кайта, аннары шуны Оренбург татарлары тормышына кертеп җибәрү өчен дә тырыша.

Гөлйөзем ханымның тырышлыгына сокланабыз. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын сак-лап калу өчен керткән хезмәтен югары бәялибез. Аллаһы Тәгалә аңа исәнлеген, гаилә иминлеген бирсен. Эшендә уңышлар телибез.

Рушания АБДРШИНА.
Оренбург өлкәсе, Шарлык районы, Яңа Муса авылы.

2010 елда кече энебез Рәфит әниебезне һәм аның сеңлесе Флүзә апаны зурәтиебезнең каберенә зиярәт кылырга алып барды.

Зурәтиебез – Әбрәров Кәрам Мөнир улы Башкортстанның Балтач районы Мәләгәз авылында туган булса да, мәңгелек йорты туган туфрагыннан еракта – Волгоград өлкәсендә язылган булган.

1942 елның май аенда алына ул сугышка. Зурәниебез Язилә белән аларның ике кызлары туган була. Олысы Нәкыя – 11 яшьлек, безнең әни Хәппә – 7 яшьлек, ә Флүзә апа белән әле авырлы гына булып кала зурәни. Зурәти соңгы хатында: «Кемебез туды соң?» – дип сорап яза. Ләкин җавап хаты алырга өлгерми, 1942 елның октябрендә «хәбәрсез югалды» дигән язу килә. 226 нчы укчылар дивизиясендә пулеметчы була ул. Әлегә кадәр без аның кайда җирләнгәнен белми идек. Сеңлемнең кызы Гөлназ «Хәтер китабы»ннан аның исемен таба.

Минем үземә дә студент чакта Волгоград шәһәренә өч тапкыр барырга туры килде. «Ватан-Ана» мемориалында һәлак булган меңнәрчә сугышчыларның исемнәре язылган, мин дә, зурәтиебезнең исеме юк микән, дип, һәрчак ул исемлекне укый торган идем. Ә ул Городище районы Кузьмичевский бистәсендәге туганнар каберлегенә җирләнгән булып чыкты.

Шулай итеп, әни белән апабызның теләге тормышка ашты, алар зурәтинең каберенә туган нигезенең туфрагын илтеп салдылар. «Менә, әти, сиңа кече кызыңны күрергә насыйп булмады. Мин аны сиңа 68 елдан соң күрсәтергә алып килдем. Синнән башка яшәве безгә бик авыр булды. Без сиңа лаеклы булып

үстек. Рәнҗеп калма, бәхил бул, әти», – дип, әни белән апа әтиләре белән саубуллашалар.

Безнең гаилә өчен бу вакыйга сөенечле дә, көенечле дә иде. Зурәтиебезне беркайчан күрмәсәк тә, әниебез сөйләве буенча, ул безнең йөрәктә зур урын алып тора. «Хәбәрсез югалды» дигән язу килсә дә, зурәни аны гомере буена көткән. Исән булса, иренең каберенә ул да барган булыр иде. Әниебезнең 75 яшьлек юбилеена зур бүләк булды бу.

Сугыш беткәнгә ничә ел үтсә дә, туганнарын эзләүчеләр әле дә бар. Көннәрдән бер көнне минем үземә дә бер хат килеп төште. Хат авторы – Башкортстанның Чишмә районы Тәпәреш авылыннан Вәлетдинов Шәрифулла мине язмаларым аша эзләп тапкан икән. Сирәк кенә аларны Башкортстанда чыгучы матбугатка җибәргәли идем шул. Уфада басылган «Истәлек китабы»нда аның абыйсы Вәлинең 1943 елның 13 августында Смоленск өлкәсе Ярцево районында һәлак булганлыгы турында язылган. Шәрифулла абый миннән шул урын турында сорашкан.

Икенче көнне үк хәрби комиссариатка шалтыратып, аның Петрово авылындагы туганнар каберлегендә җирләнгәнен ачыкладым. Петрово авылы бездән 35 чакрым ераклыкта гына. Улым белән туганнар каберлеген эзләп киттек. «Әни, син ул кешеләрне беләсеңме?» – ди улым. «Аларны белү кирәкми, изге эшне чит кеше өчен эшләргә кирәк», – дим.

Кабер бик матур тау башында урнашкан. 9 Майда һәм Смоленск өлкәсен фашист илбасарларыннан азат иткән 25 сентябрьдә монда авыл кешеләре, мәктәп укучылары чәчәкләр сала, сугышчыларны искә ала икән. Туганы җирләнгән урынның бүген дә кадерләп тотылуын белү Шәрифулла абый өчен дә бер куанычтыр.

21 яшьлек Вәли абзый яшәү ямен дә, сөю-сөелү тәмен дә тоярга өлгермичә, безнең бүген тыныч яшәвебезне кайгыртып, ерак җирләрдә башын салган. Без аның каберенә туганнары исеменнән чәчәкләр салдык. Шәрифулла абзый үзе килеп күргәнче, туганының каберен фотога төшереп җибәрдем.

Бер атнадан Шәрифулла абый үзе шалтыратты. Бик дулкынланган: «Син безнең якын кешебез хәзер», – дип, кунакка чакырды.

Илебездә сугыш кагылмаган бер генә гаилә дә юктыр. Әтием ягыннан бабам да Смоленск өчен барган сугышларда каты яраланып, госпитальдә яткан. Иремнең дәү әнисе өч баласы белән Германиягә куылган, дүрт ел әсирлектә булган, аның башыннан ниләр генә кичмәгән... Америка солдатлары азат иткәннән соң, туган якларына кайтсалар да, торырга урыннары юк, бөтен Смоленск өлкәсе кырылып, яндырылып, җир белән тигезләнгән булган. Ялан кырда мич торбалары гына утырып калган. Алар, солдатлар казыган окоплардан землянкалар ясап, шунда яшәгәннәр.

Кызганыч, сугыш ветераннары елдан-ел кими бара. Күпме истәлекле вакыйгалар алар белән мәңгелеккә китә.

Зәйтүнә РУЛЕВА.
Смоленск өлкәсе,
Капыревщина бистәсе.

Мин татарча бик әйбәт белмим. Туган телне газета-журналлар, китаплар укып кына өйрәндем.

Республикада барган вакыйгалар безгә – чит өлкәләрдә яшәүче татарларга да тынгылык бирми. Аллаһы Тәгалә сезгә акыл, зиһен, тәпле фикер бирсен инде берүк.

Кайсыдыр предметны мәҗбүри укыганнан, балаларга нииндидер зыян килә дигән сүз белән мин, гомумән, килешмим. Балаларга бүтән чит телләрне: француз, инглиз, алман телләрен укытабыз бит әле, файдадан тыш, моның бер генә зыяны да тигәне юк. Тормыш бит ул: бер кирәк булмаса, бер кирәк булуы бар. Европа телләрен өйрәнеп, рәхәтләнеп, Европа илләренә чыгып булса, татар телен белгән кеше көнчыгыш илләрендә югалып калмаячак. Шулай булгач, татар теле дәресләре дә атнага ким дигәндә ике-өч дәрес керергә тиеш дип саныйм. Татар мәктәпләре болай да бик аз калып бара. Россиянең башка төбәкләрендә юк та юк инде алар. Булганнары да ябылып бетү чигендә. Кайвакыт уйлап та куям, нигә әби-бабайлар, әти-әниләр безгә татар телен өйрәтүнең мөһимлеген аңламадылар икән? Без дә хәзер татар телендә чыккан яңа әдәби әсәрләрне укып, рухи ләззәт алыр идек, татарча газета-журналлар белән танышып барыр идек. Татар әти-әниләре! Безнең балабызга татар теле кирәкмәс дип уйлап, ялгыша күрмәгез. Олыгайган саен, кеше үз тамырларына тартыла, үз телендә сөйләшәсе, җырлар җырлыйсы, оныкларына да үз телендә әкиятләр сөйлисе килә башлый икән. Ә моның өчен кечкенәдән үк телеңне өйрәнергә кирәк.

Без инде, туган телебез дә күтәрелеп килә, буыннар арасындагы бәйләнеш ялгана, дип куанган идек. Тулы ике буынның ана телен белми үсүен бер үттек бит инде, башка мондый хәлләр кабатланмасын дип телик.

Яза китсәң, бу тормышта гаделсезлекләр бик күп инде. Әйтик, хатын-кыз бала таба да, бер-ике елдан эшкә чыга. Чыкмас иде, тормыш итәргә акча кирәк. Бәяләр нинди бит хәзер! Эшкә чыгам дисәң дә, беркем дә синең balaңны бакчага алырга атлыгып тормый. Алсалар да, анда аралашу рус телендә бара, бала рус мохитенә иялэшә, рус телен туган теле кебек кабул итә башлый. Шуңа да балам русча начар белер, уку йортларында укый алмас дип борчылмагыз.

Татар халкы гаять түзем, сабыр халык. Әби-бабайлар да Аллаһыдан безгә бик зур сабырлыклар сораганнар, шуңа тормышыбыз шундыйдыр инде безнең.

Фәүзия апагыз.
Кемерово шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

СУКБАЙЛЫКТАН ҖИНАЯТЬКӘ... БЕР АДЫМ





Мәдинә
АВЗАЛОВА

ӘТИ-ӘНИДӘН ЯКЛАУ ТАПМАГАН, ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫ, НАЗ ТОЙМАГАН БАЛА УРАМГА ИЯЛӘШӘ. ТӘРТИПСЕЗ «УЕННАР» БЕЛӘН МАВЫГА БАШЛАГАН БАЛАЛАРГА ЯРДӘМГӘ ҖӘМӘГАТЬ ТӘРБИЯЧЕЛӘРЕ КИЛӘ.

Иң яхшы җәмәгать тәрбиячесен билгеләү өчен үткәрелгән бу бәйгенең башы гасырларга барып тоташуын күз алдына китерүе дә кыен. Бер караганда, монда гаҗәпләнерлек нәрсә юк та үзе. Бала мәнфәгатен, аның законлы хокукларын яклау – ул гомер-гомергә иң җете, иң актуаль проблемаларның берсе. Борын-борын заманнардан ук шулай килгән инде ул. Тарихка күз төшереп алсак та, әле патша заманнарында – 1910 елларда ук сукбайлыкта йөрүче 2,5 миллион бала исәпләнгән. Октябрь революциясеннән соң гына караучысыз калган балаларга карата мөнәсәбәт уңай якка үзгәрә башлаган.

Республиканың балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе секретаре Илсөяр Хәләлетдин кызы Гарифуллинаның: «Бу комиссиянең оешуына тиздән 100 ел була», – дип, безне искәртүе тикмәгә түгел. Гаилә, бала тәрбияләү проблемаларының дәүләт күләмендәге җитдидән-җитди эш булуына моннан бер гасыр элек үк төшенгәннәр. В. И. Ленин 1918 елның 14 гыйнварында Халык Комиссарлары Советының «Балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе турында»гы Декретына кул куя. Шул вакытларда башлана да инде закон бозучы яшүсмерләргә каршы көрәш дип әйтимме, тәрбиямме... Сукбайлыктан җинаятькә бер адым булуын аңлау булган. Бүген Татарстанда әлеге комиссияләрнең эшен көйләү өчен 2011 елның 20 маенда кабул ителгән закон да, 2008 елның 15 декабреннән гамәлгә кергән җәмәгать тәрбиячеләре турындагы закон да әйбәт кенә эшләп килә.

Әни сүзе кермәсә

Аларны ничек кенә атама – тәрбиячеләр дипме, остазлармы, мәгънәсе-бурычлары бер: тайгак юлга кереп киткән яшүсмерне бәладән йолып алу, яшүсмерне кылганына җавап бирә алырдай итеп үстерергә булышу. Бу авыр эшкә йөрәк кушуы буенча алынган кешеләр арасында – хәрбиләр, полиция хезмәткәрләре, педагоглар, профсоюз лидерлары... «Тормышта үз эшеңне тап, яхшыдан-яхшы булырга тырыш!» Яшүсмер күңеленә ачкыч табуда аларның һәркайсы шушы шигарьне куллана.



Алмаз БОРҺАНОВ, Арча һәм Әтнә районнары хәрби комиссары: «...АРМИЯГӘ ТЕЛӘП БАРАЛАР»

– Мин үзем балалар яратам. Үземнекеләрне генә түгел, чит балаларны да шулай яратам. Буш вакытымны аларга багышларга тырышам. Җәмәгать тәрбиячесе булып эшли башлавыма сигез ел тулды. Беркем дә ирексезләмәде, үзем теләп, яратып алындым. Һәм яратып эшлим дә.

Шәкертем урамда исерек хәлендә тоткарлана. Аны районның балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе исәпкә куйды да миңа беркетте. Бу – 6 март көне иде. Шул көннән, шул сәгатьтән бу яшүсмер өчен, аның үз-үзен тотышы, тәртибе өчен мин җавап бирергә тиеш булдым. Әйе, бу бик җаваплы бурыч. Дөресен әйткәндә, кайчак үз балаңны да карап җиткереп булмый. Ә биредә... Чит гаиләдә тәрбияләнүче баланы гел игътибар үзегендә тоту четерекле, бик четерекле эш. Ләкин минем инде аңа кадәр дә берничә егетне тәртипкә «утыртып», армия сафларына озатканым булды. Беренче генә күрүем түгел, дип әйтсәм килә. Эшемне аның гаиләсе белән танышудан башладым. Бик ошаттым аларны. Хезмәт сөючән, дус гаилә. Тик менә малай гына, начар төркемгә эләгеп, ялгышып куйган. Мин моны шундук аңладым. Бала тәрбияләүдә әти-әнинең урыны турында әйтеп тә тормыйм. Аны һәркем белә, тик кайберсе шуны үтәми генә. Нәтиҗәдә, зур бәла-казалар килеп чыга, баланың киләчәге сикәлтәле, шикле сукмакка каерыла. Шундый гыйбрәтле хәлләр күпме әнә...

Без аның белән эшне наркологка барудан башладык. Икәүләшеп утырып, спиртлы эчемлекләрнең, тыелган башка әйберләрнең сәламәтлеккә зарары турында бик үтемле лекция тыңладык. Бер генә мәртәбә түгел, берничә мәртәбә. Аннары... мәчеткә бардык, хәзрәт белән очраштык. Шәкертемнең мәчет ишеген беренче тапкыр ачып керүенә шигем юк. Хәзрәт белән саубуллашып чыгып киткәндә, аның йөзе җитди, ә күзләрендә яшь иде. Күргәч, үзем дә әллә нишләп киттем.

Минем уемча, ир-егетнең һәркайсы спорт белән шөгыльләнергә тиеш. Ильмирга да шул турыда әйттем. Ул, теләп, фикеремә кушылды. Без аның белән спорт клубына бардык. Ул безнең комиссариат каршында гына. Егеткә аерым бер тренер билгеләделәр. Күнегүләргә теләп йөрде. Ә физик чыныгулар аңа бик тә ярап куйды. Тиздән аны армиягә алдылар. Ул Хәрби Көчләрнең элитасы дип аталган десантчылар гаскәрләрендә хезмәт итте. Часть командиры биргән характеристикадан күренгәнчә, егетебез Ватан алдындагы бурычын намус белән үтәде.

Әле хәрби хезмәткә алынганчы ук егетне исәптән төшерделәр. Тәртипле булганы, үзен бары яхшы яктан күрсәткәне өчен... Ул көнне мин егетнең өенә бардым. Әнисе өстәл әзерләгән, бу вакыйга чын бәйрәмгә әйләнде. Хәзер егетебез контракт буенча хәрби хезмәткә алынырга җыена. Гомумән, минем шәкертләремнең барысы да спорт белән мавыга. Ярты ел дигәндә, комиссиянең кара исемлегеннән төшерелә. Аларның барысы да армиягә теләп барды һәм аннан үрнәк солдат булып кайтты. Бусы – минем өчен аеруча мөһим.



Дания ГАЛИМУЛЛИНА, агросәнәгать комплексының Саба районы профсоюз оешмасы рәисе: «ҮСЕНДЕРЕП ТОРГАНДА...»

– Бүгенге болгавыр заманда газиз кешеләре тарафыннан яклау тапмаган сабыйлар саны арта бара. Гаиләсендә тәрбия күрмәгән бала, әлбәттә инде, өйдән чыгып китү ягын карый, урамга ияләшә, һәм аның шунда адашып калуы да ихтимал. Киләчәк буынның тормышы караңгы булмасын өчен, без дә үзебездән булдыра алганча ярдәм кулы сузарга тиеш. Агымдагы елның апрель аенда, җәмәгать тәрбиячесе буларак, миңа 7 нче сыйныфта укучы баланы билгеләделәр. Малай аз сүзле, аралашырга яратмый. Кыскасы, үз эченә бикләнгән. Эшне иң элек аның гаиләсе, укудагы уңышлары белән танышудан башладым.

Районның балигъ булмаганнарның эше һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе әгъзасы буларак, гаиләдә тәртип юклыктан җәфа күргән аянычлы язмышлы балалар белән миңа моңарчы да очрашырга туры килгәләде. Уңышсыз гаиләләрнең һәркайсының язмышы бертөрле була ул: йә аның әти-әнисе эчкече, йә гел эш белән мәшгуль әнинең тәрбиягә вакыты калмый. Мин бу малайның өендә, мәктәбендә булам. Әнисе, укытучылары белән сөйләшәм. Малай башта яхшы билгеләргә укый, спорт белән шөгыльләнә. Спорт белән мавыгып китүе, атналар буена ярышларга йөреп, дәрес калдыруы, бермәл аның укуына тискәре йогынты ясый башлый. Әлбәттә, гаиләдә контроль булса, ул спортны да ташламас, укуын да түбән

Фото: Рамил Якупов

PRESSA.RU

тәгәрәтмәс иде. Малайга терәк булырга әти юк, ә әнисенең, әйткәнемчә, вакыты юк. Әтисен бер тапкыр да күрмәгән малайны урам тарта. Ул, үзеннән өлкәнрәк малайларга ияреп, тәмәке тартырга, урлашырга өйрәнә. Шул сәбәпле, учетка куела.

Без шәкертем белән телефоннан да сөйләшеп торабыз, кафе, китапханә, музейда да очрашабыз. Мин – аның сердәше, киңәшчесе. Ул ачылып сөйли, бернәрсәне дә яшерми. Ә бу бик мөһим. Ул үзе дә бик сәләтле егет. Оста хоккейчы, картинг белән дә мавыга. Үсендереп, уңышларына ихластан сөенеп торучылар булганда, аның киләчәге дә якты.



Чулпан КОРБАНОВА,
Әтнә районы Яңа Шашы мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, инглиз һәм татар теле фәннәре укытучысы:
«ҺӘР АДЫМЫН КҮЗӘТӘМ»

– Җәмәгать тәрбиячесе булып эшли башлавыма әле ике ел чамасы гына. Ләкин нәтиҗә ясар өчен аның шунысы да бик җитә: әйтик, бала тәртип бозып, комиссиягә исәпкә алынган икән, димәк, ул вакытын кая куярга белми. Аны кызыксындырырга, эш белән мавыктырырга кирәк. Укучымның һәр адымын күзәтеп торырга тырышам. Мәктәптә, район күләмендә үткәрелә торган бер генә чара да аннан башка узмый. Ул бик иҗади малай. Самолетлар белән кызыксына, шигырьләр һәм әкиятләр яза. Спорт белән шөгыльләнә, экологик акцияләрдә катнаша. «Зур тәнәфес», «Оста куллар» түгәрәгенә, спектакльләргә йөри. Бер сүз белән әйткәндә, баланың урамда кагылып-сугылып йөрергә вакыты юк. Ул үзе дә хәзер шулай ди. Тормышта үз урыныңны табуга таба тәүге адымнар әнә шулай башлана.



Елена ГАЛКИНА,
Питрәч районы Кощак мәктәбенең педагог-оештыручысы:
«НАЧАРЛЫККА ВАКЫТЫ КАЛМЫЙ»

– Яратып, теләп эшләгәндә генә уңышка ирешергә була. Мин моны үземнән чыгып әйтәм. Баланы һәрчак яктыга омтылган чәчәк үсентесенә охшатам. Су сипмәсәң, кадерләп карап тормасаң, ул да бик тиз шиңә. Бала да шулай: Аңа да гел игътибар, ярату, җылы сүз кирәк. Ул гел мактауга мохтаҗ. Сабыегызга мактау сүзләрен кызганмагыз. Әтиәниләргә гел бер сүзне кабатлыйм: «Балагызны кечкенә генә уңышы өчен дә зурлап мактагыз. Алар бәхетле булачак», – дим.

Шәкертем агачтан әйберләр ясарга ярата. Мин дә андый эшләргә мөкиббән. Буш вакытларында без аның белән агач уеп рәсем төшерү өчен такталар ясыйбыз. Ул тик тормаска тиеш, бары шул чагында гына аның начар эшләргә вакыты калмаячак. Өч ел эшләү дәверендә азга гына да дөрес юлдан баруыма икеләнмәдем. Әнә ул хәзер әйбәт укый, әйбәт билгеләр ала башлады. Мин хәзер аның күзләрендә кызыксыну, елмаю күрәм. Аның нәни йөрәге минем белән серләшергә ачык. Ә бит кайчандыр ул җиде биктә иде. Инде күңеленә һичничек тә үтеп керә алмам дип уйлаган идем.

Америка шагыйре Дуглас Мэллокның: «Киң юл була алмасаң, тар сукмак бул. Кояш була алмасаң, күктәге йолдыз бул. Үз эшеңне тап һәм иң әйбәте булырга тырыш!» дигән сүзләре тәрбиягә авырдан бирелүче балалар белән эшләгән безнең кебек кешеләргә кагыла.



Миләүшә ХӘНӘФИЕВА,
Теләче районы балигъ булмаган балалар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе җаваплы секретаре:
«ЯҢА ДӨНЬЯ АЧАМ»

– Җәмәгать тәрбиячесе булу – ул ышанып тапшырылган балаларның тормышы белән яшәү, алар белән бер сулышта булу, аларны сиздермичә генә үз эченә суыра барган караңгылыктан тартып чыгару, бөреләнә башлаган җаннарында яңа дөнья ачу, иртәгәсен бүгенгегә караганда яхшырак булу теләгән ояту. Үзем моны шулай аңлыйм. Шәкертемә 11 яшь. Беренче мәртәбә мин аны комиссия утырышында күргән идем. Шундый кызыксынучан, тиктормас малай. Бөтен нәрсәгә ышанып карый. Шуның белән үзенә каратты да ул мине. Балачакта мин үзем дә бик актив идем. Шушы малай сыман бер урында гына утыру зур сынау иде. Спортчы дусларыма карап, буш вакытымны мин дә шуңа багышладым. Ә менә бу баланың андый дусты юк икән. Ул, әнә, кирәкмәс, начар төркемгә эләгеп, ярамаган эш эшләп ташлаган. Хәзер эше – комиссиядә.

Бала белән мөнәсәбәтләрне бик тиз җайладык. Ул мине шундук якын итте. Атна-ун көн эчендә аның гаиләсе, ул укыган мәктәптәге укытучылар, аны дәвалаучы табиб белән сөйләшеп чыктым. Аннан соң малай һәм аның әнисе белән эшләүгә психологлар, белгечләр алынды. Без аның белән төрле патриотик чараларга йөрдек, ул көннән-көн үзенә бер яңалык ача барды. Үзен чиксез бәхетле сизде. Күрәсең, балага аралашу җитмәгән. Аның үз-үзен тотышында да зур һәм уңай үзгәрешләр сизелә. Ул кул эшләре белән дә шөгыльләнә. Талантын ачу һәм үстерү юнәлешендә эшләребез дәвам итә. Бары да әйбәт булыр дип уйлыйм.

Хокукларын саклыйлар

Җәмәгать тәрбиячеләре институты безнең өчен яңалык түгел. Бигрәк тә Татарстан өчен. Әле 1967 елда оешып, ә 1990 нчы елларда юкка чыгып торган әлеге системаның кирәклеген тормыш үзе күрсәтте. Илдә сукбайлар, караучысыз калган балалар, авыр хәлдәге гаиләләр саны арта башлагач, аны торгызу мәсьәләсе янә көн үзегенә килеп басты. Бүген җәмәгать тәрбиячеләренең бурычы тәрбиягә авырдан бирелүче балаларны җинаять юлына тайпылудан саклап калу, аларны илгә лаеклы гражданнар итеп үстеререргә булышу гына түгел, ә бәлки, яшүсмерләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклау да. Чөнки баласына тиешле тәрбия бирә алмаган ата-ана бу мәсьәләдә дә дәүләт тарафыннан ярдәмгә, терәк-таянычка мохтаҗ.

Татарстанда Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачинаның әйтүенә караганда, республикада 2009 елдан яңа сулыш алып, уңышлы эшләп киткән җәмәгать тәрбиячеләре институты, бүген упкыннан бер адымда торган яшүсмерләргә вакытында ярдәм кулы сузу, аларны дөрес юнәлешкә кертеп җибәрү өчен армый-талмый эшли. Ә бит алар бу эшне төп вазыйфаларыннан, төп эшләреннән тыш башкара. Аларның һәркайсының үз гаиләсе, үз балалары. Хәрби комиссар Алмаз Борһанов әйтмешли, чит балага да үзеңнеке итеп карасаң гына, куйган бурычыңны башкаларга үрнәк будырдай итеп башкарып чыга аласың.

– Бүген республикада 3 меңнән артык җәмәгать тәрбиячесе бар, – ди республиканың балигъ булмаган балалар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе җаваплы секретаре Илсөяр Гарифуллина. – Шуларның һичьюгы 500 е күңел биреп эшләсә дә, күпме ярдәм, күпме файда бит!

Сүз дә юк, урыннардагы балигъ булмаган балалар комиссияләре дә, җәмәгать тәрбиячеләре дә куркыныч төркемнәргә кушылырга торган үсмерләрне кулларыннан җитәкләп, яктылыкка, кайнап торган тормышка алып чыгучылар, түбәнгә тәгәрәүдән чак кына тотып калучылар алар. Бүген без республикада яшүсмерләр арасында җинаятьчелек кимү ягына бара, дип сөйлибез икән, бу уңай үзгәрешләрдә аларның да әйтеп бетергесез зур өлеше бар. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, быелның ун аенда яшүсмерләр арасында 736 җинаять эше теркәлгән. Ә былтырның шушы чорында аның саны 982 гә җиткән булган. Малайлар урлыйлар, талыйлар, наркотиклар белән тотылалар. Шунысы бераз юата: саннар кимү ягына бара. Җәмәгать тәрбиячеләренең ни дәрәҗәдә игелекле, җәмгыять, гаилә өчен кирәкле эш алып баруларын әлеге саннардан чыгып та күзалларга була. Нидерланд дәүләтендәге шикелле, балигъ булмавына да карамастан, баланы төрмәгә яшереп кенә проблема хәл ителми. Ата-ана сүзе кермәгән тыңлаусыз балаларны әнә шулай, бергәләшеп, бөтен җәмәгатьчелекне аякка бастырып тәрбиялибез. Һәм ул әнә яхшы гына нәтиҗәләр бирә.

2017: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!

Без килгәндә, Ләйсән чит ил магистрларына инглиз телендә дәрес бирә иде. Аннан соң беренче курс студентларына икътисад әлифләрен өйрәтәчәк. Көн дәвамында тагын берничә проект эшенә өлгерәсе бар... Ә гыйнварда Швейцариянең Давос шәһәрендә Бөтендөнья икътисадый форумында Россияне тәкъдим итәчәк. 29 яшендә ул инде КФУ доценты, икътисад фәннәре кандидаты, шейпер... һәм кояш кебек елмаюы белән әсир итә торган чибәр яшь ханым!

Ләйсән, шейперлар кемнәр алар?

– Шейперлар – 20-30 яшьлек кешеләр, алар социаль эшчәнлек алып бара, ягъни бу дөньяны яхшыртабыз, дип яшиләр. Глобаль шейперлар җәмгыяте Бөтендөнья икътисадый форум башлангычы белән барлыкка килә. Бүген дөньяда җиде меңләп шейпер, 450 җәмгыять бар. Казанда исә без 20 ләп кеше, һәркайсыбызның эшчәнлек өлкәсе төрле.

Давоста Бөтендөнья икътисадый форумында катнашу сезнең өчен чираттагы уңышмы, хыялмы?

– Дөресен әйткәндә, мин бу турыда хыялланырга да курка идем. Икътисад һәм социаль проблемалар белән шөгыльләнә торган кешеләр өчен Давос – хыялдагы йолдыз ул, һәм бу табигый. Мин анда гариза бирдем дә оныттым, бу турыда, ирем Альберт һәм шейперлардан кала, беркем дә белмәде. Гомумән, Давоска баруым – могҗиза. Ә анда бөтен дөньядан елына 50 генә шейпер чакырыла. Казан җәмгыятеннән мин – дүртенче кеше. Миңа кадәр безнең җәмгыятьнең оештыручысы Дилбәр Садыйкова, Тимур Сөләйманов, Антон Грачев барганнар иде. Хәзер әзерлекләр бара, көн саен хәбәрләшеп торабыз.

Сез хәзерге заманда уңышка ирешкән хатын-кызның – чын үрнәге. Уңыш сере нидә?

– Эшеңне яратырга кирәк. Эшеңне яратсаң, өйгә елмаеп кайтып керәсең. Бу кәеф өйдәгеләргә дә күчә. Өйдә рәхәт булса, эш тә җайлы бара. Бүгенге көндә үз эшеңне, үзеңә туры килә торган шөгылеңне табу җиңел түгел, чөнки хәзер мөмкинлекләр күп. Моның өчен вакытны кулдан ычкындырмаска, әгәр сайлаган юлыңны дөрес түгел, дип табасың икән, үзгәрешләрдән курыкмаска кирәк.

Без булдырабыз!

Ләйсән Арсентьева: «Дөньяны яхшыртабыз дип эшлибез!»

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU




РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

БӨГЕЛМӘ КЕЛӘЙМӘСЕ



БЕЗ ЗАВОДТА БУЛГАН КӨННЕ АЛАРГА ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕНЕҢ СЫЙФАТ ӨЧЕН ПРЕМИЯЛӘР БИРҮ СОВЕТЫННАН КҮҢЕЛЛЕ ХӘБӘР КИЛДЕ: БӘЙГЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА 2017 ЕЛНЫҢ ЛАУРЕАТЫ БУЛГАННАР!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА





Ринат ГАРИЕВ, үсеш буенча директор урынбасары:

– Гүзәл – ышанычлы, булдыклы хезмәткәрләребезнең берсе ул. Аның алдына ниндидер бурыч куям икән, үти алмас дип шикләнмим дә. Яныңа һичшиксез әзер нәтиҗә белән килә. Узган ел аның катнашы белән Татарстанның сыйфат буенча премиясенә лаек булдык. Күп нәрсә турында сөйли бу... Гүзәлнең иңендә без чыгарган продукциянең сертификациясе белән бәйле авыр эш ята. Бик зур җаваплылык бу! Продукциябез иң куркыныч объектларда кулланыла. Әйтик, нефть эшкәртү заводларында. Җиһазны ничек куллануны тасвирлаганда, бер ялгыш хәрәкәт кенә өстәлсә дә, аның нәтиҗәсе ничек булачагын күз алдына китерү дә куркыныч. Монда хәтта өтер дә зур роль уйный. Үзебездә эшләнгән теләсә кайсы җиһазның сыйфаты өчен башыбыз белән җавап бирәбез. Сертификация органнарына әзерләнүче документлар бу җиһазның ГОСТның барлык таләпләренә туры килүен тулысынча гарантияләргә тиеш.





Фото: Ксения Богданова

– Соңгы вакыттагы иң авыр, иң катлаулы заказ? Беләсезме, моңарчы тотынып карамаган теләсә кайсы эш авыр тоела бит ул. Тәвәккәлләп башлау читен... Җәй көне «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексы үзендә реконструкция үткәргән дә, торбаүткәргечләрнең бер өлеше яраксызга чыккан. Ә безнең 3 метрдан зуррак диаметрлы мондый торба эшләгәнебез юк иде әле. Быел август аенда булды бу хәл. Бөтен бүлек җитәкчеләре барыбыз бергә бер өстәл янына киңәшкә – «акыл штурмы»на җыелдык. Кичке сәгать унга кадәр утырдык. Иртән инде «Татнефть» ГАҖнең генераль директоры Наил Мәгановка документлар китте. Булдырабыз дигән нәтиҗәгә килдек.

Узган ел Бөгелмә механика заводы инженеры, стандартлаштыру һәм сертификация бюросы җитәкчесе Гүзәл МОЗАФФАРОВА «Татарстан Республикасының иң яхшы стандартлаштыручысы» исеменә лаек булды. Без аның эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Эш бүлмәсе дип... Китапханә дисәк, дөресрәк булмасмы икән аны? Тик китаплар урынына киштәләргә... ГОСТ документлары салынган папкалар тезелгән. «Бигрәк күңелсез икән эше», – дип уйлап куйдыгызмы? Белмим, белмим... Үзе эшли торган заводның – иң шәп завод, эшенең иң кызыклы эш, хезмәттәшләренең иң яхшы эшчеләр икәненә Гүзәл әңгәмәнең иң беренче минутыннан ук безне ышандырды инде.

Бүген алар кырык төргә якын продукция эшләп чыгаралар.

Алтмыш еллык тарихы булган Бөгелмә механика заводы нефть һәм газ чыгару, аны эшкәртү, нефть химиясе һәм энергетика сәнәгате өчен җиһазлар әзерләү буенча бүген илдә иң алдынгы предприятиеләрдән. Россиядәге мондый заводларны санар өчен

PRESSA.RU

бер кул бармаклары да җитә. 1954 елда нигез салына аңа. Шактый кыска вакыт арасында завод сафка баса һәм 1956 елда инде илгә ул чакта нефть сәнәгате предприятиеләре өчен бик тә кирәк булган аппаратуралар эшләп чыгара башлый. 1962 елда БМЗ үз продукциясен беренче тапкыр чит илгә – Болгариягә озата. Ә 1966 елда ул инде ундүрт чит ил белән хезмәттәшлек итә. «Бөгелмәдә эшләнде» дигән марка сугылган җиһазлар туксанынчы еллар башында да Куба, Болгария, Югославия, Вьетнам һәм Кытайга китә әле.

«Бөгелмәдә эшләнгән» дигән келәймә сыйфат сүзен алыштыра ала.

Алты дистә ел эчендә завод төрле чорлар кичерә. Иң авыры әнә шул туксанынчы елларга – илдә үзгәрешләр, реформалар дулкыны кузгалган вакытка туры килә. Әмма базар шартларында да завод аягында нык басып кала, яңача яшәргә өйрәнә. Моңа «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте составына керүләре дә зур этәргеч була. – Завод капкасын бер ачып кергән кеше моннан инде кире китми, – ди Гүзәл. – БМЗда эшләү – дәрәҗә, горурлык! Директорыбыз Швецов Михаил Викторович кешеләрнең фикерләвен үзгәртүгә иреште. Бер көндә генә булмады бу, әлбәттә... Бездә һәркем «бу үзем өчен кирәк» дип тырыша. Элек рационализаторлык тәкъдимнәре белән чыгучылар күпкә аз иде. Ә хәзер ява гына! Бу җәһәттән «Татнефть»тә беренчелекне бүтәннәргә бирмибез. Директорның үзенең дә берничә патенты бар...

Узган ел завод VI «Менеджментның эффектив системалары: сыйфат, инновацияләр, тотрыклы үсеш» Халыкара фәнни-практик форумда производствога сакчыл караш бәйгесендә икенче урынны алган. Чыгымнарны киметү, табышны арттыру (хезмәт хаклары буенча завод Бөгелмә шәһәрендә алдынгы урында тора), сакчыл караш бик кирәк. Завод мәйданының төрле почмакларына урнашкан цехларны бер түбә астына җыю (директорыбызның идеясе!), транспорт чыгымнарын гына да күпмегә киметкән әнә. Элек елга бер привод эшләгәннәр, ә хәзер ай саен 30-40 ны ясыйлар. Монысы да – хезмәтне сакчыл, дөрес оештыруның бер нәтиҗәсе. Әмма иң беренче таләп – сыйфат аларда.

– Безнең ялгышырга хакыбыз юк! – ди Гүзәл. – Заказчының ышанычын аклау – йөз аклыгы ул. Сертификатларны әзерләү элек тә җиңел түгел иде, Россия Таможня союзына кергәч, тагын да катлауланды. Гомумән, без бу өлкәдәге һәр яңалыктан хәбәрдар булырга тиеш. ГОСТның кайбер документларын бер айда гамәлдән чыгарып, икенче айда кире кайтарган очраклары да бар.

Сызымнар Гүзәлләр кулына – стандартлаштыру һәм сертификация бюросына килеп җиткәнче, беләсезме, ничә кат тикшерелә? Аны группа җитәкчесе карый, өлкән ябыштыручы, өлкән технолог, үзәк лаборатория җитәкчесе, өлкән конструктор... Берсеннән-берсе тәҗрибәле белгечләр! Шуннан соң гына яңа аппаратның сызымнары производствога тапшырыла: һәр цех үзе нәрсә эшләргә тиешлеген ачыклый. (Һәр заказ бирүченең үз таләбе: аппаратның материалы, үлчәме үзгәрсә, барысы да өр-яңадан башлана.) Кечкенә баланы җитәкләп йөрткән кебек, аппаратны башыннан ахырына кадәр озата баручы, һәр адымын күз уңында тотучы техник контроль бүлеге бар әле тагын. «Алар эшнең бөтен нечкәлекләрен белә. Барыбыздан да яхшырак!» – ди әңгәмәдәшем. Әйе, кая ул монда ялгышу! Һәркем үзенә йөкләнгән вазыйфаны «иң яхшы» билгесенә башкарганга күрә, завод бербөтен булып эшли дә.

Бөгелмә механика заводы Татарстанда ASME стандарты буенча эшләүче бердәнбер предприятие.

Әлеге сертификатны алар 2011 елда алганнар – барлык продукцияләре дә хәзер «U» келәймәсе белән чыга. (Сүз уңаеннан. Безнең заводта сыйфатка куелган таләпләрне ASME стандартларына туры китерүне директорның беренче урынбасары өлкән инженер, техник фәннәр кандидаты Шамил Талыпов башлап йөрде һәм гамәлгә кертте.) Бу аларга продукцияне ASME стандартын техник норма дип санаган барлык илләрдә дә сатарга, моңарчы чит илдән кайтарткан җиһазларны үзләрендә җитештерергә мөмкинлек бирә. Шул ук «ТАНЕКО» өчен, мәсәлән, бөтен җиһаз БМЗда эшләнә хәзер – үзкыйммәте, әлбәттә, каяндыр кайтартканнан арзангарак төшә.

– Чишеп булмаслык кебек тоелган мәсьәләләр куелганны яратам, – ди Гүзәл. – Күз курка, кул эшли. Күп сыйдырышлы сыем әзерләргә дигән заказ булгач, башта аптырап калган идек менә. Артык зур, ясап булмый, дип, күпләр баш тарткан. Мөмкинлекләребезне барладык. Әзерли алабыз дип таптык. Һәм әзерләдек тә!



ҖӘМГЫЯТЬ



Мәскәүдә «Мәскәү–Татарстан» күпере» дип исемләнгән Яшьләр форумы узды. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Форумга Мәскәүдә югары белем алучы Татарстан студентлары һәм аспирантлары килде. Уңышларга ирешкән билгеле шәхесләр арасында Марат Хөснуллин, Николай Никифоров, Альбина Шаһиморатова, Ренат Акчурин, Бари Алибасов, Алсу бар иде. Татар телен укыту процессын җәлеп итәрлек итеп оештыру юнәлешендә кызыклы фикерләр яңгырады.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Лондонда III Россия–Британия бизнес-форумының пленар утырышында катнашты. Анда Россия һәм Бөекбритания арасында ИТ-технология, нефть һәм газ химиясе, медицина, туризм өлкәләрендә хезмәттәшлек турында сөйләштеләр.

WorldSkills Russia чемпионатының Татарстандагы төбәк этабы илдә колачы ягыннан иң зурысы булды. «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатта 814 конкурсант һәм 764 эксперт, «Ворлдскиллс Юниор» стандартлары буенча 131 конкурсант, 73 эксперт катнашты.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте офисында традицион «Язылу бүләк ит» хәйрия акциясенә старт бирелде. «ТАТМЕДИА» генераль директоры Андрей Кузьмин матбугатка беренче булып язылды. Теләге булган һәр кеше Яңа елга кадәр республика басмаларын җәмәгать яки хәйрия оешмасына, аерым бер пенсионерга, гаиләләргә яздырып бүләк итә ала.

МӘДӘНИЯТ

Казан шәһәренең мәгариф идарәсе, ел саен югары сыйныф укучылары арасында «Татар кызы» һәм «Татар егете» бәйгесен оештырып, туган телебезне камил белгән, мәдәниятебезне, сәнгатебезне, тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне тирәнтен өйрәнгән яшьләрне барлый. Быел бу бәйгедә Мәскәү районыннан КФУ каршындагы Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе укучысы Рамил Баһавиев, Авиатөзелеш районыннан 14 нче мәктәп укучысы Лиана Зәйнуллина җиңү яулады.



Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры Чабаксарда узган «Әкияти палитра» төбәкара милли яшьләр һәм яшь тамашачылар театрлары фестивалендә катнашты. Туфан Миңнуллинның «Әйт әле, күбәләк» дигән мистериясенең композиторы Эльмира Галимова «Иң яхшы музыкаль бизәлеш» номинациясендә лауреат исемен алды.

«Татар моңы-2017» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсы гала-концерт белән тәгәлләнде. Җиңүчеләр билгеле булды. Катнашучылар, финал җыры буларак, «Туган тел»не башкарды.

МӘГАРИФ

«Татарча диктант» акциясендә 4000 кеше катнашты. Арада рус һәм башка милләт кешеләре дә бар иде. «Сөембикә» журналистлары да бу чарадан читтә калмады. Узган ел диктант язарга 1000 кеше килгән иде. Шулай ук Россиянең 20 регионы һәм дөньяның 10 иле татарча диктант язды. Бу акциянең максаты – татар әдәби телен популярлаштыру, гыйлемлелекне арттыру. Диктант язу ике мәйданда – «Штаб» креатив индустрияләр резиденциясендә һәм КФУның Лев Толстой исемендәге Филология институтында оештырылды. Диктантны язучы Аяз Гыйләҗев әсәре буенча яздылар. Текстны шагыйрә Йолдыз Миңнуллина укыды.

Балтачта Укытучыга һәйкәл куелды. Аның идея авторы – якташлары Азат Зыятдинов иде: укытучы ул теләгән образда ачылды. Һәйкәл кара такта янында бер кулына – күрсәткеч таяк, икенче кулына китап тотып торган хатын-кыз укытучыны гәүдәләндерә. Аның яныннан һәр укытучы: «Бу бит миңа да куелган һәйкәл», – дип сөенеп, горурланып үтәр ди район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре.

КОТЛЫЙБЫЗ

Биюче Айсылу Мирхафизхан Мәскәүдә узган II Бөтенроссия балет артистлары һәм хореографлары конкурсында I премияне алды. Лауреатка конкурсның Алтын медален һәм Моисеев исемендәге халык биюләре ансамбленең махсус призын тапшырдылар.



СПОРТ

Канада һәм АКШ татарлары Монреальдә дусларча хоккей матчы уздырды. Ул спорт-мәдәни чара буларак оештырылды. Байрак чыгару, гимн җырлау кебек рәсми өлешләрдән тыш, җыр-биюләр дә булды анда. Уенчыларга һәм җанатарларга Татарстан әләме гәүдәләндерелгән тасмалар таратылды.

PRESSA.RU













Фото: Ксения Богданова

ЯШЕЛ ТҮБӘЛЕ ЧИРМЕШӘН



Эльмира ЗАКИРОВА

МӨШБИКӘ, ГАЛИЯ, РӘМЗИЯ, МАРИНА, МЕНУИ, ГӨЛШАТ, ГӨЛНАЗ...ҺӘРКАЙСЫ БЕР ЯКТЫ ОБРАЗ, ӘДӘБИ ӘСӘР ГЕРОЕ БУЛЫРЛЫК МАТУР КЕШЕЛӘР.

Алар барысы да – Чирмешән кызлары. Районның холкын, җанын, яшәешен ачарга, аңларга алар булышты, язмамны алар күңеле аша үткәрдем дисәм дә, ялгыш булмас.

Чирмешән... Миңа ул һаман бик еректадыр сыман. Моннан шактый еллар элек «кукурузник»та очкан бар иде дип искә төшерәм. Бәркәтә, Иске Кади, Урманасты Үтәмеш, Кара Чишмә, Кызыл Чишмәләр анда... Авыл атамалары үзләре үк сөйләп тора: таулы, урманлы, болынлы, чишмәле яклар. Габдрахман Утыз Имәни, нәсел шәҗәрәсе Лашманга барып тоташкан Гаяз Исхакыйлар... Әхсән Фәтхетдинов, Канәфи Нәфыйков кебек рәссамнар, җырчы Искәндәр Биктаһиров, театр артисты Наил Шәйхетдинов, «Саз» ансамбле белән күңелләргә кереп калган Рәфкать Гомәров, «Манзара» аша таныш Илдар Кыямовлар туып-үскән Чирмешән төбәге ул...

Менә тагын юлыбыз төште шул якларга. Чистай, Яңа Чишмәләрне үтүгә, Чирмешән җирләре башлана. Як-якта – көнбагыш басулары. Көз алдына китерү кыен түгел: кайткан-киткәнне җәйләрен сары кояш

булып озатып каладыр алар. Ә без менә Чирмешәннәрнең матур эшләре, булган кешеләре белән танышырга дип килдек. Кая гына барсаң да, Европа шәһәрләрендә иң элек кызыл чирәп түбәле йортлар күзгә ташлана. Ә менә Чирмешәндә – яшел түбәләр икән. Сыек яшел, саргылт-яшел, зәңгәрсу-яшел... Чирмешән кирмәне биеклегеннән караганда, тау астыннан шул яшел түбәләр, беләсезме, ничек ямьле күренә? Кышын да яшел болын кебек! Айлы мәчет манарасы (районда 22 мәчет бар!), талларга ышыкланып, авылны урталай бүлеп агучы Чирмешән елгасы ул манзараны тагын да бизи кебек. Югарыдан гаҗәеп күренеш ачыла. Мату-уур!

Чирмешән районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рәмзия Шакир кызы Долгополова безне ымсындырып, китапханә, Боз сарае, «Ислам» атналыгы, сквер, дип, тагын Әгъләмовлар, Мөшбикә исемнәрен кабатлап, Әмир, Кармышларны телгә алып, әллә ниләр күрсәтергә, әллә кайларга алып барырга, әллә кемнәр белән таныштырырга ашыга. Чып-чын экскурсовод! Без инде аның, мишәрчәләп, «барма келим», «сүләшәбез», «ызба», «әзи» дип сөйләшүләрен дә, якын итеп «иркәм» дип дәшүләрен дә аңлый башладык, «ч» авазын каты итеп чыкылдатып әйтүләренә дә колак ияләште.

Юл башыбыз затлы китап сараеннан – китапханәдән башланды. Чирмешән җирлекара үзәк китапханәсендә ял көннәрендә дә гөрләп эшләп яталар. Рузилә Минхәерова кебек җитәкче булганда соң! Бу якларның үз язучысы, Чирмешәндә яшәп иҗат итүче бухгалтер Галия Сафиуллина белән шунда таныштык. Китаплары кулдан-кулга йөри. Җырлары 200 дән дә артып китә. Айдар Галимов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Айгөл Бариева, Фирдүс Тямаевлар җырлый аларны! Менә әйт син авылда яшәп яталар дип...

Чирмешәндә парклар, скверлар күп. Менә бу заманча бина – караучысыз калган өлкәннәрнеке. Тәрәзәләре – агач-чәчәкләр утыртылган, эскәмияләр куелган, шар кебек түгәрәк фонарьлар тезелеп киткән скверга карый. Җәен сары тузганаклар күзне иркәли, ди, монда. «Скверның исеме юк әле», – ди хуҗабикә ролендәге Рәмзия. Адашы, «Сөембикә» журналы Рәмзиясе сүз уңаеннан гына: «Тузганак» булсын! Көндез – чәчәкләрдән, кич фонарь яктысыннан кояш яктысы, җылылык бөркелер», – дип әйтеп куя. Менә, исемен дә таптык!..

Боз сараенда «Ислам» атналыгы уңаеннан хоккей турниры бара иде. Районның имам-мөхтәсибе Минсәгыйрь хәзрәт Миншин мөселман яшьләре арасында узган төрле спорт чаралары – мини-футбол, гер күтәрү, волейбол ярышлары турында сөйли. «Мөшбикә» исеменә узган әлеге республика турнирында исә 8 команда катнашкан. Сургутта яшәүче бертуган Фазыйл һәм Миндар Әгъләмовлар, әниләре Мөшбикә истәлегенә әнә шундый ярыш оештырып, барлык чыгымнарны үзләре күтәргән икән. Чирмешәндә калкып килүче «Мөшбикә» мәчетен дә алар төзетә, ди. Менә шундый булган егетләре дә бар икән әле Чирмешәннең. Бер якта ветераннар йортлары тезелеп кала, көрәнсу йортлар – ятим балалар өчен салынган, яшел түбәлеләре – ипотека буенча төзелгәннәре. Алда – ялан кыр, болыннар. Арырак инде – Самара җирләре...

Рәмзиянең Яшьләр үзәген дә, балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбен дә, ипи пешерү цехын да күрсәтәсе килә. Ни уйлаганыбызны сизгәндәй: «Һәр районда бар инде алар, дисездер. Юк, безнеке башкачарак!» – ди ул үҗәтләнеп.

Яшьләр үзәге... беркемнекенә охшамаган проект буенча салынган шул. Район хакимияте башлыгы Фердинат Дәүләтшин үзе тәкъдим иткән диләр. Барысы да заманча, креатив. Спорт мәктәбендә дә шул ук күренеш. ГТО нормаларын тапшыру буенча республикакүләм ярышлар биредә узсын да! Директор Марина Овчинниковага ияреп, көрәш залына да керәбез, рингны да карыйбыз. Спорт мәктәбенә килеп керүгә үк китап киштәсе каршы ала. Китап алмашып уку модада икән бит аларда. Гюго, Марк Твен, Паустовский әсәрләрен китереп куйганнар әнә. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Тукай шигырьләре... Ә тәрәзә төбендә кып-кызыл булып янып, декабрист гөлләре шау чәчәктә утыра. Өйдәгечә җылы, рәхәт, уңайлы.

Районда дус-тату яшәүче татар, рус, чуаш, мордвалар турында, күр, ничек мавыгып сөйли Рәмзия. Кызыклы гаилә белән таныштырам әле сезне, дип, икмәк пешерүче шәхси эшмәкәрләр янына алып кереп китте. Ишекне ачуга ук кайнар күмәч исе борынны кытыклады. Сөрмә күзләре түгелергә торган чибәр ханым – әрмән хатыны Менуи Гаспарян каршы алды безне. Кай арада гына әрмәннәрнең милли ризыгын мичтән чыгарганнардыр: кап-кайнар гаталарны табынга куя.

Чирмешән яшьләре самбо, җәядән ату белән мавыга һәм... китап укырга ярата.

«Мине төп Чирмешәннеке дисәң дә була инде хәзер, – дип елмайды ул. – 1981 елдан бирле монда без. Ирем Усо Мхитарян белән ике бала үстердек. Үзем татарча аңлыйм, сөйләшә дә алыр идем, ләкин күп кеше алдында югалып калырмын да кайбер сүзләрне дөрес әйтмәм төсле. Ә менә улыбыз Тигран да, кызыбыз Роза да татарчаны су кебек эчә! Татарстанда яшәп, ничек инде шунда яшәүчеләр телен белмисең, ди! Яшәгән җиреңә, аның халкына рәхмәтле була белергә кирәк. Ә телне белү – халыкка ихтирам күрсәтү билгесе. Оныкларыбыз да татарча сөйләшәчәк әле!»

Мондагы халыкны, аның телен, гореф-гадәтләрен яратуын әнә шулай аңлатты ул. Балалары әрмәнчә дә, русча да, инглизчә дә сөйләшә икән. Тигран хәзер юрист, тәрҗемәче. Розалары Казан федераль университетында – дизайн факультетында укый икән.

...Әмир авылы китапханәсендә безне ягымлы Гөлшат каршы алды.

PRESSA.RU

«Әмин абый белән Рәшидә апа көтә-көтә көтек булды инде, кытыр җәймәләр дә күптән җәелде», – дип яратып кына шелтәләп, безне ашыктыра башлады. Кемнәр көтә, нинди кытыр җәймә – һичнәрсә аңламыйм. «Әгъләмовларга барабыз, Мөшбикә апаның олы улы Әмин абыйларга», – дип ачыклык кертте Гөлшат. Ул үзе дә Әгъләмовлар династиясенең бер сөйкемле сөяге икән.

...«Сания, Әмин, Галия, Мәдинә, Асия, Фазыйл, Миндар...» – дип саный-саный, Әмин абый үзләренең нәселе белән таныштыра. Әгъзәм абый белән Мөшбикә апаның балалары тәүфыйклы булып, кешеләргә ярдәм итеп, бәләкәйдән эшләп үскәннәр. Барысы да. Тормышлары шома гына бармаган, кыенлыкларын да күргәннәр. Әмин абый сөйләгәннәр, гыйбрәтле тормыш фәлсәфәсе, үзенә күрә яшәү кагыйдәсе булып, күңелгә уелып бара.

Әгъләмовларның игелекле эшләрен санап бетермәле түгел...

«Теләсә кем бизнесмен була алмый. Рәссам, артист кебек үк, аның өчен дә талант кирәк. Фазыйл белән Миндарда безнең Бәркәтә Нурислам бабай геннары. Ул шундыйга сәләтле булган. Заманына күрә бай кеше булган ул».

«Акчаны җый-җый да өеп куймы?! Нигә кирәк ул! Хәлеңнән килгәнчә мохтаҗларга ярдәм ит!»

«Тормыштан канәгать булыр өчен тәүфыйк кирәк. Тәүфыйгың булмаса, бәхетең дә булмый».

...Әмирдән Кармышка юл тоттык. Кармышны хәзер күпләр Гөлназ авылы дип йөртә. Замана кызы. Яшь, чибәр, талантлы, зирәк... «Татар кызы» дигән тирән, зур, мәртәбәле исемгә лаек икәнен халыкара дәрәҗәдә күрсәтә алган Гөлназ Гатина ул. Кайсы йолдыз асларында туган да, кайсы чишмәләрдән су алып эчкән икән Гөлназыбыз? Кем ул? Нинди рәк бу Чирмешән кызы? Монысы инде – үзе бер тарих, үзе бер хикәя...



ГӨЛНАЗ

Без бит авыл кызлары!

Кармышта да шул ук яшел түбәләр, мәчет, бакчалар. Урамнар артында яшел болын. Гөлназлар өен әллә каян танып алдык: яшел капка төбендә... «Татар кызы-2017» дип язылган «Лада Гранта» автомобиле! Беләбез инде: Уфада бүләк иттеләр!.. Без килешкә, Гөлназ үзе дә кайткан Казаннан. Алъяпкычлар бәйләп, апалы-сеңелле токмач кисәләр. Лилиясен күр: апам, апам дип кенә тора! Сагынган! Әниләре Гөлия ханым да яулыгын бәйләгән, алъяпкычын япкан: кай арада бәлешен салган да, кай арада коймагын өлгерткән...

...Абау! Әкият өедер бу! Җәннәт бишеге! Таудагы нарат урманы ишегалларына ук терәлеп тора. «Өйне кайда салырга белгән Гатиннар», – дибез.

– Юк шул, – дип көлә әти кеше. – 3 гектар җиргә үзебез утырттык ул наратларны. Кызларыбыз белән бергәләп! Шәрә тау битләре генә иде бит каршыда... Әле тагын утыртачакбыз.

Менә ничек икән! Районның финанс-бюджет палатасы рәисе Шәүкәт Фатыйх улы Гатин – тәвәккәл, нинди генә эшкә тотынса да, беркемнекенә охшамаганча эшләп куя, дигәннәр иде аны.



Уфаларга баруларым...

...Ул көнне бөтен Чирмешән, юк ла, бөтен Казан, яраткан университеты, алай гынамы – бөтен Татарстан «Гөлназ» исемен йөз, мең кат кабатлагандыр. Җиңгәнче дә, җиңгәч тә... Уфада узган «Татар кызы-2017» Халыкара гүзәллек конкурсында Россиянең иң матур татар кызы булып танылды бит ул! Көндәшләре дә бик лаек иде югыйсә. Репетицияләр вакытында: «Без, без, без идек, без унике кыз идек», – дип, уйнап-көлеп, үзләрен төрле яктан күрсәтә алган, сәхнәдә төрле образларга кереп, халкыбызның асыл сыйфатларын ача алган Алсу, Регина, Әлфия, Динара, Диана, Адэль, Розалия, Назлыгөлләр... Мәскәү, Петербург, Чиләбе, Әстерхан, Екатеринбург, Уфа, Ижау, Симферополь, Ульяновск, Оренбург, Актүбә (Казакъстан) кызлары арасыннан Гөлназны ничек сайлап ала белгәннәр? Үзе менә искә төшереп карый да... Ниләр кичерде соң ул? Нәрсәсе белән таләпчән жюрины эретә алды? Ничек тамашачы күңеленә хуш килде? Бөтен җаны белән сәхнәдән елмаеп чыгыш ясаган, белеме, таланты, уңганлыгы белән таң калдырган горур һәм тыйнак, гади һәм ихлас, чая һәм тапкыр бу кызны күрмәү, аңа сокланмау мөмкин түгел иде.

«Әтинең уйлау сәләте таң калдыра. Бөтенләй башкача фикер йөртә ул. Әле дә истә: ярыша-ярыша математикадан мәсьәлә чишәбез. Әти гел көтелмәгән юллар белән, берниндИ формуласыз-нисез чишә, җавап та дөрес чыга! Аның белән шахмат уйнау рәхәт. Төгәл фәннәргә тартылу әтидән күчкән...» – Гөлназ шулай ди.

«Әдәбиятка, иҗатка, җыр-моңга мәхәббәтне әни тәрбияләде. Шигъриятне дә әни яраттырды. Әни ягы – җырчылар, гармунчылар ягы. Үзе, абыйлары, әтисе, бабасы – бар да уйный. Бабасы Зөфәр тирәюньдә бер атаклы гармунчы булган. Безнең авылның бер кешесе әйтә икән, әгәр Зөфәр кебек уйный белсәм, шундук сыерымны сатып гармун алыр идем, дип... Безнең әни бик сабыр, тыйнак, гадел. Шуңа укучылары да ярата. Мәктәптә химия һәм сәнгать фәннәре укыта ул...» – монысы әнисе турында. «Гөлия ханым зирәк, зыялы, тәртип ярата, аз сөйләп, күп эшли», – дип, Гөлназ сүзләрен тагын дәвам итәсе килә.

...Өйгә терәлеп торган наратлыкны карарга дип чыгып китеп, Сөлчә елгасын да, Ерак Кизләү чишмәсен дә, Ташказанын да күреп кайттык. Иксез-чиксез болыннар, тау сыртлары, моннан Европа–Кытай юлы узачак икән... Кайда да киңлек, иркенлек. Гөлназның «мин авылга береккән» дигән сүзләре аңлашыла... «Без балаларыбызны күбрәк хезмәт белән тәрбияләдек. Аларның җайләре гел эш белән үтә иде. Сыерын да савалар, умарталарны да карашалар... Малайлар эше дип тормыйлар: җирен дә казыйлар, печәнен дә чабалар, көтүгә дә чыгалар», – ди әтиләре горурланып. Менә кайдан килә икән ул тырышлык, үҗәтлек, максатчанлык! Менә кайдан башлана икән зур җиңүләр, уңыш юлы!

Уфада узган «Татар кызы-2017» Халыкара конкурсы мизгелләре күз алдыннан йөгереп уза...

Тамашачы каршында гына түгел, милләтең, халкың алдында да зур имтихан бу!

Фирүзә төсендәге күлмәге, күр, ничек килешә үзенә! Ул толымнары тагын! Алкалары!.. «Язмышыма хуҗа булып / Кайтчы, зинһар, Сөембикә!» Монысы – җыры. Ул бит – Сөембикә ханбикә бүген! Хәер, бәйгедә катнашучы кызларның һәркайсы кабатланмас образда аныя. Режиссер Гүзәл Акбердина аларны Мөхлисә Бубый, Заһидә Тинчурина, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Сара Садыйкова, Мәгубә Сыртланова, Бэлла Әхмәдуллина, Мәрьям Солтанова, Фәридә Кудашева, Чулпан Хаматова, Альбина Шаһиморатовалар итеп күрде. Җырчы Гөлназның Фәридә Кудашева буласы килгән иде бик тә. Режиссерга яхшырак күренәдер – «Сиңа Сөембикәне бирәбез!» – диде. Гөлназ бөтен җаны-тәне белән тәвәккәл Сөембикә образына кереп чумды. Аның турында никадәр мәгълүматлар алды, күпме китап укыды, риваятьләр өйрәнде! Сөембикәнең сабырлыгы, милләтенә, диненә тугрылыгы, каһарманлыгы, фаҗигасе таң калдырды Гөлназны! Менә хәзер шул образны сәхнәдә ачарга кирәк!

Мәктәп елларында Нәүрүз бәйрәмендә Нәүрүзбикә булган, «Созвездие-Йолдызлык», «Сөембикә варислары», «Дулкыннар», «Ягымлы яз» бәйгеләрендә чарланган, «Сәләт» мәктәбе аша узган, физика, химия, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда катнашкан һәм җиңгән (татар әдәбияты буенча өч ел рәттән – районда, ике тапкыр республика күләмендә беренче урынны яулаган кыз бит ул!), мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, КФУның Идарә, икътисад

PRESSA.RU



Яраткан җырчысы, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Айдар Галимов «Татар кызы-2017» дип Гөлназның исемен яңгырата. «Милли шура» рәисе Васил Шәйхразыев машина ачкычын тапшыра.

һәм финанслар институтына укырга кергән Кармыш кызы сынатамы соң! Студентларның «Яз гүзәле» фестивалендә «вице-яз гүзәле» булды әнә. «Татар кызы» бәйгесенең Татарстан буенча йомгаклау турында җиңеп чыккач, «Казансылу» исемен куштылар үзенә.

«Матурлык ул – күңел байлыгы».

Дулкынландыргыч мизгелләр... Златоуст осталары ясаган таҗны Гөлназга кидерәләр. Алкышлар, чәчәкләр, елмаюлар... «Гөл-наз! Гөл-наз!» дип бөтен зал гүли... Тамашачылар арасында җан атып утырган әтисе дә дулкынланган, сеңлесе Лилия исә сөенечтән бөтенләй елап ук җибәрде...

Бәхет шушыдыр ул!..

...Сәхнәдән буй җитмәс югарылыкта күренгән Гөлназ, өйләрендә балалыгы да чыгып бетмәгән гап-гади кызга әйләнеп, яныбызда бөтерелә. Шаян. Йомры-йомры сүзләр чыга үзеннән. Кармышка кайткач, мишәрчәгә күчкәнемне сизми дә калам, ди дә, «Чәчәкле чәйнектән чәй эчәбез дип сүләшәләр бездә», – дип көлдерә, «ч»лары чыңлап-чыкылдап тора мәгәр.

Озак сөйләшәбез. Бәхет, киләчәк, хыял, матурлык турында да... Китаплар, җырлар, иҗат хакында да... Уй-хыяллары белән ул тагын да тулырак, тирәнрәк ачыла бара...

«Мондый конкурсларда катнашу өчен үз халкыңны, милләтеңне, телеңне, гореф-гадәтләреңне яратырга һәм шуны башкаларга да күрсәтә белергә кирәк».

«Күңелдә һаман аңлатып та, язып та бетерә алмаслык хисләр! Бәхет шушыдыр инде ул! «Татар кызы» дигән горур исемне йөртә алу бәхете!»

«Замана кызы – акыллы, түзем, хуҗалыкчыл, әдәпле, ягымлы булырга тиеш».

Машина йөртү таныклыгым бар. Уфадан машина белән кайтып төшкәч, авылдашлар и сөенде инде!»

«Бабам халык әкиятләре сөйли иде. Әбием исә авылыбызның «аяклы энциклопедиясе». Аның ярдәмендә җиде буын бабаларыбызны табып, нәсел шәҗәрәбезне ясадык. Нәселебез тарихы бик бай. Советлар Союзы Герое Бари Габдрахмановның тамырлары безнең гаиләгә барып тоташа».

«Әти белән әни динебезгә, телебезгә, халкыбызга тугрылыклы итеп үстерде. Камиллеккә омтылырга, сабыр булырга, үзеңне башкалардан өстен куймаска өйрәттеләр».

«Уфада Чиләбе кызы Розалина Туктарова белән бер бүлмәдә яшәдем. Татарча сөйләшүемә соклана, кызыга иде. Чит өлкәләрдә татарча сөйләшергә тилмерүчеләр бар икән бит! Нигә әле аларга ярдәм итмәскә? Шул ук «Сәләт»не оештырырга була. Ләкин бу проектка алыныр өчен вакыт кирәк. Акча мәсьәләсенә дә килеп төртеләсең. Оештырып җибәрү өчен команда булу да шарт. Берүзең генә беркайчан да бернәрсә дә эшләп булмый».

«Ялтада «Сөембикә варислары» фестивалендә Салих Сәйдәшевнең «Җәй айлары»н җырладым».

«Еллар узгач, монда килгән һәркем турында ишетерсез, белерсез әле», – дигән иде Гөлзадә апа Сафиуллина. Ничек алдан күрә белгән ул! «Сөембикә варислары»нда катнашкан Гөлназ Асаева, Илүсә Хуҗина, Марат Фәйрушин, Айгөл Хәйри, Гөлназ Исмәгыйлева, Артем Пискунов, Резеда Сәлахովалар турында бөтен кеше белә хәзер!»

Туфан белән Җәлилне, Гаяз Исхакый, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен кайта-кайта укыйм. Буш вакытларымда бәйләргә, чигәргә яратам».

«Гадел Кутуйның «Сагыну» нәсерен сәхнәдән укыганда күз алдымда гел туган авылым, аның чишмәләре булды. Минем дә сагыну иде ул».

«Халкым өчен янып яшәвемне күрсәтәсем килә».

«Җырлый торган кызларны туплап, институтта «Мизгел» ансамбле оештырдым».

«Ә чәчләремне гап-гади шампуньнар белән юам. Бәлки, Кармыш сулары шулай үстергәндер... Әниемнең дә, сеңлемнең дә чәчләре озын».

«Хисләрем, күңелгә генә сыялмыйча, шигырь булып, кәгазьгә төшә...

Ялгыз урамнардан атлап барам, / Күңелемдә гармун тавышы. / Ерак гасырлардан уелып калган / Милли, сихри моңнар агышы...

Йә, ничек?..»

...Афәрин, Гөлназ! Ошый! Матур! Без юл буе синең җырларны, синең тавышны тыңлап кайтабыз. Репертурны да сайлый белгәнсең инде! «Җәйнең матур аяз таңнарында», «Илкәем», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Иделләре-күлләре», «Туган җирем», «Тибрәнә җыр күңелдә», «Әйләнеп авылга кайт әле»... Гөлназ җырлары авыл, табигать, туган җир сәламе булып, Казангача озата кайта безне...

ӘНИГӘ ӘЙТӘ КҮРМӘГЕЗ!



Кызганыч, бүген инде әни безнең арабызда юк. Ул көн әле җитмәс кебек тоелса да... китте ул. Әмма безгә үзенең бернинди хисләр белән чагыштырып булмый торган тиңсез мәхәббәтен калдырып китте әни. Бишебезгә дә...

Ризидә ГАСЫЙМОВА

Мин әнинең нинди булуын белми үстем. Чибәр-нәфис идеме ул, ягымлы-сөйкемлеме? Аңа карагач, борчу-мәшәкать, моң-сагыш, уйгамь белән мөлдерәмә тулы күзләрен күрәсең дә, әнинең йөз сызыклары ничектер тоныкланып, югалып кала сыман иде. Шуның өстенә, бу акыллы-сабыр карашта әнинең үз язмышыннан разый булуы, Ходай аның өлешенә җибәргән авырлыкларны берсүзсез, үпкә-сыкрануларсыз үз иңнәрендә күтәрәчәге дә ап-ачык «язылган» иде.

Без гаиләдә биш бала. Тик җырдагыдан аермалы буларак, без иркәрәк үстек бугай. Дөрес, әнинең безне сөеп-сыйпап, җайлап-көйләп утырырга вакыты юк иде. Кайбер әти-әниләр сыман, бертуктаусыз «тәрбияләргә», һәр адымыбызны тикшереп, бимазалап торырга да арасы булмады. Үзе дә аңламастан, ул безне үз иркебезгә куйды. Шунысы гаҗәп: безгә эш кушарга да «оныта» иде әни. «Үзем», «син күтәрә алмассың», «сиңа авыр булыр», дип, тормышның бәләкәй генә авырлыкларыннан да араларга омтыла иде. Инде бераз чирләп китсәк, әз-мәз ютәлли башласак, әнинең бөтенләй тынычлыгы югала, йөзен хәсрәт пәрдәсе каплый. Әгәр кулыннан килсә, ул безнең бөтен авырту-газапларны үзенә алыр иде. Шуңа күрә без ничек тә әнине борчымаска тырыштык. Ни кырыс әтидән түгел, әнинең «йөрәген бозу»дан куркып, әйбәт укырга, гел туры юлдан гына йөрергә омтыла идек. Тик менә хәзер уйлап-хәтерләп утырам да, без, әле акыллы-тәртипле саналган балалар да, яшьлек җүләрлеге, дуамаллыгы белән әнигә күпме борчу китергәнбез...

Бүгенгедәй хәтеремдә – Казанда, университетта укыган чагым. Җәйге каникул вакыты – хуш исе белән исертә торган җылы, бөркү, тылсымлы, матур кичләр. Өйдә безне клубка чыгудан тыючы юк иде. Ләкин миңа кадәр үк, әле абыйлар-апалар өчен куелган соңгы чик бар – төнге уникe. Тик җәй көне уникe бик «иртә» була бит әле.

Шулай, капка артында сөйләшеп утырып, мин вакытның ничек узганын сизми дә калганмын – сәгать телләре төн уртасын узып, әкрен генә бер тирәсенә барып җитмәсенме! Аяк очларына гына басып, кереп ятсам, бәлки, әни белми дә калыр иде – гөнаһ шомлыгына каршы, өйалды ишеге эчтән бикле. Әтинең, уйлапнитеп тормастан, келәне төшереп кереп китә торган гадәте бар иде. Ишекне шакымакчы булам – кыюлык җитми. Уятыргамы-юкмы, дип икеләнеп, нишләргә белмичә аптырап, үземне бик бәхетсез һәм юньсез кеше дип хис итеп, озак басып тордым. Таң ата башлады. Андасанда, ялгышып, беренче әтәчләр аваз салды. Лапаска кереп, әти бүген генә урманнан чабып кайткан хуш исле печән эченә чумдым...

Ниндидер ыгы-зыгыга, сөйләшкән тавышларга уянып киттем. Башта, аңышмыйча, як-ягыма карандым – ябылмыйча калган лапас ишегеннән ургылып кергән таң яктысы почмакта ваемсыз гына печән күшәп торган сыерны, адашып, печәнлек авызына сөяп куелган баскыч басмасына кунаклап калган ялгыз чебешне күрсәтеп, мине бу фани дөньяга кайтарды. Эх!.. Әти белән әни дөнья бетереп мине эзлиләр. Ишетеп-белеп утырам – әни йөгереп диярлек бакча башларын әйләнеп кайтты. Әти урамнарны урап керде. Мин «юк идем». Менә хәзер, үзем дә балалар үстерүче ана буларак, мин аларның хәлен шулкадәр яхшы аңлыйм – җиткән кызың кичке биләмнән кайтмый калса, ниләр уйларга белмәссең! Ә ул чакта мин йомшак күңелле, тиз шөбһәгә бирелүчән әнине бик кызгансам да, торып, алар янына чыгарга курыктым. Дөресрәге, оялдым. Үзәкләрне өзгән үкенү тойгысыннан калтыранып, кымшанырга да кыймыйча утыра бирдем. Менә әни лапаска килеп керде, бик гаепле кыяфәттә печән арасында бөрешеп утырган кызын күрде, һәм нибары бер сүз әйтте: «И Аллам...» – диде. Шулай диде дә борылып чыгып та китте. Бар кыюлыгымны җыеп өйгә кергәндә, әни урын өстендә ята, әти аңа дару эчереп йөри иде. «Кисәк йөрәк хәле китте анаңның», – диде ул, миңа шелтәле караш ташлап. Мин сыерларны савып, малларны көтүгә куып кергәч тә тора алмады әни. Бу, күрәсең, «нервный срыв» булгандыр. Фельдшер апа укол ясап чыгып киткәч, кыяркыймас кына әнинең янына ук барып утырдым. Аның авыр эштән яргаланган җылы кулын үземнең учыма алдым. Әни миңа таба борылды. Шулкадәр яратып, мине исән-имин күрүенә сөенеп туя алмыйча, өздереп карап куйды ул – кыен да, бер үк вакытта рәхәт тә булып китте миңа...

Гомер булмаганны, ике көн авырып ятты әни. Мин көткән ачу-үпкә сүзләрен дә әйтмәде. Әти дә дәшмәде.

Әни, әни... Бәйрәм-ял көннәрендә без бишебез дә гаиләбез, балалар белән бик күп булып туган-үскән нигезгә җыелабыз. Мин үзем капкадан керү мизгелен аеруча яратам: әти белән әни безне түр тәрәзәдән күреп алалар да, сөенечтән балкып, ашыгып-кабаланып ишегалдына кадәр каршы алырга чыгалар. Аннары туганнар арасында кочаклашулар, хәл сорашулар башлана, һәркем үз куанычларын һәм көенечләрен сөйли. Тик чират көенечкә җиткәч, «әнигә әйтә күрмәгез...» дип, берберебезне кисәтеп куярга онытмыйбыз. Уйламый кылган гамәлләребез, ялгышларыбыз белән әнине борчыган чакларыбыз булса да, шунысы күңелгә тынычлык бирә иде. Аллага шөкер, без әти-әнинең йөзенә кызыллык, оят китермәскә тырыштык.

блогер: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

Галиҗәнап Татар театрының таҗындагы гәүһәрләр берсеннән-берсе балкышлырак. Юк, исемнәрне санамыйм. Гасырдан ашкан иҗат дәверендә Сәхибҗамал Волжскаядан, Фатыйма Ильскаядан, Гөлсем Камскаядан, Гөлсем Болгарскаядан башлап «ская»лар байтак булган. Купшы тәхәллүсләр сәхнә кануннары кушканга күрә генә сайланмагандыр инде ул. Бәлки «фәләннәрнең кызы театрда уйнап йөри икән» дигән кырын хәбәрләрдән нәсел-нәсәпне аралау өчен дә фамилияне ярып салу ярамагандыр.

Илсөя ТӨХФӘТУЛЛИНА Камал театры сәхнәсенә моннан 30 ел элек аяк баскандагы фамилиясен үзгәртмәде. Аны Алсу Гайнуллинаның ике туган сеңлесе икән дигән хәбәр озата кайтты. Яңа артистканың яшь кенә түгел, бәлки, әле гаҗәеп матур да булырга тиешлегенә бер шарт иде бугай бу туганлык. «Төхфәтуллина» дигән фамилияне аңа – Щепкин исемендәге югары театр училищесында укып йөргән булачак артисткага икенче бер артистыбыз – Рамил Төхфәтуллин ялгаган булып чыкты. Мәскәү урамнарын урагандa Мәскәү күзе юраган мәхәббәт булган икән ул! Шуңа күрә театрда тагын бер Гайнуллина булмый калды.





Асия
ЮНЫСОВА

СӨЙКЕМЛЕГӘ КҮРӘ СӨЕКЛЕ







Илсөя үзе сентябрь кызы. Әмма Татарстанның халык артисты түгәрәк юбилеена кунакларны ноябрь ахырында җыйды.

Алданрак килдем театрга. Капшый торыйм әле. Буш фойеда йөреп торам. Буш дип инде... Диварларда Илсөя Төхфәтуллина уйнаган спектакльләрдән фотокүргәзмә. Мәйсәрәләр, Галиябанулар, Маргариталар арсында йөренеп торам. Бераздан без – тамашачылар күбәеп тә киткәнбез икән. Диварга тезелгән фотосурәтләрдән алган тәэсир, матурлык хозурлыгы гына да кара көз кичендә театрга дип өйдән чыгып китүне аклый сыман. 50 нче–60 нчы еллар кинооператорлары йөз матурлыгын экран тутырып күрсәтергә ярата торганнар иде. Менә аларга материал монда! Мәрмәр маңгай, җәя кашлар, ук керфекләр, ганҗәдәй иреннәр. Ул мөлаемлык, ул сөйкемлелек, ул караштагы назлылык! Нindидер кибәрле назлылык түгел, җылыта, юата торган назлылык бу. Ярабби! Шушы кадәр чибәр булып була микәнни соң ул! «Алсуга җиткәне юк!» – дип йөри идем бит әле. Әллә уздырган инде?! Хәер, нәселләре бер шул, калыплары бер! Ходай Тәгалә кечесенә җырлау куәсен дә мулдан бүләк итеп ташлаган. Кинәнсен генә татар театры.

Кинәнә дә. Бөегебез Марсель Сәлимҗанов аны хәтта Мәскәү юлыннан туктатырга да омтылып карый. «Кал! Мәйсәрәгә кертәм мин сине!» Калмый кыз ул чагында. Әмма дүрт елдан соң «керә» ул Мәйсәрәгә. Галиябануга да керә. Инде Мәскәү остазлары мәктәбен узган, вокал мөмкинлекләре чарланган оста артистка булып килеп керә. Сәхнә түренә эленгән экраннан яраткан сандугачын – шәкертен 100 яшьлек остазы сәламләде. Гомер еллары да, арада яткан 30 ел да кызның образын остаз күңеленнән юмаган.

Юбилей сәхнәсендә Илсөя Төхфәтуллина уйнаган спектакльләрдән өзекләр чиратлаша. «Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Эзләдем, бәгърем, сине»... Булат белән Мәйсәрә, Хәлил белән Галиябану, Рәхимҗан белән Нурсилә – Илсөя белән Рамил Төхфәтуллиннарның мәхәббәттә аңлашуы, 30 ел сыналган мәхәббәтләренең гомерлек мәхәббәт икәнлеген меңләгән күз каршында исбатлавы иде бу күренешләр. Бер-береңне шулкадәрле яратып уйнамасаң, дөньяларыңны онытып икәү генә кала белмәсәң, тамашачыны катарсиска җиткерү, ягъни тетрәндерү мөмкин түгелдер. Илсөянең меццолирик сопраносы белән Рамилнең драматик баритоны тамашачының йөрәген яулап алган мизгелләр татар театрының казанышы ул. Татар театры, барыбер дә, халык йөрәгенә юлны нотык сөйләп түгел, бәлки, үзәкләрне өзәрдәй җырлар җырлап ярган! Илсөянең фа-диезларны ала торган тавыш мөмкинлекләре йөрәк түренә җиңел үтеп керә алуына инде ничә инандык.

Ә бит шушы артистка – сабакташы Әмир Камалиев: «Ул безнең курсыбызның сандугачы иде» дигән Илсөя – үзенең комедияләрдә дә уйный алуын исбатлардан элек, «Ричард III» спектаклендә Англия королевасы Маргаританы да ышандырырлык итеп, тавышына хакимләр аһәңнәре ягып уйный белде. Комедия дигәннән, өр-яңа премьерада ул Гөлбану булып чыгачак. Бу юлы да алар ире Рамил белән бергә сәхнә тотарга җыена. (Сүз уңаеннан, Рамил Төхфәтуллинның кабат Камал театрына кайтуы Илсөянең юбилеена иң зур бүләк булды. Хәер, бер аңа гына микән әле.)

Бу гаиләдә хәзер егет кеше дә үсә. Камил онык кем булыр икән – артистмы, режиссермы, юристмы?

Артистканың иҗат биографиясендәге тагын бер рольне күрмәмешкә сабыша алмыйм. Бу – Зөләйха! Рамил Төхфәтуллинның «Зөләйха» фильмы (Гаяз Исхакый әсәре буенча) һәртөрле гыйсъянчылыкка әзер 90 нчы еллар өчен дә вакыйга булган иде. Шул фильмда Илсөя иҗат иткән каһәрләнгән хатын-кыз образы безнең сәхнә иҗаты тарихында бердәнбер булып кала әле, Зөләйха оныту белмәс хәтерне һаман тетрәтә. Аның ул фильмдагы әрнүле карашы, елапелап арыган күзләрендәге сагыш – ул безнең дә әрнү, безнең дә сагыш!

Ә бит бу кыз бала, безнең Илсөябез җырлы-тальян гармунлы гаиләдә Зәйнәп белән Җиһангирның дүрт баласы арасында төпчеге булып, үзе дә әнисен «Ал Зәйнәбем» җыры белән куандырып, алар җырлаган җырларны отып алып үскән. Әнә берсен – әнисе







PRESSA.RU

яраткан «Ачылы тау» җырын газизләренең фотосурәтенә карап, хатирәләрен моңга манып җырлады. Мөгаен, ул бу мизгелләрдә үзе дә җилкәсенә көянтә-чиләк элеп, Зөягә суга төшкән яшь чакларын сагынгандыр, Дәвеш болыннарында печән җыйган елларын, болын җиләге җыеп йөргән җәйләрен юксынгандыр, сыер савып кергән кичләрен искә төшергәндер... Үткәннәр үткәндә кала шул. Әнә инде үзенең төпчек кызы Диләрә ишек ярыгыннан гына карап, әнисенең артистлар бүлмәсендә грим ягынып утырганын күзәтә. Әнисе моннан 30 ел элек Мәйсәрә роле өчен тегелгән зәңгәрсу күлмәктән. Буй-сыны бу 30 елда бер дә үзгәрмәгән. Бергәләшеп фитнеска, йөзәргә йөрүләрнең хикмәте инде бу. Чү! Әнисе кузгалды. Димәк, сәхнәгә чыга. Диләрә театр чаршавының икенче канаты ягына йөгерде. Хәзер ул үзе дә аңа каршы чыгачак.

Алар 1984 елда, Щепкин училищесына 12 егет, 6 кыз киткәләр.120 кешелек конкурсны узганнар, имеш.

Казан консерваториясенең беренче курсы студенты Диләрә Төхфәтуллинаның тавышын, әнисенә бүләк итеп җырлаган катлаулы арияне тыңлагач, тамашачы аһ итте. Пышын-пышын хәбәрләшү китте: «Вена операсына чакырганнар икән дә, кыз Клара Хәйретдиновада гына укырга телим дигән икән, ди. Олы кызлары Индира юрист икән. Югыйсә анысы да җырлый, ди». Кызының җырлы бүләген кабул иткәннән соң, Рамиленең, Булат авызы белән әйтелгән: «Синнән дә матуррак кызны күрмәдем», – дигән соклanулы сүзләрен ишеткәннән соң, Илсөябез бер тында залга серен чишә: «Бәхетемә рәхмәт!» Әйбәт бит. Әгәренки ул, инде Мәйсәрә авызы белән: «Узган гомер бигрәк җәл!» – дисә, ни хәлләр итәр идек тә, аны ничек юатыр идек.

2017: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!

Яшь драматург Сөмбел ГАФФАРОВАның «Килмешәк» пьесасы буенча куелган спектакль... Премьерасы 2017 елның октябрендә узды... Рецензияләр, күзәтүләр шулай башлана. Ә «Сөембикә»леләр өчен ул безнең Сөмбел. Һәм ул татар сәнгатендә вакыйга ясады!

Сөмбел, «Килмешәк» – татар халкы тарихындагы аянычлы тема – мөһаҗирлекнең драматизмын күрсәтә торган пьеса. Бу теманы XXI гасырда күтәрүеңнең сәбәпләре нидә?

– Пьеса IBSEN INTERNATIONAL Кытай–Норвегия–Россия проекты кысаларында язылды. Оештыручылар теманы сайлаганда бик озак киңәшләшкәннәр. Мөһаҗирлек-миграция темасы гомер-гомергә актуаль. XXI гасырда да халык яхшырак тормыш эзли. Нәрсәдәндер кача, нәрсәгәдер өметләнә. Бу тема күтәрелмәде, ул дәвам итә.

Әсәреңнең татар театрының төп сәхнәсендә – Камалда куелуын үзең ничек кабул иттең?

– Бу – минем һәрбер Яңа ел кичендә сорала торган теләгем иде. Г. Камал театры сәхнәсенә менү, пьесаның Фәрит Бикчәнтәев тарафыннан куелуы – тормышымдагы иң югары үрләрнең берсе. Пафослы яңгырыйдыр, әмма бу чыннан да шулай. Могҗизалар илендәге Алиса сыман, бик тә керергә теләгән гөлбакчага эләгүгә тиң. Аермасы шунда: минем гөлбакчам төш түгел!

Спектакльдән соң иҗади тормышыңда нәрсәләр үзгәрде?

– Мин үземә күбрәк ышана башладым. Башка драматурглар белән аралашам – алар гражданлык позицияләре көчле булган кешеләр. Андый кешеләрнең бар икәнен белү яшәүгә, язуга дәрт өсти.

Әле ниндидер проектларда катнашасыңмы?

– Хәзерге вакытта Камал театры оештырган «Яңа татар пьесасы» лабораториясендә катнашам. Рус драматургиясенең бүгенге көндә популяр вәкилләре – Юлия Тупикина һәм Евгений Казачков безне пьеса язарга өйрәтте. Башта кануннарына төшендерделәр... аннары үзебез теләгәнчә иҗат итәргә куштылар!

Шушы көннәрдә театрның кече залында лабораториядә катнашучыларның пьесалары укылачак. Камал театры артистлары һәм режиссерлар тамашачы һәм оештыручы-кураторлар алдында чыгыш ясарга әзерләнә. Бу бик дулкынландыргыч этап, чөнки укудан соң фикер алышу була, ә ул фикер алышулар башыңнан сыйпау гына түгел шул, пыр туздырулары да бар!



Сөмбел Гаффарова: «Минем гөлбакчам төш түгел!»

Фото: Ксения Богданова



Нәсүр ЮРЫШБАЕВ

Казан дәүләт университеты журналистика факультетының татар бүлеге


Өч бала атасы

Карьера: журналист, сценарист, режиссер, оператор

Тормыш шигаре: «Сабырлык, гадилек, кешелеклелек – тормышның өч тоткасы шушы».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

сөендерде







көендерде


Гайнә каны тартып кайтарды

38 ел читтә йөргәннән соң, туган ягым Барда районының Бакча авылына кайтып, туган нигеземне яңадан сатып алдым. «Ural-Film Gaina Media» кино төшерү студиясен ачып җибәрдем. Мин бит Гайнәләр ыруыннан, шуңа да студиягә Гайнә исемен куштым. Элек документаль фильмнар төшерү белән генә шөгыльләнә идем, быел мәнә беренче тапкыр Галимҗан Гыйльманов-ның «Нигез йорт» хикәясе буенча нәфис фильм төшерәчәкбез.

Эшләгән кешегә күбрәк «эләгә»

Хәзер мин ике илдә дә яшим бит. Лейпцигта тележурналист булып эшлим. Саксония полициясе мин төшергән видеосюжетлар аша бандитларны тотты. Шуннан соң ул неонацистларның ишләре мин яшәгән йортка килеп, почта тартмасын шартлатып китте, аннан башка да куркытулар булды. Ул чыннан да куркыныч нәрсә икән. Ләкин аңа карап яраткан эшеңнән ваз кичмисең, исән калуыңа шөкер итеп, эшли бирәсең.

сөендерде





көендерде

Чикләүләр «кыздыра» гына

Безнең илгә карата нинди генә санкцияләр – чикләүләр кертмәсеннәр, аңа карап Россияне тезләндереп булмый. Киресенчә, илебезнең куәте ачыла гына бара кебек. Олимпиада икән, Россия алга чыга; футбол икән, Россия аны үзендә үткәрә. Татарстан гөрләп тора: президент Рөстәм Миңнеханов корольләр, шәехләр белән очрашып, үзара файда китерә торган килешүләр төзи. Кыскасы, халыкны санкцияләр белән генә куркытып булмый бездә.

Терсәк сугышы


Читтә яшәп кайткач, бигрәк сизелде: халык кырысланган. Моның сәбәбе нидә икән, дип уйлана торгач, бер кызыклы фактка игътибар иттем. Бәлки, мин ялгышамдыр. Германиядә мин яшәгән Лейпциг шәһәрендә 20 театр бар.


Бу театрларга үзләренә акча эшләргә кушалар дип уйлыйсызмы? Юк, театр-ларны муниципалитет яшәтә.

Бездә хакимият мәдәниятка һәм мәдәниятлелеккә игътибарны аз бирә. Шуңадырмы, сыйфат турында онытыла, акча эшләү беренче планга чыга.

Акча исә, үзегез беләсез, терсәк белән этеп-төртүгә китерә.

сөендерде







көендерде

Яңа ел белән!

Форсаттан файдаланып, хатын-кызларыбызны Яңа ел белән котлыйм! Тормышымда урын тоткан барлык хатын-кызларны яратам. Әниләр, апа-сеңелләр, сөйгән ярлар – ир-егетләрнең тормышын ямьләп, аны мәгънәле, гамьле, чын итә торган кешеләр бит сез! Яңа елда яңа бәхетләр телим. Сез бәхетле булсагыз, без дә бәхетле.

Полиэтиленсыз да яшәп була...

Ярый әле Green Peace экологик оешмасы бар. Югыйсә экологик һәлакәтләр безне урап уза, кайдадыр ерактагы кыйтгалар гына зыян күрә, дип яшәргә өйрәнеп кит-тек. Җир йөзендәге урманнарның 70 про-центы Россиягә туры килә, дип мактана идек, ләкин үзебез үк аны юкка чыгару юлына басканбыз. Саный китсәң, коточ-кыч күп икән ул проблемалар. Әле мәнә Гринпис «Ашан» кибетләрен бушлай по-лиэтилен пакетлар өләшмәскә ризалаткан. Без ел саен чүплеккә ташлаган полиэти-лен пакетлардан гына Мәскәүне өч тап-кыр каплап куеп булыр иде. Ә чыгарып ташлаганнары суга, туфракка, организмга эләгә.

PRESSA.RU



Фото: Ксения Богданова

КИЛЕН – КАЙНАНА ТУФРАГЫННАН



Гөлнур САФИУЛЛИНА

«Яшәгән, ди, булган, ди, Саба авылы башында бер гаилә...» Оныкларына һәр кич үзе уйлап чыгарып сөйли торган әкиятләре шулай башлана икән Гөлсинә апаның. Ул хикәятләр тормыштан әллә ни аерылмыйдыр: Әмирә исемле кызның һәм Нариман исемле малайның бер-берсе өчен өзелеп торган әти-әнисе, алар бәхетенә куанып яшәгән әби-бабасы турындадыр алар. Шулай, әкияттән чынбарлыкка бер генә адым...

Саба дигәч, сүзнең язучы Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА хакында барганын күпләр инде аңлагандыр. Соңгы вакытта аның китапларын көтеп, эзләп алып укучылар байтак. (Юкка гына «Ел китабы» бәйгеләрендә җиңү яуламады бит ул!)

Ә бүгенге язмадан сез аның акыллы балалар үстергән әни, бик зирәк кайнана икәнен дә белеп калырсыз. Үзенә бик тә охшаган килененә сокланырсыз.

Эльвира: мин – Казан кызы. 17 нче татар гимназиясен тәмамладым, аннан КАИга укырга кердем. Компьютер безнең дөньяга яңа кереп килгән чак, хәтта социаль челтәрләр дә юк иде әле. Интернет аша аралашулар танышу сайтларында гына иде. Кызык өчен абый белән без дә теркәлдек. Һәм... мин бу хакта оныттым. III курста укыганда, бер дус кызымны туган көне белән котларга кирәк булды да, шул сайтка кердем. Баксаң, анда мине хат-хәбәр көтә икән бит! Фоторәсемем янәшәсендәге: «Матурлыкны кешенең тышкы кыяфәтеннән түгел, эчке дөньясыннан эзләгез», – дигән сүзләремне укыган да, «Әгәр күңелегез дә шундый ук матур икән, сез – минем идеал!» – дип язган бер егет. Алим, Сакраменто диелгән. Интернетны ачып карадым – Америка, Калифорния штаты! Мондый исемне дә беренче ишетүем, кемдер минем белән шаярта дип уйладым. «Идеал кешеләр булмый!» – дип җавап бирдем. Шулай сөйләшеп киттек... Ә хат миңа, чыннан да, океан артыннан килгән булып чыкты! Алимнең анда укыган вакыты бу. (Скайп аша сөйләшкәч кенә тәмам ышандым моңа.) Электрон адресларыбызны алыштык, аннан – телефоннарны. Шалтыраткач, әнидән мине татарча сорады, монысы да йөрәккә сары май булып ятты... Тормышта кемдер белән танышканда, без бит башта аның тышкы кыяфәтенә игътибар итәбез, аннары, аралашканнан соң гына, эчке дөньясын ачабыз. Ә безнең киресенчә булды. Алимнең эчке дөньясы якын иде миңа! Максатлар белән яшәгән кешеләрне һәрвакыт уңышлы дип саный идем. Ә Алимдәге уйхыяллар, үз алдына куйган максатлар – бихисап!

Әнисе белән бик якын аларның аралары. Моны белә идем инде. Бер хатында: «Әнием белән очрашып алмыйсыңмы?» – дип сорагач, шунда ук: «Ярар соң», – дидем. Хәзерге акылым белән уйлыйм да аптырыйм: ничек шулай җиңел хәл иткәнмен? Никах күкләрдә укыла дигән сүз дөрестер ул – мин ул чакта күңел кушуын тыңлаганмын... Без Казанда очраштык. Бик дулкынландым, билгеле. «Кызым, Сабага да кайтып килмисеңме?» – диде Гөлсинә апа. «Кайтырмын», – дидем...

Гөлсинә апа: Эльвира безгә шимбә-якшәмбегә кайтты. Ул өйгә килеп кергәндә, өйлә намазына әзерләнеп йөри идем. «Мин дә сезнең белән бергә укыйм әле», – дип яныма килде. Йортыбызга шулай дога белән аяк басуын хәерлегә юрадым. Намаздан соң: «Бигрәк инсафлы бала, безнең килен булырга насыйп ит», – дип дога кылдым. Яратырга өлгергән идем инде аны... «Мин әби белән үстем, кечкенә чагымда бакчага йөрмәдем, гел аның янында булдым, намазга ул өйрәтте», – диде Эльвира. Ял арасында икәү бергә авылга – Эзмәдәге туганнарга да кайтып килдек.

Эльвира: аралаша башлавыбызга ел ярым булгач, Алимнең кайтыр вакыты җитте. Чын-чынлап беренче күрешүебез булса да, бераз гына куркытса да, ул миңа тәүге очрашу кебек тоелмады. Көне буе Казан урамнары буйлап йөрдек, сөйләштек тә сөйләштек... Сабага кайтып китеп, өч көн узгач, ул миңа телефоннан тәкъдим ясады. «Риза», – дип җавап бирдем...

Гөлсинә апа: Алим Казанга, беренче очрашуга җыена. «Улым, Эльвираны беренче күрүдә ошатмасаң, күңеленә каты бәрелә күрмә. Ул кызны бик яраттым, минем дустым булыр», – дим. Алим әйләнеп кайтканчы, түзмәдем, Эльвирага да шалтыратып алдым: «Ничек?» – дим. «Бер-беребезне ошаттык!» – ди. Теләп тордым бит... Өчәү олы кызым Айгөлләргә кунакка барып килдек. Эльвира шунда безгә Коръән укып күрсәтте. Күзләребез яшьләнде... Өйдә аш үткәргәндә, Коръәнне гел Эльвира укый безнең хәзер, мин багышлыйм.

Гаиләдә олы кеше зирәк булсын.

Эльвира: Алим Америкадан кайтып ун көн узуга, без инде никах укыттык. Аның туган көнендә. «Беркайчан да авыл егетенә кияүгә чыкмаячакмын», – дия идем. Моны тирә-юнемдәгеләр барысы да белә иде. «Беркайчан» дигән сүзне беркайчан әйтмә диләрме әле?

Алим – урманчы. Казан дәүләт аграр университетының урман факультетын кызыл дипломга тәмамлаган. Америкага укырга киткәнче, Коркачыкта урманчы булып эшләгән. Урман аның мәхәббәте дә, җан сызлавы да... Урманнарның бүгенге хәлен – аларның кирәксезгә әйләнүен ул шәхси фаҗигасе кебек кабул итә. Җәен үз тирәсенә мәктәп укучыларын җыеп, аларны агач утыртырга, үстерергә өйрәтүе, «Салават күпере» журналын алдыручы 10 мең гаиләгә бүләк итеп чыршы орлыклары таратуы да – шуңа аның. Җир шарына янаган экологик һәлакәтне булдырмый калу, бу проблеманы глобаль масштабта үзгәртү турында өметләнә.

Без аның белән идеяләр, проектлар буенча яшибез. Өйләнешкәч, Алим Казанда «Татгазинвест» оешмасында эшләде. Кызыбызга өч ай чакта аны Мәскәүгә бер проектка чакырдылар (агач үстерү белән бәйле проектларның күбесендә катнаша ул). Үзе икеләнсә дә, мин: «Барырга кирәк», – дидем. Бер ел Мәскәүдә яшәдек. Кайтуга аны «Биосфера» питомнигының директоры итеп куйдылар – ул аны аякка бастырды. Аннан менә, синең ярдәм кирәк, дип, Саба урман хуҗалыгына – Лесхозда ачылган лабораториягә чакырдылар. Авылда яшәрбез дип уйламаган идем... Бу лабораторияне Алимнең укытучысы, профессор Әхмәдулла Газизуллин ачкан. Аңа инде 86 яшь. Төп максаты – урмандагы агачларның генотибын үзгәртү, тәз, тиз үсә торган, сәламәт агачлар үстерү. Моның өчен күкрәп үсеп утырган иң яхшы агачның теләсә кайсы күзәнәген алып клонлаштыралар. Табигый рәвештә үрчегән агачтан аермалы буларак, мондые череми. Һәм бик тиз үсә! (Мәсәлән, усактан 45 ел урынына 25 елда инде материал алып була.) Промышленность масштабында эшли торган мондый лаборатория Россиядә башка юк! Агачның күзәнәге махсус сыеклыкта үсәргә тиеш. 13 ай буе шуның составы нинди булырга тиешлеген ачыклый алмадылар. Аннан, ниһаять, уйлап таптылар. Лабораториядә барысы да җайлангач кына, инде үз эшебезне ачарга вакыт җитте дигән нәтиҗәгә килдек.

PRESSA.RU



Эшне ничектер җайлап кына куша белә безнең әни. Китабын русчага тәрҗемә итәргә кирәк булды менә. «Кызым, әйдә, син башлап кара әле», – ди. «Мин нинди тәрҗемәче булыйм инде, әни!» – дим. Ул мине ашыктырмый – үз уйларым белән калдыра. Йөрим-йөрим дә, китапны кулыма алып, беренче җөмләләрен тәрҗемә итеп карыйм, аннан инде аерыла алмыйм... Эшләп чыктым бит!

Гөлсинә апа: балалар белән бергә яшәү ирем Фиргатьнең иң зур хыялы иде. Аның әтисе кебек күргән дусты бар, аларга барып кайткан саен: «Их, Револь абыйга кызыгам, аның кебек оныкларны бакчага озатасы иде», – дия иде. Әмирә белән Нариманны бакчага ул илтә, ул алып кайта безнең. Балалар кая гына кунакка китсәләр дә: «Бабай, ни хәлең бар?» – дип аңа шалтыраталар. Өйгә кайтып керүгә иң элек аны кочаклыйлар.

Килененнең улыңны яратуын күрү бик рәхәт!

Эльвира: кыз чакта беребез дә кайнана белән бергә торырмын дип уйламыйбыз инде без. Минем өчен дә бу стресс булды... Әмма безнең әни бик акыллы кеше.

Берсендә икебез арасында нидер булды. Сәбәбен инде хәтерләмим. Бераз тынычлангач, чәй эчкәндә әни миңа әйтә: «Кызым, син бер дәфтәр ал, нинди сыйфатларым ошамый – язып бар. Үзеңнең дә киләчәктә кайнана буласың бар, кабатламассың», – ди... Гомумән, һәр кешене нинди бар – шулай кабул итәргә өйрәнергә кирәк. Сиңа ошап бетмәгән якларын күрәсең икән, язмышын якыннан белгәч, аңлыйсың: менә бу ситуация аны шулай үзгәрткән, икенчесе – болай. Әйе, бездә дә башкалардагы кебек төрле чаклар була. Андый чакта әни, бер сүз дәшмичә, үзенә кереп китә, мин – үзебезгә... Бераздан чыгабыз, ул да оныткан, мин дә.

Гөлсинә апа: килен өчен кайнана үрнәк булырга тиеш дип саныйм. Яшьләр каршында үзеңне матур тотасың икән, сүзең дә үтәчәк. Күп гаиләләрдә вактөяк нәрсәләрне купайтырга яраталар. «Ул шулай әйтте», «бу болай әйтте»ләр, күпертә-күпертә, кар тавына әйләнә һәм әкренләп барысын да басып китә. Тормыш бозыла. Иң зур ыгы-зыгыны сүз тудыра. Бөтен хикмәт – телдә. Мин үзем кайбер сүзләрне үткәреп җибәрәм, онытам. Кешенең күңел халәте гел бертөрле була алмый, уңайсызрак чагында сиңа бигүк матур тоелмаган җавап биргән икән, нигә аңа тукталып торырга?

Эльвира: ирнең уңышы хатын-кыздан да тора дип әйтәләр. Хаклык бар бу сүздә. Авылга кайткан беренче ике елда Алимне гел: «Әйдә, кире Казанга китик», – дип аптыраттым. Аңа ничек авыр булганын хәзер генә аңлыйм. Никадәр тырышып та, лабораториядә бернинди нәтиҗәгә ирешә алмаган вакыты. Ә өйгә кайтса, анда мин тынгылык бирмим – һаман бер сүзне тукыйм... Бала белән декрет ялында утырган чагым: гел дүрт стена арасында. Сабада беркемне белмим, бер дустым юк. Аралашырга кеше булмау, дусларымнан аерылу читен иде, әлбәттә. Аннан кул эшенә тотындым – бәйли башладым. Заказ бирүчеләр барлыкка килде. Әни бик күп яңа кешеләр белән таныштырды. Үземне кирәкле итеп тоя башладым... Язмышым белән килешеп, аны кабул иткәч, иремә бар эштә дә ярдәм итә башлагач, Алимгә уңыш килде. «Син – иң әйбәте» дип ышандырганда, ул шундыйга әйләнә бугай. Әмма бу бер көндә генә булмый, моның өчен адым саен ireң өчен нидер эшләргә кирәк. Һәм иң мөһиме – үзеңне алга чыгарырга, беренче урынга куймаска...

Сабаны яратам мин хәзер. Яшәү өчен бик җайлы, рәхәт җир ул безнең. Әмирә белән Нариманның бакчалары искиткеч – Казанда андый балалар бакчасын табу да, аңа урнашу да авыр булыр иде. Алар белән Сәнгать йортына йөрибез. Барысы да янәшәдә, якын – юлга вакыт әрәм итмим. Мин үзем дә әби-бабай белән үстем. Шуңа күрә бүген балаларым өчен сөенәм: әби белән бабайның яратуына, иркәләвенә кадәр башка бит аның.

Эшебез дә Саба белән бәйле бит хәзер. Алим белән безнең үз гаилә кодексыбыз бар. Ун ел элек анда «бизнес ачарга телибез» дип тә язган идек. Нәрсә белән бәйле булачагын гына белми идек әле... Алимгә кабат бер елга Америкага барырга тәкъдим булды. Аның янына мин дә барып кайттым. Без икәү тирә-юньдәге бөтен «бакча үзәк»ләрен йөреп чыктык. Кайсысына керсәк тә: «Монда без ирле-хатынлы эшлибез», – диделәр. Безнең «Гафэль» дә – гаилә компаниясе. Аның юнәлешләре берничә. «Бакча үзәге»без әйбәт кенә эшләп китте менә. Районда бердәнбер ул. Декоратив агачлар сатабыз – Алим аларны Европадан үзе барып сайлап алып кайта. Интернет-кибет аша теләсә кем заказ бирә ала. Кыш көне, бушрак вакытта агачтан йортлар салабыз. Ландшафт дизайны белән шөгыльләнәбез. Суккулентлар үстерә башладык. Алимне Мәскәүләргә кадәр консультацияләргә чакыралар: «Агач үстерү – бала үстерү белән бер», – ди ул үзе. Иң зур хыялыбыз, әлбәттә, питомник. Аның инде проекты әзер. Алимнең анда күк җиләк, кара бөрлегән, карлыган, кура җиләге үстерәсе килә. Контейнерда утырган килеш үк җимеш бирә торган куаклар булачак алар.

Эш җитәрлек... Арып киткән чаклар да була. Әни шул вакыт җиткәнне каяндыр сизә. «Арыдың бугай, кызым. Концертка билет алдым, әйдә, барып кайтабыз», – ди. Шундый ул безнең... Гел онытмыйм. Алимне Америкага озаттык. Ансыз миңа кыен, күңелсез булачагын әни

белә бит: шул атнаны ук поездга билет алып кайткан – балалар белән мине Екатеринбургта яшәүче бертуган сеңлесе янына кунакка җибәрде.

Гөлсинә апа: нишләсәм дә, Эльвира белән киңәшләшәм. Ул булгач бик рәхәт... Телефоныма да «Эльвира җимеш» дип язылган. Безнең өйдә исә «җаным» сүзе күбрәк яңгырый. Алим белән аларның бер-берсенә исем белән эндәшкәннәрен ишеткәнем юк – «Җаным» диләр.

Эш бүлешкән юк безнең: кем буш, кайсыбыз өлгерә – шул тотына. Йортта тәртип булырга тиеш, әлбәттә. Тик өй мәшәкатьләрен беренче урынга чыгарырга ярамый: идән юып, тузан сөртеп кенә тормыш алга бармый.

Китап язганда өйне бөтенләе белән Эльвирага тапшырам. Гомер буе район газетасында журналист идем – китап язу моңарчы уема да кермәде. Лаеклы ялга чыккач кына тотындым бу эшкә. Һәм... минем икенче тормышым башланды. Никадәр яхшы, якты күңелле кешеләр белән таныштым китапларым аркасында! Геройларым – тормышта күпне күргән, күпне кичергән, әмма сынмаган-сыгылмаган көчле хатын-кызлар. Андыйлар юлыма очрап кына тора. «Ак бураннар аша» китабының прототибы Энҗе ханым белән, мәсәлән, социаль челтәрләрдә таныштык. Аның: «Бәхетле көннәремнең бер генә сәгатен кире кайтарыр идем», – дигән җөмләсе җәлеп итте. «Үткәннәрне кайтарып булмый шул, Энҗе, андагы хаталарны кабатламыйча, тормышны дәвам итәргә генә мөмкиндер», – дип яздым мин аңа. Шулай аралашып киттек. «Гел чит ил күренешләре генә тезгәнсең, начар яшәмисең дә кебек», – дим. «И-и, тормышымны белсәгез иде! Чит илгә бала белән операциягә йөрибез. Ул хирург пычагы астында ятканда, чәчемне йолкый-йолкый елап, башымда чәчем калмады инде», – дип җавап бирде ул.

«Ефәк кулъяулык» китабымның героинясы – суррогат әни. Без аның белән Шәмәрдәндә, укытучыларның республика конференциясендә таныштык. Сөйләшә башлагач, шушы темага килеп чыктык...

«Тау җылысы» дигән китабым киләсе елның башында дөнья күрәчәк. Ул Бельгиядә яшәүче милләттәшебез турында. Бу китап аның туган якны сагынулары, чит җирдә үз урынын табуының авырлыклары, андагы татарларны берләштерүгә керткән өлеше хакында.

Эльвира: лаеклы ялга чыккач, мин дә әни кебек яшәсәм иде дип хыялланам. Гади хуҗабикә булып кына калмыйча. Соңгы вакытта аны гел очрашуларга чакыралар. Гадәттә, күбрәк әти озата бара, китапны тарату белән дә бергә шөгыльләнәләр. Яза торган һәр яңа китабының эчтәлеген алдан белəм – ул гел сөйли. Болай миңа да җиңел: китап тышларын ясау минем өстә бит.

Гомумән, яңа идея булып, нинди генә эшкә тотынсам да, әни шунда ук күтәреп ала: «Матур булган! Тагын яса! Мин моны синнән сатып алам, берәрсенә бүләк итәм!» – ди. Ә идея белән кайнау бар инде ул бездә: берсе тәмамлана, икенчесе башлана. Миңа ошый! Тормыш агымын туктатырга ярамый – бер ишекне ябуга, шунда ук икенчесен ачарга кирәк.



Гөлсинә апа: Эльвира бер секундын бушка уздырмый! Хәтта кер үтүкләгәндә дә колагында наушник аның: үз-үзен камилләштерү турында аудиокитаплар тыңлый. Бәйләвен исә машинада барганда да кулыннан төшерми. Булдыклы – нинди эшкә тотынса да, җиренә җиткереп эшли. Ашарга пешерсә, минеке кебек ит белән бәрәңге генә булмый инде аның. Эше бик күп Эльвираның. Компаниянең бухгалтеры да бит. Көндәлек планы дәфтәргә язып куелган: бүген, иртәгә нишлисе, аннары... Ул шулай план белән яши. Аннан гаеп эзләсәм, мине кем диярләр?! Җай чыккан саен Алимгә: «Эльвира синең бәхеткә туган», – дим. Моны гел кабатларга кирәк, кеше күңеле бик нечкә бит ул: матур ягын күрсәтсәң, гел шуны гына күрәчәк. Мин аларны борчымаска тырышам. Эшләренә вакытлары күбрәк калсын дим. Аннан, киләчәктә кайда яшәрләр, белмим, кайда булсалар да: «Әти белән әни янында торганда рәхәт иде», – дип искә алсыннар иде.


Мин күбрәк кайнанама охшаган.

Эльвира: читтән караганда, безнең өйдә әни хуҗа дип уйларга мөмкин. Чынлыкта – әти. Әни – идеяләр бирүче, ә әти көндәлек тормышны көйләүче.

Алим белән туганнарны «синеке», «минеке»нә бүлмибез: әтинең дә, әнинең дә Эзмә авылындагы төп йортларына, балаларны алып, берүзем генә дә еш кайтып төшәм. Шундый кунакчыл алар! Алимнең Әлмәттә яшәүче апасы Айгөл дә күптән инде якын кешемә әйләнде. Бер-беребезнең уңышларына куанып торабыз. Алар өч кыз үстерәләр: Мәрьям, Асия, Әйшә – аралашып, дус-тату яшибез.

Гөлсинә апа: балаларымнан бик канәгать, шөкер. Улым белән киленемнән дә, кызым белән кияүдән дә. Киявебез акыллы кеше. «Бу дөньяда безгә килә торган уңышлар барысы да әни догасыннан гына, әти белән әни озын гомер кичерсеннәр», – дип тели икән.

PRESSA.RU



БАКЫЙ МӘХӘББӘТ



Роза
КАМАЛЕТДИНОВА

Без: «Яңа татар поэзиясенә һәм татар музыкасына нигез салучылар кемнәр?» – дип сораганда – беренчесе Тукай, икенчесе Сәйдәш, дип җавап бирсәк, инде: «Татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем? – дигәндә: «Бакый ага Урманче!» – дип, бүген хаклы рәвештә әйтә алабыз».

Нәкый Исәнбәт. («Казан утлары», 1969 ел, 12 нче сан.)

Күтеп алган газиз улына Бакый – мәңгелек дигән мәгънәле исем куйган Идрис хәзрәт кыек атып туры китерүен сиздеме икән? Юктыр, мөгаен. Ә бит Раббыбызның 99 исеменнән берсен кушканда Алла колы дигәнен дә өстәргә онытмаган – Габделбакый Урманче дип, үз кулы белән таныклык тутырган ул.

Булачак рәссам, сынчы-скульптор 1897 елны – 23 февральдә хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында якты дөньяга аваз сала. Урманчеларның тугыз буын нәсел-нәсәбе имамнар, мөгаллимнәр, алай да «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?» дип тик утыручы юк. Стан ясап киндер дә суккан, буяган-бизәгән дә, теккән-үргән дә алар. Җыр-бәеткә оста Маһибәдәр әбиләре эш-мәшәкать арасында әкият-риваятьләр сөйли, борынгы моңнарны яшьләргә җиткерүдән ямь таба. Әнкәләре Мәгъҗүбә абыстайның чигү-тегүгә кулы ятып тора. Апалары чәчәк-сурәтләр ясап кашага-эскәтер, сөлге чигәргә, өй бизәргә маһир. Җырчы һәм рәссам буласы тәкъдиренә язылган Бакый исә, кемнеңдер скрипкәдә уйнаганын күреп, агачтан үзе «каз муены» әтмәлли, көйләр сыздыра.

1907 елда гаилә Кече Салтыкка күченә. Ә Бакыйны әтисе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Малай сәнгать мәктәбе дип хыяллана, әмма татарга анда юл ябык. Казанда яшәү авырлашкач (акча килер җир юк, гаилә ишле), укуын ташлап, Тамбовта балалар укыта, Донбасс шахталарында күмер чыгара, Уралда металлургия заводында эшли, патша армиясендә хезмәт итә. Ниһаять, татарлардан беренче булып сәнгать мәктәбе студенты булу бәхетенә ирешә. Аннан Кызыл Армиягә алына. 25 яшендә генә Мәскәүнең югары сәнгать уку йортына аяк баса. Берьюлы ике – рәсем һәм сынчылык факультетларында укый. Төрки халык җыела торган Әсәдуллаев йортында бәрхет баритон тавышы белән борынгы татар көйләрен җырлап, милләттәшләрен шаккатыра.

1926 елда – диплом алыр алдыннан Казанга кайткан Урманчены сәнгать техникумының укыту бүлеге мөдире, мөгаллим итеп раслыйлар. Техникумда бер татар да булмавына ачынып, талантлар эзләргә тотына, муеннан эшкә чума.

Ә 1929 елда Бакыйны кулга алалар. Өендә тентү үткәрәләр. Энесе Һади Мирсәет Солтангалиев лекцияләренә йөргән икән. Ә Солтангалиевнең һәр адымы күзәтү астында, җәен ул Урманчеларда кунып та киткән булган.

Гарәп имлясын латинга алыштыруга каршы 82 сәнгать әһеле кул куйган хатта Бакый Урманче исеме дә булуны шымчылар белеп тора. Абыйлы-энеле ике егетне – Черек күлгә, аннан Мәскәүгә – Бутыркага алып китәләр. Бакыйны – биш, Һадины ун елга сөргенгә хөкем итеп, Ак диңгездәге Соловки утравына озаталар. Соловки хөкрәләренең берсендә сөргендәге үз ишләре – Сәгыйт Сүнчәләй, Мәхмүт Бөдәйли, Мирсәет Солтангалиев, Кәшшаф Мохтар каршында «Казан сөлгесе»н башкаргандагы кебек, рухланып, бүтән беркайчан җырлаганы булмавын еллар үткәч искә алыр әле ул. Сүнчәләй азык-төлек складында эшли, Бакыйны төлке, куян питомнигына эшкә урнаштыру җаен таба. Урманче шунда чыга торган газетага рәсемнәр дә ясый. Кәгазь-каләм – кул астында. Бик күп портретлар эшли.

Дүрт елдан – хөкем срогыннан бер ел алда иреккә чыга. Казанга кайтып җитәм дигәндә – Канаш тирәсендә рәсемнәрен урлыйлар. Үкенечләр, үкенечләр... Энесе Габделһади белән дә күрешүләр насыйп булмый, аны 1938 елда Соловкида аталар. Икенче энеләре Габделбари исә Бөек Ватан сугышында һәлак була.

Гаепсезгә төрмә газаплары кичергән Бакый исеме аклануны бик озак көтә. 92 яшендә, үләренә ел ярым кала aклана. Гарәп язуын яклап язылган хатка кул куйган сәнгать әһелләре арасыннан – үзе исән чакта акланган бердәнбер кеше ул.

Соловкидан кайткан рәссамны Казан колач җәеп каршыламый, әлбәттә. Өстә иске сырма, башта малахай, әмма чиста күк йөздәй күзләре һаман зәп-зәңгәр бит әле. Тик барыбер таныш-белеш, танымамышка салынып, аны урап уза. Рәсемнәре кайсы югалган, кайсын кемнәрдер үзләштергән. Сагынып кайткан Казанын үзәге өзелеп, җаны сыкрап ташлап китәргә мәҗбүр ул. «Кара козгын»нар күзеннән качу, әзме-күпме эз югалту өчен дә кулай гамәл ич бу.

Казаннарга сыя алмаган Бакый Мәскәүдә үзен танытa, илһамланып эшли, күренекле рәссамга әйләнә.

Сара ханым

Мәскәүдә ул гомерлек олы мәхәббәте – Сара ханымны очрата. Милке тартып алынган, бөлгән Пенза сәүдәгәре Хәсән Башиев кызы Сара әнкәсе, сеңлесе һәм улы Морат белән 8 квадрат метрлы бүлмәдә көн күрә. Ире Хафиз Ишмәмәтов та репрессия корбаны, хат-мазары юк, сөргендә үлде дигән хәбәре генә ишетелә.

Гомеренең ахыры якынлашканда Бакый ага икенче никахтагы җәмәгате Флора ханымга йөрәк серен ачачак әле: «Балалы хатынга өйләнү өчен олы җанлы булырга һәм олы мәхәббәт тоярга кирәк». Әлегә... бу икәүнең бер-берсен табып кушылуы бер Хода хикмәте ич. Кодрәтлебез адәм балаларын – ир белән хатынны бербөтен итеп ярата, әмма мәхәббәтнең кадерен белсеннәр өчен икесен ике җиргә ташлый, дигән риваятькә ышанмас җирдән ышанырсың. Үз яртысын кемдер таба, кемдер гомер буе интегеп эзләп тә очрата алмый. Бу олы мәхәббәттән 1935 елда аларның уллары Илдар туа.

Ләкин... Озак та үтми, 8 метрлы фатир хуҗасы, акланып, үзе кайтып төшә. Нишләргә? Сараның

Фото: Рөстәм Мөхәммәтҗанов

PRESSA.RU



Флора ханым Урманче «Айгөл» портреты янында.

Тормышы җайланмаган, әмма сөйгәне, улы кайтыр да рәхәт яши башларбыз дигән хыялы исән әле.

зирәк әнкәсе – сәүдәгәр хатыны олы кызының язмышы кыл өстендә икәнен күреп, димче ролен өстенә ала. Яңа акланып кайткан кияүне «апасыннан матур сеңлесе»нә өйләндерү хәстәренә керешә. Чаршау белән генә бүленгән әлеге 8 квадрат метрлы бүлмәдә ике гаилә дә итагать саклап яшәп китә. Тагын бер малай киң дөньяга аваз сала. Ә Бакый ага олыгайгач та Хафиз Ишмәмәтовтан отып алган җырларны яратып җырлый торган була.

1941 елның язында Абайның 100 еллыгына әзерлек башлана, Урманчены Алма-Атага чакыралар. Сугыш чыгу хәбәрен ул юлда ишетә, кайтып, гаиләсен Алма-Атага алып китә. Балдызы белән Хафиз Ишмәмәтов туган яклары Пензага юл тота. Сугыштан соң Урманче гаиләсе – әнисе, балалары белән хатыны Сара – Мәскәүгә әйләнеп кайта, әмма аның үзенә юл ябык. Репрессияләнгән кешеләргә башкалада һәм портлы 39 шәһәрдә яшәү тыела дигән Указ чыккан. Урманче Петушкидан йөреп эшли. Алма-Ата, Казан, Ташкент та аны сыендыра алмый. Берара Балхаш бакыр заводында мәдәният сараен бизи. Ташкент сәнгать институтында укыта. Урта Азия, Казакъстан рәссамнары аны остаз итеп таный. Бары тик 1958 елда, 61 яшендә генә Казанга кайту насыйп була аңа. Өмет, яшьләрчә дәрт, ышаныч белән могҗизаи көчкә ия әсәрләрен иҗат итә. Тукай темасы, Тукай рухы аңа көч, илһам бирә. Чакырып-чакырып та Казанга кайтмаган, кайта алмаган Сарасын онытырга вакыттыр бәлки? Аһ, үткән гомерләрне онытып булса икән! Остазның горурлыгы булган рәссам Илдар Урманче әтисе янына кайтып, сайрашып таң аттырган чаклар олы бәйрәм, әлбәттә.

Сара ханым Бакый агадан бер ел алдан вафат була. Илдарлары да мәңгелек йортында инде... Урыннары оҗмахта булсын!

Айгөл

Җәһәннәм тәмуглары кичеп, репрессияләнгән кешегә кара шәүлә булып тагылган язмыш сынауларын үтеп тә, акылын, талантын саклап калыр, намусын, вөҗданын, оятын җуймас өчен адәм баласына нинди көч, ышаныч кирәк икән? Халык иҗаты әсәрләре адәмгә көч бирүче саф чишмә кебек, рәссамга илһам чыганагы булдымы икән? Себер татарларының йола җырларын, дастаннарын, бәет-риваятьләрен – халык иҗатын өйрәнүгә гомерен багышлаячак фольклорчы-галимә Флора Әхмәтова белән очрашу Бакый агага өстәмә көч, дәрт, илһам бирсә, гаҗәпме?! Дөрес, яше җитмешкә якынлашып килә, әмма йөрәге яшь бит әле. Ә бәлки моны язмыш сынавына юраргадыр?

Себердә – күлләр иле Күкрәнде авылында туып, укытучы Ваһап Әхмәтов гаиләсендә үскән Флора Казанда – Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар халык иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Еракларга тоташкан риваятьләр, тарихи шәхесләр – Күчем хан, Сүзгебикә ханымнар турындагы дастаннарны мавыгып бәян итүче кызның төс-кыяфәте коеп куйган Сүзгебикә (ә бәлки үз әнкәсе Әтнәбикә, йә бабасы Туктабай чалымнары?) түгелме соң? Ягымлы-йомшак тавышы, сүзнең тәмен белеп сөйләве... Фәнни конференциядә чыгышын тыңлап утырган рәссам яшь туташның рәсемен ясамый түзә димени?! «Аннан-моннан сызгалап» галимәгә бүләк ителгән шул рәсем тормышын да, язмышын да үзгәртер дип кем уйлаган ул чакта? «Вакыт кысан, иркенләбрәк эшләсәң иде...» диюен кыз: «Мин киләм, әйтегез генә...» – дип эләктереп алдымы икән? Тәүге очрашулары ничегрәк булгандыр – бусы сер булып калсын. Шунысы хак: килә Флора. Китмәскә килә.

Серле чәчәк, ай гөле – Айгөл дип йөртә иде Бакый ага аны. «Халкыбызның рухын күрсәтүче бөек әсәрләр иҗат иткән, 93 яшендә дә кылкаләмен, өтерге, борау, чүкеч ише эш коралларын кулыннан

төшермәгән, мәрмәр ташларны җырлаткан, киндерне көй-моңнар белән сугарган, кәгазь битләрендә төсләр симфониясе ачкан Бакый Урманчега мәхәббәтле, законлы ике гаилә тоту насыйп булды», – дип, истәлекләрен уртаклашачак Флора Әхмәтова-Урманче. Чынлыкта, «Бакый ага миңа гашыйк иде!» дип хыялланучы гүзәлләр заманында аз булмагандыр дип фаразлыйм. Сынчы-рәссам иң элек портретлар остасы да бит әле. Кәгазьгә, киндергә, агач-ташка кемнәрнең генә йөз-кыяфәтен уеп, мәңгелеккә мирас итмәгән ул. Ләкин бөегебез, Флора ханым сүзләренә караганда, Сарасыннан кала берәүгә дә бер күрүдә гашыйк булып, сүнми торган гыйшык утларында янмаган. «Аның иң олы мәхәббәте – Сәнгать! Әмма Бакый абыйның рухи дөньясын аңлап, җанының матурлыгын тойган, моңлы аһәңле бәрхет тавышын – җырлавын ишеткән хатын-кызлар дөньяларын онытып аңа үзләре гашыйк булалар иде», – дип сөйләгәне хәтергә уелып калган. «Тирән белемле, бик дини кеше иде ул. Күрәсең, бабаларыннан калгандыр, кулдан язылган, кадерләп саклый торган бик борынгы Коръәне бар иде. Җомга көннәрне ул шуны укып, күңеленә юаныч таба. Гомумән, ул бик иртә – сәгать дүртләрдә үк йокыдан тора. Таң атуын күреп ләззәтләнә. Мин дә иртә торырга күнектем. Иртәнге алты гына әле. Ризык өстәлдә. Ашап, чәйләр эчкәч, Бакый абый остаханәсенә төшеп китә. Һәм көне буе, арып талганчы эшли... Җырлый-җырлый эшли иде ул». Ә җыр дигәннән... гаҗәп матур, моңлы тавышы йөрәккә ятышлы Флора ханым үзе дә әкертен генә борынгы көйләрне көйләргә ярата.

«Сөембикә» журналының редколлегия әгъзасы, авторы, якын дусты иде ул. Әдәби-иҗтимагый басмабызның исеме «Азат хатын»нан «Сөембикә»гә күчкәч, Бакый Урманче иҗаты – «Сөембикә» әсәре журналның йөзен бизәүче атрибутка әйләнде. Кәгазьгә тушь белән язылган (1976), аннан агачка уелган «Сөембикә» (1978) – патшабикәләр чалымын горурлык һәм тирән сагыш, кайгы-хәсрәт, моң белән сурәтләгән әсәр – бәгырьләрне тетрәндерә, уйландыра. Йөрәк өзгеч югалту кичергән бит – дәүләтчелек таҗы җуелган, улы хәсрәте өстәлгән – менә-менә елап җибәрер, калфагындагы энҗеләр күз яше булып тамар төсле... Юк, еламас, горур башын күтәрер дә хакимнәрчә боерыклар бирә башлар, алга дәшер, чакырыр. Мескен түгел ул, горур! Рәнҗетелгән, әмма сынмаган! Бакый абыйның үзе кебек дисәң дә, арттыру булмастыр.

Казан Кремлендә барачак беренче күргәзмәсенә «Сөембикә»сен өлгертергә теләп, Бакый ага җан ата... Әмма эш бармый. Таба алмый иң кирәкле штрихны. Төс-йөзен ничегрәк сурәтләсәң дөрес булыр? Кем күргән Сөембикә-ханбикәне?

Шул көннәрдә Ания Туишеваның җырлавын ишетеп, Флора ханым хәйран кала. Махсус эзләп, табынын көйләп, җырчыны кунакка чакыра. Зәңгәр күзле, ак йөзле чибәр мишәр кызының (Сарасының якташы – Пенза татары түгелме икән? Ялгышкан – Сарытау кызы икән ул) җыры да, үзе дә Бакый аганың күңеленә хуш киләсен сизә... Ания Туишева белән минем дә очрашканым, аның хакында язганым булды, кем ничектер, әмма мин үзем «Сөембикә»дә аның да йөз чалымнарын таныйм.

«Ак калфак» Бөтендөнья хатын-кызлар берләшмәсе дә фольклорчы галимәбезнең турыдан-туры катнашы белән оешты дисәк тә, арттыру булмас. Без якыннан аралашып, киңәш-табыш итеп яшәдек. Журналның шул чактагы баш мөхәррире, «Ак калфак» оешмасын гамәлгә куйган Роза ханым Туфитуллова галимәне хәзер дә зур хөрмәт белән искә ала: «Сугыш вакытында Ленинград галимнәре, мөгаллимнәр Себергә эвакуацияләнгән. Флора Ваһаповна белем алган Тубыл педагогика көллиятендә һәм Төмән педагогика институтында укытканнар. Зыялы, гыйлем затлардан камил тәрбия алган, акыл, тәҗрибә, туплаган тирән белемле, тәрбияле зат иде ул. Ә Бакый аганы хасиятләп каравы-тәрбияләве, рәссамның бөеклеген аңлап, иҗатын пропагандалавы үзе олы хөрмәткә лаек».

Бөегебезгә иң зур терәк, якын дус, иптәш булган ханым аны ир бала алып кайтып та сөендерә. Урманченең «Айдар» (1973) портретыннан безгә искиткеч самимисадә, эченнән нур бөркелеп торган кара малай карап тора. «Бакый ага аны яратып: «Күчем хан токымы бит бу!» – дия торган иде. Улым безнең нәселгә – әтиемә охшаган», – дип сөйләгән иде Флора Урманче. Ул Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе иде.
Татар халык иҗатына багышланып, Тел, әдәбият, тарих институты әзерләп чыгарган күптомлык өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Кунакчыллыгы, аш-суга осталыгы, суыткычындагы – бик тиз пешә торган бармак башы кадәр тәмле пилмәннәре, Себер күчтәнәчләре, без исемнәрен дә белмәгән җиләк-җимеш, Фәридә Кудашевалар белән аларда кунак булуларны сөйли башласам... озакка китәр.

Рәссамның гаилә мәхәббәте сынлы сәнгать, җыр-музыкага мәхәббәт белән үрелеп барды.

Гомәр Бәширов 1990 елның августында көндәлегенә мондый сүзләр язып куйган: «Бик зур кайгыбыз бар. 6 августта 94 нче яшендә Бакый абзый вафат булды. Аның үпкәсе шешкән иде, үпкәсендә су хасил булган. Әҗәленә шул сәбәп. Күптән түгел бик һәйбәт сөйләшеп утырган идек. Менә хәзер ул юк инде.

Аксакаллардан иң өлкәне, иң дәрәҗәлесе китте. Бакый абзый революциягә кадәрге зыялылар, аларның гореф-гадәтләре, традицияләре белән хәзерге заманны тоташтыручы бер күпер иде.
Хәзер татар мәдәниятендә андый кеше калмады, элекке зыялылар белән хәзергеләре арасында җанлы элемтә өзелде.

Иннә иләйһи раҗигун».

PRESSA.RU



Шагыйрә Нәҗибә Сафина редакциядә бер шәлкем шигырьләрен калдырды. Җор телле, туры сүзле, тел, милләт язмышын кайгыртып яза торган трибун шагыйрәбез ул безнең. Фәлсәфи шигырьләре уйландыра, балаларга юллангыннары мажараларга күмә, лирик шигырьләре күңел кылларына кагыла...

Нәҗибә САФИНА

ЯРАТСАҢ ӘГӘР МИНЕ

Авыр чакта

Мөдәррискә

Кайтмаганны көтмә икән,
Җаныңны өтмә икән.
Бозлардан ут, утлардан су
Чыгар дип көтмә икән.

Көтмә икән хыялларның
Җирдән җәяү йөрүен.
Тузаннан да кече килеш
Көтмә кояш күрүен.

Син түгел, әле тирәкләр
Китмичә бер ноктадан,
Күтәп кояш игътибарын
Мәңгелеккә тукталган.

Син түгел, диңгезләр ята –
Мөлдерәмә җир күзе.
Аларга да җитмидер шул
Галәмнең җылы сүзе.

Үгиләр юк та кояшка,
Җирдә күпме үги бар.
Җаннарына җылы җитми,
Миндәй үксеп елыйлар.

Ярый, нур яулыгы белән
Кояш сөртә күзләрне:
«Шагыйрь булсаң, кояш итеп
Балкыт, – диеп, – сүзләрне! –

Эресен җанда бозларның
Утырып калганнары.
Чын кеше дип, таный кояш
Кабына алганнарны!»

Тик суларны агызырга,
Җанда кояш кабызырга
кирәк Син!
Әкиятләрне чын итүче,
Зарларны да җыр итүче
йөрәк – Син!

Йөрәк гөле

Дөнья татлы, дөнья ачы,
Кайнар, зәмһәрир салкын.
Үзем дә сизми, җанымны
Сөю утына яктым...

Сөю уты юлындагы
Бар нәрсәне яндыра.
Фанилыкта шушы хакта
Җырларга җыр калдыра.

Сөйгәннәрдән, бәлки, җирдә
Каладыр йөрәк көле?!
Мин киттем... йөрәк көлемдә
Тибрәлә йөрәк гөле.

Кирәк иде...

Кайгыга чумган иделәр,
Мин җыр башладым.
Иңнәренә баскан йөкне
Алып ташладым.
«Син кирәксең!» – диеп, мине
Кочып алдылар.
Мин җырлаган җырны бик тиз
Отып алдылар.
Аларга кайгы таратыр
Җыр кирәк иде.
Ә миңа башымны салыр
Җир кирәк иде...

Мин генә

Мин сине яраткан кадәр
Яратсаң әгәр мине,
Таулар тез чүгәрләр иде, –
Яратмадың син мине.

Әгәр мин яраткан кадәр
Ярата калсаң мине,
Ай акылдан шашар иде, –
Яраталмадың мине.

Әгәр минем яратуның
Тамчысы булса синдә,
Җилләр тынып калыр иде,
Исмичә бу мизгелдә...

Ярый яратмадың әле...
Ае да көндәгечә.
Таулар горур карап тора,
Сызгырып җилләр исә.

Мин генә сөю алдында
Тезләнгән тау, шашкан ай.
Сөю тотып торган давыл,
Тоткындагы ташкындай.

Шигырьләре аша без яңа образ ачтык. Унҗиде яшьлек кыз! Ул – студент, максатчан һәм омтылышлы. Ул – хыялый, дөньяны яңача күрә. Ул – гашыйк, сагына белә, ярата белә... Таныш булыгыз: Балтач районы Карадуган авылы кызы Миләүшә Гафурова. КФУның Югары журналистика мәктәбендә укый. Җанында авыл табигыйлеге дә, шәһәр купшылыгы да урын алган. Һәм алар, әлбәттә, иҗатында чагыла.



Миләүшә ГАФУРОВА

КҮҢЕЛЕМНЕҢ ЧӘЧЕ ҖИРӘН...

Сөю, бәхет

Сөю,
Бәхет.
Бу дөньяда һичбер тәхет
Кызыктырмый,
Бу икесе белән
Янәшә дә тормый –
Яхшы беләм.
Яхшы беләм сөю белән бәхет көчен.
Күперләр дә
Шул икесен очраштыру өчен
Салыналар.
Күмәрләр дә...
Онытырлар.
Кемгә кирәк
Синең ләхет!
Яннарында берсе калмый.
Кеше зирәк,
Кеше сайлый:
Сөю,
Бәхет.

* * *

Куркып калган сабый күңелемнең
Син кабыгын әрчеп алгансың.
Ник әйтмәдең туйгач, кире кулга
Ул кабыкны китереп саласың?

Хәзер атлыйм –
уйный күкрәктә җил,
Ул зиһенгә салкын тидергән.
Хәтеремә яхшы уелып калдың,
Юк иде шул болай тилмергән.

Тәрәзәмә бүтән шакыма,
Кышкы һава аннан агыла.
Сине яратырга сәбәп эзлим,
Яратмаска гына табыла.

* * *

Минем күзләр аша кояш карый,
Нурлар белән чәчләремне тарый,
Елмаюым белән елмая.

Һәр кесәмдә йөртә өч кашкарый,
Яманлыктан шулкадәрле
ул тиз арый –
Айлап түгел, көнләп картая.

Кеше күрмәгәнне шундук күрә,
Йөгереп килеп, барсын сөйләп бирә.
Алар күргәннәргә күз йома.

Шуңа күңелемнең чәче җирән,
(Төсе кояш белән бергә килгән),
Ефәк булып ята муеныма.

Минем аякларда кояш йөри,
Тик нигәдер беркем аны күрми,
Болай яшәүләре кызыкмыни?
Бары назлар белән туенам.

Чыннан да, ул шомлы көн
җитәрмени,
Явызлыктан кешелек бетәрмени?
Кояшым да җыеп алып китәрмени
Җирән чәчләремне муенымнан?

Илһам булып

Мин елмайган саен синең йөзләреңә
җылы ага,
Эчеңдәге күбәләкләр армый
канат кага-кага.

Куркасың син, син белмисең:
юлларыңда ташлар эри,
Төшенмисең – үзем сиңа илһам
булып килеп йөрим.

Чит кызларга караш салсаң,
күзең каплыйм кулың белән,
Гәрчә үзем миннән башкаларны
сөймәсеңне беләм.

Орышасың үз-үзеңне,
эш чыкмагач мине уйлап,
Ә мин атлыйм яланаяк
синең хыялларың буйлап.

«Кирәк түгел, – дисең кайчак
ярсып, – сөю дигәннәре!»
Шул вакытта күзләремнән
яшьләр тама эре-эре.

Куркам да мин, беләм дә мин
(сизмим генә әле исең) –
Илһам булып үзең һаман
акылымны төенлисең.





Халисә ШИРМӘН

СИНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

(Хикәя)

...Җепшек кар бөртекләре машина тәрәзәсенә килеп сылана, эреп, пыяла буйлап агып төшә, бик тиз күз күремен каплыйлар иде. Чистарткычларның җаен көйли алмый Рүзәл. Кызулатып кына куюы була – «дворниклар», пыяланы кырдырып, сызгырган тавыш чыгара башлыйлар. Рүзәлнең моңа ачуы килә, үрелеп, аларның амплитудасын әкренәйтә. Шуны гына көткән кебек, кар бөртекләре яңадан тәрәзәне сырып ала, юлны каплый. Көне дә көн булмады инде. Әйтерсең, әбисе әкиятләрендәге Каф тавы арты җен-пәриләре, барысы да бергә сүз куешып, Казан белән Әлмәт арасында дуен оештырырга карар кылганнар. Юлга ятып себереләләр, күккә күтәрелеп бөтереләләр, озын карлы бармаклары белән юл читен капшап, аны юлчы күзеннән яшерәләр.... Юлга чыгар алдыннан интернеттан һава торышын да карады югыйсә, көн аяз булырга вәгъдә ителгән иде. Соң, буран чыгасын ярты көн алданрак белә алмый микәнни бу синоптиклар?! Беркемгә, бернигә ышанырга ярамый шул, ярамый!

...Алда неон яктырткычлары белән балкып, кичке караңгылыкны ерткан зур реклама тактасы күренде. Хәер, реклама түгел икән. «Машина йөртүче! Ашыкма! Сине өйдә көтәләр!» дип язылган плакатны күреп, Рүзәл үзалдына елмаеп куйды. Ашыгырсың монда. Көч-хәл белән сөйрәлә. Тизлекне алтмыш-сиксәннән арттырып булмый. Өйдә көтәләр инде анысы, сүз дә юк. Бүген – Яңа ел киче. Хатыны пилмән бөгәдер, ике малае, чырык-чырык килеп, янында бөтереләдер. Өйдә – чыршы исе, әфлисун, мандарин иседер... Ел саен бергә мәш киләләр иде дә, быел менә башкачарак килеп чыкты шул. «Акча кирәк!» дигән уй, кулыннан җитәкләп, зур

юлга алып чыгып китте. Чыгуы үзе әйбәт булды тагы, буш кул белән кайтмый: арткы утыргычта яткан күн тышлы кара портфелендә – егерме миллион сумлык товарга килешү. Соңгы араларда Рүзәл эшләгән фирма хисабына мондый табышның кергәне юк иде. Директорлары кул куйган бланкны алып киткәндә йөрәгендә шом бар иде әле. Егерме миллион бит! Хәерлегә булсын. Эшне кызуында сугып калырга кирәк: шәһәргә кайтып җиткәч, Рүзәл килешүне банкта быелның соңгы көне белән теркәп, тиешле адреска акчаны күчереп өлгерергә тиеш. Бухгалтер ханым, өенә кайтмыйча, аны көтеп тора. Әле вакыт бар. Әле өлгерә.

Ашкынулар үкенечкә була,
Юктыр минем сабыр канатым...
Үкенечләр – урман, урманнарда – буран,
Көлә-көлә кереп адаштым...

Салонда яңгыраган салмак җырны тыңлый-тыңлый, үз уйларына чумып барганда, дөньяны каплап алган ак кар чаршавы аша алдагы машиналарның кызыл фаралары янып-янып алуы күзгә чалынды. Тормозга басалар. Әкренәяләр. Ни булды икән? Рүзәл дә, шомланып, тизлеген әкренәйтте, алга, ике як юл кырыена чекрәеп карап бара башлады. Юк, машина туктаган, авария булган урын күренмәде. Җиңел сулап, тизлеген арттырган гына иде, юл кырыенда кулларын чак күтәреп, тораташтай басып каткан адәм күренде. Кырыйда кюветка төшеп, карга чумган машинасының арткы ягы шәйләнә. Менә нидә икән эш! Үзе исән-сау, машинасы да артык зыян күрмәгән, ахры, куркыныч юк; берәрсе туктар да өстерәп чыгарыр. Көчлерәк машина кирәк инде монда. Туктар иде дә, машинасы әллә ни зур түгел, җитмәсә, ашыга... Йөзләгән машина үтә бит, ярар, бу юлы Ходай кичерер, башкалар туктар әле...

...Тораташтай баскан кеше артта калды. Рүзәлнең күңелен әллә нинди хис тырный башлады. Нигә туктамады инде... Үзенең дә бит мондый хәлдә калганы бар. Әле машина йөртергә өйрәнә башлаган гына чагы иде. Кулында машина йөртү хокукын раслаган таныклык бар, ә тәҗрибәсе – юк. Үч иткәндәй, машина белән килешеп бетә алмады ул. Техникага сәләт кемгәдер күкләрдән бирелә, диләр; күрәсең, Рүзәл андый сәләттән мәхрүм инде. Юк кына урында да тәгәрмәче тишелә; яңа булса да, совет машинасының ременьнәре сызгыра, саклагыч лампалары янып чыга. Сукранасукрана, Рүзәл аларны автосервиска барып рәтләтә дә яңадан юлга чыгып китә. Үҗәт. Бервакыт юл уртасында машинасы сүнеп калды. Нәрсә ярамады, ни булды – аңламады. Сукранып кына калмыйча, чыгып, машинаның тәгәрмәчләренә типкәләде, һавада йодрыкларын уйнатып алды. Кеше булса, кыйнап атар иде, валлаһи. Машинага ни – тик тора юл кырында, эһ тә итми. Капотны ачып куеп, кул күтәреп басып торудан башка чара юк иде. Рүзәл шулай эшләде дә. Озак тормады, тәгәрмәчләрен чыелдатып, пошкырып, зур тизлектә тормозга басылганлыктан сикергәләп, янына зур йөк машинасы килеп туктады. Таныш түгел ир-ат белдекле кыяфәттә капот астын тикшерде, клеммаларны актарды, иснәде, капшады, карады, руль артына кереп утырып, ачкычны борыйм дигәндә генә кычкырып көлеп җибәрде.

– Брат, «чәйнүк»ме әллә син? – диде ул, мыскыллы тавыш белән. – Кайчаннан бирле рульдә?

– Кайчаннан дип... Күптән түгел.

Аңышмыйча басып торган Рүзәлнең ачуы чыкты. Әйтерсең кайберәүләр ана карыныннан машина йөртүче булып туа.

– Бензиның беткән, кардәш. Миндә дизель, сиңа салырга ярамый. Әйдә, берәрсен туктатабыз.

Гомерлек сабак булды бу Рүзәлгә. Чит ил машинасына утыруга ук панельдәге бензин бетә башлаганын искәрткән сары утның януын көтмичә, бакны тутырып куя торган булды...

...Менә шул вакыйгалар искә төшеп, күз алдыннан үттеләр дә, уйлары аны яңадан тораташтай басып калган кешегә алып кайттылар. Өстендә дә юка иде бугай инде... Машинага ышанып, калын киенеп утырмый шул хәзер кеше. Ә юлда ни генә булмас. Тукта, бу кеше үзе генә идеме соң? Юк бит! Үтеп киткәндә күрде: карга чумган машинаның бозлы арткы ян тәрәзәсендә тын белән уелган «күзләр» бар иде бит!

«Туктаганнардыр... Башкалар туктаганнардыр...»
Ә туктамасалар?!

Әле ул кадәр ерак китмәде бит Рүзәл. Беренче чатка барып җитте дә, каршы як машиналарны үткәреп җибәреп, кирегә борылды.

...Һаман шул урында, һаман шул хәлдә басып торган кешене күреп, йөрәге сулкылдап куйды.
Әй, кешеләр!.. Бәгырьсезләр.

Борылды, туктады. Тораташ адәм, бу хәлгә ышанып җитмәгәндәй, баскан урынында чайкалып тора бирде. Рүзәл, машинасыннан чыгып, аның янына килде.

– Нәрсә булды, кардәш? Баттыңмы?

Иреннәре зәңгәрләнеп каткан кеше көч-хәл белән калтыравын җиңеп, бер сүз сытып чыгара алды:

– Баттым.

– Әйдә, җылын әле башта. Утыр машинага.

Шул вакыт кюветка очкан машинаның ишеге ачылды, буран сызгыруын күмеп, олы яшьтәге бер апаның ыңгырашулы тавышы ишетелде:

– Сәгыйть! Нишлибез соң инде?!

Сәгыйть дигәне берни дәшми, Рүзәл машинасына кереп утырды.

– Әйдә, апа! Сез дә минем машинага утырыгыз әле, уйлашабыз хәзер.

– Нинди хәерсез көн булды инде бу, – дип сукрана башлады апа, Рүзәл машинасына кереп утыру белән үк. – Әле монысы, әле тегесе дигәндәй, бер-бер артлы чакырып китергәндәй бәла аяк астыннан чыга да тора!

– Юлда төрле хәл була инде, апа, – дип, Рүзәл хатынны тынычландырырга тырышты. – Сез әле юл читенә бик җайлы гына төшеп утыргансыз, ярый бозлавык каршы як юлга чыгарып атмаган.

– Алла саклады инде, улым, Алла саклады! Бер гаиләгә өч мәет күбрәк булыр дигәндер!

PRESSA.RU

Апа, мышык-мышык килеп, борын тарта башлады, күзләрен сөрткәләп алды. Рүзәл, аңышмыйча, янында авызына су капкандай утырган иргә текәлеп карады.

– Нәрсә булды соң?

– Әти үлгән. Иртән. Апа белән күмәргә кайта идек. Ашыктым шул.

Рүзәл сискәнеп китте. Яңа ел киче бит бу! Ничек инде алай...

Апа белән аны-моны сөйләшкән арада, ниһаять, иргә дә җан керә башлады. Бүрегендәге кар, эреп, куе кара кашларына, керфек очларына кагылып үтте, суыктан җылыга кергәч, кып-кызыл булган бит алмаларына тамды, иягенә кадәр юл сызып агып төште.

– Әйттем дә бит Сәгыйтькә, иртәгә иртән кайтырбыз, мәет янында кеше бар, кичкә каршы юлга чыкмыйк дидем... Тыңламады! Менә шулай була ул!

– Ярар. Зыянлы түгел. Хәзер сөйрәп чыгарырбыз.

Ир-ат башын чайкады.

– Булмый. Күчәр сынган.

Алай икән. Димәк, эш катлаулырак, машина йөрерлек хәлдә түгел.

– Эвакуатор чакырырга кирәк.

– Чакырдым. Өч сәгать көтәм.

– Өч сәгать?! Беркем дә туктамадымы?!

– Туктадылар да китеп бардылар. Яңа ел бит! Ашыгалар. ГИБДДга шалтыраттым. Алары килми.

– Ник?

– Зыян күрүчеләр юк, диләр. КАСКОм юк.

– Казангамы соң сез?

– Юк. Яшел Үзәнгә.

Бу – Казанның икенче ягы иде. Рүзәл шәһәргә башка яктан керә. Ярар, Казанга кадәр алып та кайтыр. Әмма аннан соң... Ихтыярсыз, Рүзәл артта яткан кара күн портфеленә күз ташлады. Соңга кала бит!

– Тәк... Эвакуаторны көтәргә кирәк. Шунсыз булмый.

Кинәт ир кеше, Рүзәлгә якынрак авышып, колагына гына әйткәндәй пышылдады:

– Кардәш, ташлама. Хәлем шәп түгел. Бәрелдем. Кара.

Күзләре белән апасына ымлады, «Дәшмә!» дигәндәй хәрәкәт ясады да, бүреген артка шудырды. Кып-кызылга манчылган кулъяулык күренде. Борынына кинәт китереп бәргән кан исеннән Рүзәлнең күңеле болганды, күзләре шар булды.

– Сез нәрсә! – диде ул, куркынып. Үзе дә сизмәстән, тавышы күтәрелде. – «Ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк!

– Мин дә шулай дим! – Апа кеше Рүзәлнең сүзләрен ишетеп, җанланып китте. – «Бәрелдек, кеше үләргә ята» дисәң, хәзер килеп җитәләр бит алар, болай интекмәс идек! Килгәч, ачуланмаслар иде әле, бәлки, ул аңын югалткан булгандыр, ә мин үлгән дип уйлаганмындыр. Өч сәгать юлда басып тормас идең! Инде менә кирәкмәгәннәргә шалтыратып, телефонның зарядкасы бетте!

Апа кеше энесенең башы бәрелгәнен белми иде. Күрәсең, шулай кирәктер, Сәгыйть дөрес эшли. Чәүчәләккә охшаган апасы.

Сәгыйть, ник әйткәненә үкенгәндәй, шунда ук бүреген батырып киеп куйды.

– Җәрәхәтләндем, – диде ул авыз эченнән, Рүзәл ишетерлек итеп. – Түзәрлек, ярар!

Рүзәлнең күңелендә давыл уйный башлады. Урыслар «Не делай добра» дип белми әйтми шул. Нишләргә соң инде хәзер?! «Төшегез, мин сезгә ярдәм итә алмыйм, үзем ашыгам» дип, боларны машинадан куып төшерсенме? Сәгыйтьнең яралы икәнен күрәләтә белеп?

Бер генә юл: машиналарын шушы хәлдә калдырып, юлчыларны Казанга алып кайту. Рүзәлнең уйларын аңлаган кебек, ир-ат кистереп әйтеп куйды:

– Машинаны монда калдыра алмыйм. Үземнеке түгел.

– Тегеләй дә булмый, болай да – нишлибез соң инде? Миңа Казанга кайтырга кирәк! – Рүзәлнең түземе соңгы чиккә җитте.

– Ярар, кардәш, җылындык, рәхмәт! Син үз юлыңда бул инде. Әйдә, апа, чыгабыз!

– Тукта! Туктагыз.

Рүзәл үз-үзен аңламады. Нәрсәдер, ниндидер аңлашылмаган бер хис аны бу бәлагә тарган юлчылар янында тота иде.

– Әйдәгез, яңадан эвакуатор хезмәтенә шалтыратып карыйк әле. Берсе килмәсә, башкасы килергә тиеш бит инде аларның!

Рүзәл шактый вакыт бер номердан икенчесенә күчеп, сөйләште, әрләште, кычкырышты. «Көтегез, килә!» диделәр.

Ул сөйләшкән арада, чыннан да, төн караңгылыгын ертып, артка зур гына машина килеп туктады, фараларының яктысы юлчыларның күзләрен камаштырды. Сәгыйть кычкырып ук җибәрде:

– Килде! Әйтәм бит, килә ул дип. Эвакуатор килде!

Юк, хәтта эвакуатор килгәч тә, Рүзәл боларны тиз генә калдырып китә алмады. Казанда көтеп утыручы бухгалтер хатын йөз шалтыратты, аңа да «Озакламый, хәзер, кайтам» диюдән башка сүз әйтә алмады. Ахырдан ул да шалтыратудан туктады. Машинаны күтәрделәр, беркеттеләр, әмма эвакуатор кабинасында апа белән энегә урын юк иде. Рүзәл, юл кырыена басып, башка машиналарны туктатып карады, әмма беркем дә Яңа ел кичендә ташбакадай сөйрәлеп эвакуатор артыннан кайтырга ризалашмады. Рүзәл эчтән кара янды, көйде, сүгенде, әмма барыбер бу ике бичараны юлда ташлап китә алмады. Хәер, хәзер ничек кенә кызу кайтса да, вакытында кайтып өлгермәячәк иде. Кремль курантлары сукканчы өенә кайтып керсә, әйбәт. Ярый әле, хатыны аңлый торган, кычкырынмас, ә менә нәчәлниге...

...Ярты юлда кисәктән генә телефон тавышын сизде Рүзәл. Ишетмәде – сизде. Кулына алып, номерга күз салса – фирма башлыгы.

– Акчаны күчердеңме?!

Башлыкның тавышы яман иде. Яшелле-күкле. Исәнме-саумы юк. Мәктәптә укыганда, география



Рәсем: Наталья Васильева

укытучысы шундый тавыш белән кычкыра иде. Рүзәл калтырап төшкәнен хәтерли.

– Эээ... Ни бит, Рөстәм Әхәтович...

– Күчердеңме?!

– Буран әле монда...

– Күчердеңме, юкмы?!

Тозлы-борычлы сүгенүне ишеткәч, Рүзәл тынычланыбрак киткәндәй булды.

– Юк. Өлгермәдем.

Трубканың теге башында тынлык урнашты. Аннан башлыкның җиңел сулап куйганы ишетелде, шаркылдап көлде.

– Ай, Рүзәл, ай, ташбака! Юкка сиңа кушмаганмын икән! Молодец! Син килешү төзегән фирма бүгеннән банкрот! Менә шул! Давай, переваривай. Бизнес бу!

Рүзәл бераз вакыт аңышмый торды. Димәк, әгәр ул бүген акчаны күчергән булса... Яңа елдан соң товар килмәячәк! Егерме миллион фирма акчасы... Рүзәл исәбендә йөргән егерме миллион... яначак идеме?!.

– Аңладыңмы? Син юлдамы әллә һаман? Ярар, исән-сау кайтып җит, еллардан соң премия язармын. Яңа ел белән, коллега!..

Рүзәл тынсыз-сүзсез калды.

Йомшак шул ул, күңеле белән йомшак... Юкка гына аннан хатыны «Синнән нинди эшмәкәр чыксын инде, җаным, сиңа песи докторы буласы калган» дип көлми. Әллә шундый йомшак булганга, бу юлы Аллаһ саклады микән үзен?! Егерме миллион сумны түләтә калсалар, чыдамас, кешелектән чыгар диде микән?!

...Бераздан уң якта, җемелдәп, автосервис язулары күренде. Эвакуатор Сәгыйтьнең машинасын шунда калдырасы иде.

– Алиякәем-алмакаем! Пилмән салдыңмы? Хәзер кайтып җитәм, бәгырем, ачуланма! Үзем генә түгел, ике кунак алып кайтам! Кемнәр? Фәрештәләр, җаным, ике фәрештә алып кайтам!

...Төнгелеккә буран тынды. Күк йөзе, Кыш бабайның кызыл бияләе белән сөртеп алгандай, чип-чиста булып калды. Ялтырап йолдызлар күренде. Йорт янына килеп җитәрәк, Рүзәл кунакларын алга җибәрде дә, күтәрелеп, төнге күккә карады. Әллә күзләре камашты шунда, әллә чыннан да могҗиза булды – төнге күктә бер төркем йолдызлар, «Не делай добра» сүзләрен сызып атып, әбисенең «Яхшылык җирдә ятмый, улым» дигәнен язып маташалар иде...

PRESSA.RU



БАШЛАРЫМ ӘЙЛӘНСЕН СӨЮДӘН...

Эльмира ЖӘЛИЛОВА

Бу җыр язылырга тиеш булгандыр. Минем җанны нидер дертләткән өчен дә. Бу халәт күпләрнең күңелендә аваздашлык табып, җаннарында яз булып калсын өчен дә! Ә җырның язылу тарихы әллә кайларга барып тоташа икән...

Мин вакыт-вакыт «Ирек мәйданы» газетасы өчен үземә кызык шәхесләр белән әңгәмәләр оештыра идем. Газетаның редакторы, дустым Раиф Усманов: «Эльмира, никтер Рөстәм Закиров сәхнәдә күптән күренми, беркемгә дә әңгәмә бирергә дә ризалашмый, дәшеп кара әле, син сөйләштерә алмассың микән?!» – дип шалтыратты берничә ел элек. Рөстәм ризалашты. Татар җыр сәнгате, үткәне,

Җанымда яз булып кал әле

Бер ярсу биләде җанымны,
Бу ярсу давылдан көчлерәк.
Ничә ел яшәп тә сөюне
Белмәгән икән бит бу йөрәк.

Кушымта:
Утка сал, суга сал син мине,
Үзең дә бер дөрләп ян әле.
Үземә булмасаң булмассың –
Җанымда яз булып кал әле.

Башларым әйләнсен сөюдән –
Син мине бәхетле ит әле.
Янымда калмасаң калмассың,
Яндырып булса да кит әле!

Син мине яшәрттең,
яшьнәттең,
Теләмим ярсуның тынганын.
Күрмәсәм мин сине дөньядан
Яратмый китәсе булганмын.

бүгенгесе турында әллә дүрт сәгатьләп сөйләштек инде без аның белән. «Ник югалдың?!» – дип соравыма: «Берни дә яндырмый башлады», – диде. «Менә син берәр җыр язсаң икән ул!» – дип тә өстәде. Шаярып кына мин – җыр язарга, ә ул, 10 еллык тәнәфестән соң, кабат үз концертын оештырырга сүз куешып, саубуллаштык. Чын, ихлас борчылдым мин аның өчен – чөнки татар эстрадасында иң яраткан җырчым иде дисәм, һич дөреслеккә хилафлык килмәс. Таланты, тавышы булганнарның сәхнәдән югалуын да, сәхнәдә килеш үз-үзләрен җуюларын да авыр кичерәм...

Шуңа, биргән вәгъдәмдә торып, язып карарга булдым. Дөресрәге, ул үзе җаннан мөлдерәп түгелде. Шундук Фирзәр абый Мортазинга шалтыраттым. «Шушы сүзләргә җыр языйк та, Рөстәм Закиров җырласын әле!» – дим. «Ник Рөстәм үзе дәшәлмиме әллә?!» – дип шаяртты бугай Фирзәр абый. Рөстәм озак уйлый. Минем көтәргә чик-чамам юк. Миңа менә бүген, хәзер... ә иң яхшысы – кичә кирәк!.. Каударлану тавышка чыккан булгандырмы, Фирзәр абый Мортазин ике-өч көн эчендә язды ул җырны. Рөстәм, тота-каба, Буага җыр алырга барган шәптән үк Апаска аранжировка эшләтергә китеп барды. Юлдан: «Кара, бер дә болай кыланган юк иде бит минем!» – дип шалтыраткач: «Минем каударлык йоккандыр!» – дип көлдем бугай.

Җырны беренче тыңлаганда ук нидер булды миңа. Тыңлый гына башлыйм, бетә дә китә. Кече телгә дә йокмый – җитми кала. Димәк, тансык. Димәк, начар булмаган. «Соңгы 15 елда иң яратып иҗат ителгән җырым», – дип башкарды аны Рөстәм Закиров. Яратып язылды. Яратып җырланды. Бу кадәр ярату салынган җыр тыңлаучыга барып җитми калалмый иде.

Рөстәм Закиров та вәгъдә ителгән концертын оештырды – һәм ул концерт «Җанымда яз булып кал әле» дип аталды.

Аннары никтер шушы җырга клип төшерү нияте белән яна башлады Рөстәм. «Ничек күрәсең?!» – дип сорады ул миннән. Мин, шоу-бизнеста, клип ясау серләрендә әлифне таяк дип тә белмәгән кеше, сценарий язып карарга булдым. Нindидер уйдырмалар уясым килми иде, тормышчан, ихлас булып күзалланды бу клип. Сценарий әзер булгач, «Төп героиняны үзең уйнасаң?!» дигәненә аптырап калдым. Камерадан уттан курыккандай куркуымны һәм шул ук вакытта гомерем буе берәр роль уйнап карыйсым килеп яшәвемне яшерү дә, шәрран яру да уңайсыз иде... Язылды. Уйналды. Ничек бар шулай. Беренче коймак төерсез була алмый иде... Тик бу тәҗрибә мине күп нәрсәгә өйрәтте. Кемнәрдер «синең урынга башка кеше уйнаса отышлырак булыр иде!» диде. Бәлки?!. Тик миңа «ярый үзең уйнагансың әле!» диючеләр якынрак иде. Юк, төче сүз ишетәсе килгәннән түгел, минем бөтен кимчелекләрем белән дә кабул итүче үз кешеләрем булуларын аңлаудан!.. «Кабатлар идеңме?!» – дип сорыйлар. Һичбер икеләнүсез – әгәр шулкадәр җаныма якын җыр языла икән, кабат сценарий язып, үзем уйнап карар идем! Тик җыр язу гына кыен хәзер нишләптер. Кайчандыр үзе җыр язып карамаган берәүдән: «Һәй, җыр ул шулкадәр примитив нәрсә, мин андый гади текст язып та азапланмыйм!» – дигәнрәк (сүзен сүзгә хәтерләмим инде) фикер ишетергә туры килде. Һәркем үз фикерен әйтергә хаклы, билгеле... Әмма җыр язып караган кеше буларак, аның бик четерекле эш икәнен искәртер идем. Шигырь – ул тулаем продукт! Синеке генә! Ә җыр – ул композитор, җырчы һәм сүзләр авторының уртак хезмәте. Монда әле тәңгәл килү дигән катлаулы өлеше бар!.. Сүзләрнең яңгырашлы булуы, көйнең җанга үтеп керүе – һәм боларның барысының да үз җырчысына туры килүе.

Җыр бәхете формуласын уйлап утырам бүген: ул ике авторның «җеннәре туры килү»дәдер, мөгаен. Ул җырчының җырда яшәвендәдер. Мин бит шигырьләрдә һәрчак кайнап чыгып түгеләм. Шуңа формуланы болай язып карыйм әле: авыл мичендә кетердәп пешкән кайнар ипигә (җыр сүзләре) әле генә аертылган бал тәмнәре килеп торган авыл каймагы (көе) яксаааааң!.. Һәм дөньядагы иң тәмле ризык икәненә инанып, күзләрен йомып, кетердәтә-кетердәтә урамга күтәреп чыгучы (җырчы) булса, якын-тирәдәгеләрнең аның тәмлелегендә шиге калмыйдыр шикелле!..

Яратып тыңлаганнардан: «Җырның башы, дәвамы, ахыры бар – шуңа тулаем бер тарих буларак кабул ителә», – дигән фикер ишеткәнем бар. Шулайдыр. Мөгаен...

PRESSA.RU



Фото: Газинур Хафизов

ӨЧ «МИНУС» ҺӘМ УТЫЗ «ПЛЮС»



Лилия ГӘРӘЕВА

ӘЛЕ ГЕНӘ АК КҮЛМӘКЛӘР КИЕП, ГӨЛЛӘРГӘ КҮМЕЛГӘН АК МАШИНАЛАРДА КИЛЕН БУЛЫП ТӨШКӘН ИДЕК, ИНДЕ МЕНӘ ҮЗ КЫЗЛАРЫБЫЗ КӘЛӘШ БУЛЫР ЯШЬКӘ ҖИТЕП КИЛӘ ИКӘН. КАЙЧАН МОНЫҢ КАДӘР ЯШӘДЕК СОҢ ӘЛЕ, ДИЯРСЕҢ.

Бергә укыган дустымның кызы узган ел кияүгә чыкты. Мең үлеп, мең терелде ул. «Матур гына яшәп китә алырлармы? Кызым бәхетле булырмы? Кайнана-кайнатасы какмасмы?» – күңелен мең төрле уй телде. Бигрәк тә яшь шул әле кызы. Кияү дә яшь. Икесенең берсенә егерме тулмаган.

«Йөргәндә кызларның барысы да әйбәт, каян килә явыз хатыннар?» – дип аптыраган ди берәү. Икесе ике төрле тәрбия алган икәүгә бергә яшәп китүе җайлы гына түгел, билгеле. Шуңа да гаиләләрнең күбесе беренче елны ук аерылыша да икән. Аерылышуның сәбәбен холыклар туры килмәүгә сылтасалар да, нигездә, төп сәбәп холыкта түгел, уртак гаилә бюджетын оештыра, вакытны бергә уздыра белмәүдә, дип таба психологлар. Бер-береңнән артык күпне таләп итүдә, әллә нәрсәләр көтүдәдер дим мин, егерме еллык никах тәҗрибәмнән чыгып. Сабырлык та җитеп бетмидер инде...

Дустымның кызы кебек, без дә бик иртә өйләнештек. Икебезнең беребез ныгытып аягына басмаган, мин – студент, иремнең дә яңа гына армиядән кайткан чагы. Торыр урыныбыз да, рәхәтләнеп тотарга акчабыз да юк. Ишегалдында очрашып, сөйләшеп утырабыз да, ул – апаларына, мин әни янына кайтып китәм. Аерым бүлмә табып, бергә яши башлагач та, тормышыбыз алай тиз генә җайлашып китмәде әле безнең. Бер-беребезне аңлап, кайчак юл куеп, кайчак дәшми калып яши башлаганчы, шактый талкындык. Ул вакытта мин бөтен гаепне иремнән күрдем, билгеле. Менә ул дөрес эшләми, менә ул игътибарсыз, менә ул... Чәчәк күтәреп кайтканмы – акчаны суга салган, торт алганмы – юри котыртыр өчен, белә бит инде баллыны яратмаганымны! Хәзер инде хәтерләмим, тормышның кай мизгелендә, кайсы борылышында гаепнең үземдә дә булуын абайладым икән?

Бүгенге яшьләр безгә караганда акыллырак. Без ясаган хаталарны ясамаслар, дисәм... яшь гаиләдә дә беренче проблемалар озак көттермәде. Кияү, эштән соң өйгә кайтмыйча, дуслары белән очрашып йөрүне гадәт иткән икән. Дустымның кызы, күз яшьләренә чыланып, ярсып, ярты төнгәчә аны өйдә көтсә, монда әнисенең йөрәге телгәләнә...

Аһ, ничек таныш бу хәл миңа. Шуның аркасында күпме низаг, ызгыш, күз яшьләре иде бездә дә. Ә ник аның өйгә кайтасы килми соң, дип уйлый, нәтиҗә ясый белмәгәнмен ул вакытта. Өйдә мыжгак хатын көтеп, эштән кайткан кешегә тынычлап ял итәргә ирек бирмичә, тегендә-монда әйдәкләсә, ирнең өйгә кайтасы килмәвенә гаҗәпләнәсе түгел. Гаилә тормышында иң беренче өйрәнгән сабагым шул булган иде минем – ир кешенең өйгә кайтасы гына килеп торырга тиеш, һәм бу «кайтасы килеп тору» өчен хатын-кыз үзе җаваплы.

Өстәвенә, дустым үзе дә, еш кына барып, кызы белән кияве тормыш итәргә өйрәтеп кайткалый. «Берүк кысыла күрмә! – дим аңа. – Кызыңны каһәрләми, ормый-сукмый, җайланырлар».

Күбебезгә хас нәрсә бит бу – безгә үзебез генә дөрес яшибездер кебек тоела. Тормыш барган саен, тәҗрибә арта, һәм башкаларның «кыек» урыннарын шундук эләктереп алырга торасың. Киявенең эштән соң ял итүе – ялкаулык, яшьләрнең кинога-мазарга барулары исраф булып тоела аңа. Кияүнең кимчелекләрен ачып күрсәткәннән генә яшь гаиләгә ишелеп бәхет килсә иде дә бит. Киресенчә, үзенең яшьлеге аркасында ирендәге күп кенә җитешсезлекләрне күрмәве белән кызы бәхетлерәк тә. Дөньяда кимчелексез кеше юк.

Ир-ат артык мәшәкать яратмый. Проблемалардан качарга тырыша. Ә без, хатын-кызлар, мәшәкать тудырырга бик оста. Обойларны да яңартасы килә безнең, җиһазлар да ялыктыра башлый.

«Бернәрсә кирәкми икән бу кешегә!» – ди беркөн дустым, кабат кияве хакында сүз кузгатып. Баксаң, кемдер үзләреннән арткан шкафларын биргән дә, кияү шуны урнаштырып куя алмый.

Быелның ун аенда Татарстанда 23 436 пар кушылган, 11 319 пар аерылышкан.

Бездә дә булды ул андый хәл. Фатирга ремонт ясагач, җиһазларны яңартасы иттек. Искеләрен дә чыгарып ыргытырга кызганыч. «Менә бу кечкенә шкафны шушы аралыкка элеп бир әле, – дим иремә. – Артык-портыкны куярга бик уңай булачак». Әмма шкаф чак кына зуррак булып чыкты. Алай да бирешәсе килми: аны бер-ике сантиметрга тарайтсаң, кереп кенә утырачак бит инде (җайлы гына тарайтырга әйтерсең лә чалбар балагы!). Бу шкаф шулай сүтелгән килеш безнең йокы бүлмәсендә шактый торды. Урыны бик уңай, беркемгә дә комачауламый. Ә минем уемда ул бит инде күптән теге аралыкта эленеп тора, мин инде анда бөтен чүкечләрне, борау, кадак, шөрепләрне таслап тутырып та куйдым. Авылга кайткач, иремнең әнисенә зарландым, малаең сүземне тыңламый, шкафны элми. «Аяк астынарак, йөргәндә комачаулый торган урынга чыгарып куй син аны. Үтеп киткән саен ишелеп төшә башласа, элми булдыралмас». Әнинең киңәше ярады, шкаф мин теләгән җирдә эленеп тора хәзер. Дустыма шушы хәлне сөйләгәч: «Кызыма әйтәсе булыр, алгы якка чыгарып куйсын әле шуны», – дигән иде, сораганым юк, хәйләнең файдасы тиде микән?

Ишек алыштырдык берсендә, ә ишек яңагын сылап куярга кулы җитми иремнең. Эшләсә, ул аны бер дигән итеп эшләячәк, әлегә, үзе әйтмешли, илһамы килми тора. «Кайчан килә инде ул илһам, бәлки, бер елдан да килмәс. Шушы ишек аркасында мин балага табиб чакыртырга да оялам», – дип, тагын әнигә зарланып ташладым. «Икегез дә өйдә булганда, син аны үзең сылый башла. Эчендә җаны булган кеше түзмәс, килеп кушылыр». «Якшәмбе операциясе»нә бик тырышып әзерләндем. Ирем яраткан кыска итәгемне, матур

PRESSA.RU

кофтамны киеп куйдым, хушбуй сибендем... Аннары измә изәргә буш табак хәстәрләп, ишек катына цемент капчыгын сөйрәп китердем. Нишләвең бу, дип, телевизор карап яткан җиреннән ирем дә торып чыкты. «Ишек яңагын сылыйм!» – дидем дә, әйбәтләп торып бер уч измәне чәпәдем. Ул, билгеле, ишек яңагына түгел, чак кына кырыйгарак, әле генә алыштырган ишеккә чапылдап барып төште. Ирем, авыр сулап, кулымнан мастерогымны алды... мин исә кухняга, берәр тәмле әйбер пешерергә кереп киттем. Эшләгән кешене ничек сыйламыйсың!

Ирләрнең күбесе кибеттән яки базардан әйбер сайлап йөрергә яратмый. Әмма хатын-кыз берүзе генә ничек барысын да җайлап бетерсен?! Берәр ял көнендә базарга чыгып, биш-алты кило ит алып кайту нәрсә инде ул ир кеше өчен? Оят булса да әйтим, шушы яшемә җитеп тә базардан ит сайлый белмим мин. Йә каты булып чыга ул, йә бөтен сөяген тутырып кайтаралар. «Икәү барыйк әле, – дим иремә. – Син әйбәт итне аера беләсең». «Юмаларга оста да инде үзең», – ди ул, әмма сүземне кире какмый. Ә икенче юлы базарга мин аның үзен генә җибәрәчәкмен: «Теге юлы син алганы шундый шәп булган иде!» – диячәкмен. Хәтта алай артык шәп булмаса да.

Артык яшьли өйләнешү – йөзә белмәгән килеш ярсу диңгезгә ташлану белән бер ул.

«Ирең молодец! Кайтканыңны көтеп ятмый, ашарга әзерли тора», – ди хезмәттәшләрем. Ул яктан, Аллага шөкер, өйгә кем беренче кайта, ашарга шул пешерә бездә. Кайчандыр: «Менә анысы булмас инде!» – дигән кеше бит ул. Өйләнешкән елларда без коммуналь фатирларда яшәдек. Күршеләребез – Анна апа белән Геннадий абый, Нина белән Анатолий да кухняда гел бергә кайнашалар иде. Бергә өчпочмак ясыйлар, бергә кыяр тозлыйлар. Без бит авыл балалары. Авылда ир-атка, ашарга пешереп йөрмәсә дә, эш җитәрлек. Ә шәһәр фатирында ир кеше генә эшләрдәй эш алай еш чыгып тормый, монысы – синеке, монысы – минеке, дип, кискен бүлеп куярга нигез юк. Күршеләрдән күрмәкче, без дә ирем белән ашау-эчүне бергә әзерләргә күнектек. Икәү эшләгәч, тиз була, бергә булырга вакыт та күбрәк кала.

Ир кеше тәнкыйтьне авыр кичерә. Бигрәк тә ул тәнкыйть хатын-кыз тарафыннан булса. Кайсыдыр бер бәйрәмгә ирем зур чәчәк бәйләме күтәреп кайтты. Сөенеп, рәхмәт әйтеп алып кына куй бит инде шуны. Ә мин аны битәрләдем, имеш, акчаны юк нәрсәгә сарыф иткәнсең, өч көннән бу чәчәкләр чүплектә булачак. Ә ул шундый бәхетле, күзләреннән шатлык бөркелә иде. Минем ризасызлыгым ул шатлыкны мизгел эчендә юып төшерде. «Ярар, моннан соң бер генә чәчәк тә бүләк итмәм», – дигән иде ул. Әлбәттә, ахырдан бу вәгъдәсен онытты. Мин исә мәңгелек сабак алдым: кеше сине шатландырам дип, нәрсә дә булса сатып алган икән, күңелен төшермә.

Менә хәзер, егерме ел бергә гомер иткәннән соң, кайтып-кайтып, еллар йомгагын кире сүтәм дә, нинди ахмак хаталар ясалган, дип, шаклар катам. Хәер, хаталар әле бүген дә ясала. Әмма мин инде ачуымны нәкъ менә шушы минутта ук әйтмәячәкмен, моның өчен уңайлы вакыт көтәчәкмен. Ирем дуслары белән тоткарланасы булса, хәзер бу да гаиләгә хыянәт буларак кабул ителми. Аның дуслары белән күрешергә хакы бар лабаса. Әмма... көн саен түгел.

Мине әни ялгызы үстерде, аңымда ирле тормышның төгәл генә моделе юк иде. Баштагы елларда ир-атны аңлавы, аңа яраклашуы шуңа да авыр булгандыр, мөгаен. Аннары без әдәби әсәрләрдәге хыялый саф хисләр белән «агуланган». Ир кешедән туктаусыз игътибар, кайгырту, романтика көтәбез. Булмаса – үпкәлибез, яратмый, дибез. Менә үкенсен инде хәзер, дип, акылыбыз ирнең «терсәген тешләтер» җай эзли.

Аллаһы Тәгалә иң элек Адәмне яралта. Аннары аның күңелен күрер өчен – Хаваны. Хакыйкатьтә дә шулай бит, без никадәр генә телик-теләмик ир-ат түгел, хатын-кыз көйли, җайлый, үгетли...

Никах җепләре өзелергә җитеп тартылган бер мизгелдә киңәш сорап психологка барганым хәтердә. «Ирегезнең «плюс»ларын һәм «минус»ларын санап чыгыгыз», – дип, буш бит сузды ул миңа. Бик озак уйлап утырып та, иремнең нибары өч «плюсын» таба алган идем. Ә «минус»лары-ы-ы! «Әйдәгез, бу утыз «минус»ны «плюс»ка әйләндерик. Пешергән ашыгыз өчен ирегез рәхмәт әйтәме? Әйтсә, без моны «плюс» дип куйыйк. Димәк, ул сезнең тырышлыкны бәяли. «Кайтышлый ипи белән сөт ал әле», – дисәң, сүзегезне тыңлыймы? Моны да «плюс»ка язабыз, чөнки гаиләсе өчен эшли». Берәм-берәм тикшерә торгач, иремнең уңай яклары шактый чыкты. Психологның юк кына әйберләрне дә зур итеп, уңай сыйфат дип бәяләве мине гаҗәпләндергән иде. Аның яныннан чыкканда мин инде иремне бөтенләй башка кеше итеп – кайгыртучан, эш сөючән, уңган-булган итеп күрә идем. Без бит бер-беребезнең яхшы якларын күп очракта күрмибез дә, моны үзеннән-үзе тиеш, гадәти әйбер дип кабул итәбез, ә менә энә очы кадәр «минус»ы бик зур булып күренә. Шунда психолог ханым минем өчен бик әһәмиятле бер сүз әйтте: «Кемнең дә булса үзебезгә мөнәсәбәтен үзгәрергә теләсәк, без иң элек аңа үз мөнәсәбәтебезне үзгәртергә тиеш. Әгәр дә хатын-кыз, ирем яхшы, кайгыртучан, дип уйлый, аның юк кына ярдәмен дә зур итеп кабул итә, бәяли икән, ир кеше үзе дә бу хатынга карата кайгыртучанрак, игътибарлырак булачак». Шушы ук сүзләрне безгә Аллаһы Тәгалә дә җиткерә бит: «Үз хәлегезне үзегез үзгәртми торып, без сезнең хәлегезне үзгәртмәбез», – ди (13 нче сүрә, 11 нче аять).

Ә сез әле гаепне кемнән күрәсез: ирегездәнме, үзегездәнме?



Татьяна ЛЕОНТЬЕВА –
Татарстан Иҗтимагый палатасының социаль сәясәт һәм хәйриячелек эшчәнлеге комиссиясе рәисе, «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» генераль директоры, психолог, медиатор.

Яшь гаиләләр белән эшләгәндә, бер-берләрен ярата торып та аерылышырга килгән яшь парларны күп очратырга туры килә. Бер миндә генә түгел, коллегаларымда да күп андый тарихлар. Гаиләнең бәхете өчен ярату гына җитми шул. Нәрсә генә дисәң дә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре олы хезмәт ул. Нинди генә кызыклы кешеләр булсалар да, гаилә мөнәсәбәтләре коруның үз кагыйдәләре бар. Әгәр дә ул кагыйдәләргә буйсынмасаң, бәхетле гаилә булып яши алуы бик икеле.

Безгә мөрәҗәгать иткән яшь гаиләләр белән сөйләшә башлаганчы, мин аларны баштан ук кисәтеп куям: сезгә сәер сораулар бирермен, әмма ник биргәнемне соңыннан аңлатырмын, дим. Мондыйрак сораулар алар: гаилә бюджетыгызны ничегрәк оештырасыз һәм ялларыгыз ничек уза?

Ник шушы ике сорау кызыксындырганын укучыларга аңлатып китим. Гаилә бюджеты бер түбә астында яшәүчеләрнең иң мөһим һәм бигүк мөһим булмаган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәк. Бу – стратегик запас. Әлеге запасны кем саклый һәм кем бүлә? Гаиләнең акча запасы кем кулында – җаваплылык һәм хакимлек тә шул кешедә була. Сездә бу хакимлек ничек итеп бүленгән?

Еш кына шулай була: яшьләр әле үзләре акча эшли башлап, матди бәйсезлеккә ирешкәнче үк өйләнешә. Бер гаилә булып яши башлагач та аларның уртак акча янчыгы булмый. Кибеткә барасылар булса, акчаны икесе дә уртаклап түли. Бераз акча җыеп кую дигән нәрсә юк, зуррак әйберләрне кредитка алалар. Мондый яшәү рәвеше гаиләне ныгыта алмый. Психолог янына да алар бөтен өметләре җимерелеп, бер-берсенә ышанычлары беткәч килә. «Мин иремә яки хатыныма ышана алмыйм икән», – ди алар.

Мәсәлән, берсендә яшь гаилә килде. Бергә яши башлаганнарына өч ел, бер балалары бар. Бала туганчы хатын фатирында яшәгәннәр. Ир кешенең бизнесы булса да, әлегә зур табыш китерми, бар булган акчасын аны киңәйтүгә тота, шуңа да иркенләп тотарлык акчасы юк. Ир кеше хәтта хатынын бала табу йортыннан да каршылый алмаган, эше белән мәшәкатьләр килеп чыккан. Ул чакта һәркем үз акчасына яшәгән. Бала тугач, гаиләне ир кеше генә тәэмин итәсе булып калган. Әмма акча да, уртак гаилә бюджетын оештыру тәҗрибәсе дә юк. Хатын баласы белән әти-әниләренә кайтып, алар хисабына яши. Ирдән дә үз әнисе янына кайтып яшәвен сорый, фатирга кеше кертеп, балага да, үзенә дә бераз акча эшләргә уйлый. Ир исә аның бу тәкъдименә хурлана, бала өчен күпме кирәк дип табам, ай саен шуның кадәр акча биреп торам, ди ул. Хатыны өчен акча тотмый, фатирдан кергән акчасына яшәсен, ди. Алар икесе дә финанс мәсьәләләрен аерым-аерым чишәргә күнеккән. Хәзер хатын кабат үз фатирына кайтып, эшкә чыгарга, иреннән аерылырга уйлый. Сөйләшүдән ачыкланганча, икесе дә бер-берсенең элеккеге карарын гаиләгә хыянәт дип кабул итә. Психолог буларак шуны әйтә алам: гаиләнең уртак бюджеты юк икән, димәк, ир белән хатын бер-берсенә ышанмый.

Икенче соравым: буш вакытыгызны ничек уздырасыз?

Яшь парларның ялларын ничек итеп уздырулары турында сораганда мине буш вакытларын ничек уздырулары турында килешә алу-алмаулары кызысындыра. Буш вакытның үзең генә, икең бергә, башкалар белән бергә уздыра торганы була. Гаиләдә бу чикләр ничек билгеләнгән? Кешеләр бер-берсенә якынрак булган саен, саграк булырга тиешләр.

Әле шундый бер миф та бар. Имеш, яраткан кешеңне тәүлегенә 24 сәгать буе күреп торсаң да туймыйсың һәм бөтен эшне дә бергә эшләгәннән тәм табасың. Әгәр дә мин андый булмасам? Кайвакыт минем үзем генә каласым яки дус кызым белән икәүдән-икәү генә серләшәсем килсә? Алайса, мин иремне яратмыйм булып чыгамы? Болай уйлаган кеше үзенең ихтыяҗларын күрсәтергә ояла. Әгәр теләгемне белдерсәм, ирем (хатыным) минем яратуыма шикләнер, дип уйлый. Һәм шушының белән бәйле кыенлык килеп чыга, кешенең бит дуслары белән дә очрашасы килә, ялгызы гына да ял итәргә тели.

Яшь гаиләләр белән аралаша башлагач, «гел бездә генә яткан» әни, кайтып китә белмәүче «синең» дусларың, гел күз алдында буталган ир яки хатын каршылыгы килеп чыга.

Күпчелек гаиләләрдәге низагның асылында яткан шушы төп ике теманы әйтеп күрсәткәч, яшьләр җиңел сулап куя, аларга инде үзләрен борчыган нәрсәләр турында сөйләве, ихтыяҗларын белдерүе җиңелрәк була. Алар бер-берләренә үз ихтыяҗларын, нәкъ менә икәү бергә тормышка ашырырга хыялланган теләкләрен, ниятләрен әйтергә өйрәнә. Бу инде савыга башлауга тиң. Мәхәббәт үзе әле исән булса...

Аерылышу чигенә килеп җиткән гаиләләр, соңгы адымны атлаганчы, безгә килсеннәр иде. Без аларга ярдәм итәргә әзер. Татарстан ЗАГС Идарәсе, Татарстанның Җәмәгать хөкемдарлары хезмәте белән берлектә, «Яшь гаиләләргә психологик ярдәм» оештырды. Кабул итү бушлай. Сорауларыгыз булса, сайтыбыз аша да мөрәҗәгать итәргә мөмкин: http://zags.tatarstan.ru/ Япон халкы нәрсә ди әле: «Бер-берсен яраткан ике йөрәк тимерне дә эретә», – диме?!

PRESSA.RU

ЯЛГЫШУЛАР – УРМАН...



Фото: Газинур Хафизов

– ЯЛГЫШТЫМ... ЯШЬЛЕГЕМ БЕЛӘН ЯЛГЫШТЫМ. ШУҢА ДА ЯШЬЛЕК – ЮЛӘРЛЕК ДИЛӘРДЕР ИНДЕ. 18-19 ЯШЬТӘ БӨТЕН КЕШЕ ДӘ УЙЛАМЫЙЧА МИНЕМ КЕБЕК МОНДЫЙ АДЫМ ЯСАМЫЙ. Ә МИН...

Ул бу сүзләрне үкенүләрсез генә әйтә. Үкенүләр, үртәлүләр, күз яшьләре инде күптән артта калган. Бу көздә инде аңа сиксән тулды. Гомернең тугызынчы дистәсен ваклаганда, артта калган елларга, анда ясалган ялгышларга карап, аның кебек шулай моңсу елмаясың гынадыр инде ул...

Мәдинә апа Әлмәт районы авылларының берсендә туып-үсә. Унъеллык мәктәпне тәмамлагач, татар теле укытучысы булу хыялы аны Казан дәүләт университетына алып килә. Әмма башкалада озак тоткарланмый: беренче курсны тәмамлауга, читтән торып уку бүлегенә күчеп, кире Әлмәтенә кайта – нефтьчеләр янына эшкә урнаша. Бу – язмыш чакырып кайтаруы була бугай...

Институт тәмамлаганнан соң, юллама белән Татарстанга эшкә килгән ул азәрбайҗан егете Томрис исемле була. Мәдинәдән ун яшькә олырак. Татар җирендә төпләнү нияте уенда юк, берничә ел эшләгәннән соң, туган ягына кайтып китәргә җыена. Мөселман динендә булса да, телләр башка, йолалар бер-берсенә охшамаган, гореф-гадәтләр үзгә... Кыз берәүгә дә ишетми, тыңламый. «Яшьлектә карарлар шундый җиңел кабул ителә», – ди ул әлеге көннәрне искә төшереп. Юлында очраган беренче кешегә, үзенә дәшкән беренче ир-егеткә 19 яшендә кияүгә чыга да куя ул шулай. Тагын бер елдан уллары туа, аңа Наил дип исем кушалар.

– Томрисны Бөгелмә шәһәренә, яңа гына ачылган ТатНИПИнефть институтына күчерделәр дә, анда китеп бардык. Иремнән кала алмыйм бит... 3 яшькә кадәр Наил авылда, минем сеңелләрем янында үсте дисәм дә була – аны әни карады. Декрет еллары ул чакта болай озын түгел, эшкә чыгарга кирәк иде.

Гомернең «бәхетле» дигән өлеше шушы урында тәмамлана.

1961 елның маенда Мәдинә белән улын поездга утыртып, ире аларны Азәрбайҗанга озата. Үзенең әле эшләре тапшырылмаган, берничә айдан соң гына килергә тиеш була. (Нигә аны көтәргә, нигә юлга гаилә белән бергә чыгып китәргә ярамаган – Мәдинә апа моның сәбәбен хәзер дә белми.)

Азәрбайҗанның төньягында урнашкан Хачмаз шәһәренә, иренең моңа кадәр әле бер тапкыр да күрмәгән, аралашмаган туганнары янына барып төшә ул. «Юлга чыкканда: «Чит илгә китмим, ошамаса, кайтырмын да килермен – поездлар йөреп тора, дип уйладым», – ди. Ошамаса – кайтырмын... Тик кулында бала булганда, карарларны инде уйламыйча, ашык-пошык кабул итә алмыйсың шул. Ә баланы азәрбайҗан туганнар зурлап каршы ала. Ир бала бит, нәселне дәвам итүче! Әнисе исә ир малайга ияреп йөрүче – аның шәүләсе генә.

И-и, чит-ят җиргә барып кергән ул беренче минутлар, беренче көннәр. Бүгенгедәй истә...

– Биемем ул чакта кызларында – иремнең апаларында тора иде. Элеккеге байның зур йортында дүрт гаилә яшиләр. Ул яктагы гадәтләр буенча, бары – бергә, югы – уртак боларның. Берсе ашарга нидер пешерсә, калганнар бөтенесе җыелып килеп керә. Һәммәсенә бер озын коридор. Идәннәре буялмаган, күптән су күрмәгән – җир белән бер. Бусаганы атлап керүгә игътибар иткән идем моңа. Икенче көнне иртүк тордым да, алар йокыдан торганчы идәннәрен юдым. Без бит авылда идәнне комлап, мунчалалап юарга, агартырга ияләшкән. Монда да кыра-кыра юдым. Торып чыктылар да, барысы да шаккаттылар: «Бу идән шундый төстәмени?» – диделәр. Улым белән мине ашарга аерым кечкенә өстәлгә утырттылар.

Тел белмим, ә биемем белән ничектер аралашырга кирәк. «Синең белән русча сөйләшеп, үләр вакытым җиткәндә генә авызымны пычратмыйм, өйрән», – диде ул миңа. Ялгыш та русча бер сүз әйтмәде, гел үзләренчә сөйләде. Аңламыйча торсам, «шуны да белмисең, аңламыйсың», дип ачуланды. Улым да анда барганда татарча гына сөйләшә иде әле. Бер ай дигәндә русчаны өйрәнде, өч ай булганда – азәрбайҗанчаны. Ул миңа тәрҗемә итә башлагач, хәлем азрак җиңеләйде... Наил татар телен онытсын өчен бик тырыштылар инде. «Башын бутама баланың, киләчәктә ул Татарстанда яшәмәячәк!» – дип, миңа да аның белән татарча сөйләшүне тыйдылар. Улымның телен саклый алмадым шул. Көн саен талашырга кирәк булачак иде бит. Алар белән көрәшергә көчем җитмәде...

Ире кайтып «Каспморнефть» оешмасына эшкә урнаша. Алар йорт сатып алуга, кайнанасы улы гаиләсе янына яшәргә күченеп килә. Ташларга да китәргә кирәк, дигән уйлар һаман кичектерелә. Беренче мәлләрдә әнисен гел: «Әйдә, чемоданны җый, үзебезгә кайтып китәбез, сагындым!» – дип йөдәткән Наил дә бу хакта инде көннән-көн сирәгрәк искә төшерә.

Бер-бер артлы ике кызлары туа. Аның берсенә – Ульвия, икенчесенә Арзу дип исем кушалар. Дөресрәге, кайнанасы куша. Киленнең теләгeн кем сорап торсын?!

«Миңа анда бер дә рәхәт булмады...» Мәдинә апа бу сүзләрне әйләндерә дә кабатлый, әйләндерә дә тагын кабатлый. Шулайдыр, үзеңне кешегә санамаган җирдә ничек рәхәт була алсын, ди?!

...Берсендә кемнең өендә төзелеш бар, шуларга машина белән таш өләшәләр. Кайнанасы да капка төпләренә бер самосвал таш бушаттыра. «Урлап ташып бетерерләр, капканың эчке ягына кертергә кирәк», – дип каршы ала ул шул көнне эштән кайткан киленен. Зур-зур ташларны интегә-интегә ишегалдына ташый Мәдинә. Берүзе! Берничә кичкә сузыла бу эш. Инде бүген ял итәм, дип кайтса, кайнанасы: «Хәзер бит капка ачылмый, монда ятмасыннар, әнә теге почмакка күчерергә кирәк», – ди. Нишләсен, тагын күчерә...

«Төшкән җиреңдә таш бул!» – дип тәрбияләгәннәр шул аны.

«Бер-ике көн күз яшемне күрмәсә, моны ничек итеп елатыйм икән, дип уйлый кебек тоела иде ул миңа», – ди Мәдинә апа биеме турында. Килен көндез утырып торырга, ял итәргә тиеш түгел. Өйгә кеше кергәндә бигрәк тә утырырга ярамый – кунак чыгып киткәнче аяк өстендә басып торырга тиешсең. Биемең белән, ireңнең апалары белән мөнәсәбәтләр кору шактый катлаулы – һәрберсенең аерым тәртибе бар. Килешмичә, каршы төшеп кара! «Бездә алай түгел!», «Бездә андый закон юк!» дип шундук авызыңны ябалар. Ирең белән икәү генә беркая бара алмыйсың: парлап театр-концертларга йөрергә, хәтта кунакта да янәшә утырырга ярамый – монда алай кабул ителмәгән...

Гомер шулай уза. Дүрт елга бер туган якка кайтып килүләр арасында ничек яшәлгәнен үзе генә белә. Онытылып торулар эштә генә була. Хачмазда яшәгәндә, мәктәптә башлангыч классларны укыта, Бакуга күчеп килгәч, Азәрбайҗан нефть һәм химия институтының китапханәсенә урнаша, бүлек җитәкчесе булып күтәрелә.

Аннан, көтмәгәндә-уйламаганда, ире үлеп китә. Йөрәк... Бу хакта ул уфтануларсыз гына әйтә. Яратып, якын итеп яшәмәгәч соң... (Әлеге урында түзмим: «Мәдинә апа, сез бит гомер эченә бер тапкыр да яратып карамагансыз», – дим. Ул килешә: «Әйе...» – ди. Берара икебез дә сүзсез калабыз.)

Аннан илдә үзгәртеп корулар башлана да, моңа кадәр корган бөтен тормыш җимерелә. Оешмаларның күбесе ябыла. Улы да, кызлары да эшсез кала.

PRESSA.RU

– Иремне җирләгәч, туган якка кайтып китәргә була иде, әлбәттә. Тик инде җанымның бер өлешен – балаларымны калдырырга туры килер иде. Аларга иң авыр вакытта... Балалар үсеп җиттеләр дә: «Нигә иртәрәк аерылып китмәдең? Нигә Татарстандагы туганнар белән аралаштырмадың, татар телен өйрәтмәдең?» – диделәр. Булдыра алганча аңлатырга тырыштым... Наил өйләнде, Ульвия белән Арзу кияүгә чыктылар. Әйе, азәрбайҗаннарга. Аларның бит бу үз илләре, үз кешеләре... Менә монысының никахы әйбәт булды, унды, дия алмыйм. Башта кызларның кечесе башлыкүзле булды. 23 яшендә аның инде үзенең өч баласы бар иде. Аның кызы – беренче оныгым үсеп җитте дә, 18 яшендә кияүгә дә чыгып куйды – әнисе 36 яшендә инде әби булды. Туксанынчы елларны сөйли идем бит әле... Ярый ул вакытта минем пенсиягә чыгар вакытым җиткән иде инде. Әмма онықларны үстерәсе бар бит... Улым белән базарда сатарга урын алдык.

Туган тел безгә җыр кебек булып ишетелә», – ди ул.

Базарда басып торганда татарча сөйләшүчеләрне ишетә дә инде ул. Ничә еллар эчендә беренче тапкыр! Үз колакларына үзе ышанмый. Шуңа күрәдер инде, җөмләсенә кадәр истә. Бер хатын янындагы кызына: «Туктале, майонез да алыйк», – ди. Чабып, каршыларына чыга. Танышалар. «Без, татарлар, Бакуда бик күп бит, – ди ул хатын аптырап. – Биатам үлгән иде, кырыгын уздырабыз менә, сез дә килегез әле...»

Коръән ашына бара, әлбәттә. Өй тутырып кунак җыелган: ир-атлар, хатын-кызлар. Барысы да татарлар! 25 ел буена ничек ул аларның берсен дә очратмаган?!

Милләттәшләрен табу аның тормышын шактый үзгәртә. Әйткәнемчә, туксанынчы еллар бу, һәркайда милли күтәрелеш башланган чор. Азәрбайҗан Республикасында яшәүче татарлар да туплана, берләшә башлыйлар. Мәдинә апа Бакудагы татар оешмасы оештырган чараларның уртасында кайный. Бу эшкә аның балалары да бик теләп кушыла. Бизнесы аякка басуга Наиле оешманың эшенә акчалата ярдәм күрсәтә башлый. Татар оешмасына кайдан гына кунак килсә дә, әнисе аларны улының өенә алып кайта: йорты зур, күңелләре иркен – һәммәсе сыя.

Татар теле өйрәнергә теләүчеләр өчен курслар оештыралар. Беренче тапкыр Сабантуй үткәреп карыйлар. Халыкка ошый! Берничә елдан ул инде шәһәркүләм бәйрәмгә әверелә, «Кайчан була?» – дип халык аны көтеп ала. Татарларны белә, шәһәрдә барган барлык чараларга чакыра башлыйлар. Хөкүмәт татар оешмасының эшләренә ярдәм дә итә.

Ә бу вакыт аның ике кызы чит илгә китеп яшәргә җыена.

– Ирләреннән уңмадылар, хезмәт хаклары очын очка ялгарлык кына иде... «Киләчәктә безне монда ни көтә?» – диделәр дә тәвәккәлләделәр шул. Мине дә үзләре белән чакырдылар. «Әнине ташлап китә алмыйм», – дидем. «Килә алсаң – кил, килә алмасаң – хуш», – диделәр дә чыгып киттеләр... Мин Әлмәткә кайткан саен, әни: «Син монда чакта ахирәткә күчсәм ярар иде, кызым», – дия иде. Авырый башлагач, янында бик озак утырып, Бакуга – өйгә кайтып керүгә, артымнан: «Хәле начар», – дигән хәбәр килеп җитте. Мәскәүгә очтым, тик аннан шул көнне үк Казанга самолетка билет булмады. Әнинең өзелгәнен шунда шалтыратып әйттеләр. Хәтта җирләргә дә кайтып җитә алмадым... И-и, ул чактагы үкенүләр! Җиде ел буе көн саен диярлек еладым... Эчтә нидер өзелде. Авылда әнинең җидесен уздырганнан соң, балалар янына чыгып киттем. Кече кызым да Чехиядән кабат Германиягә күченгән иде инде – барыбыз да Берлинда җыелдык.

Мәдинә апа белән без Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән чараларның берсендә таныштык. Германия татарлары делегациясе белән килгән иде ул. «Бу юлы милләттәшләрегезне Бакудагы кебек чирек гасыр эзләмәгәнсез бугай», – дип елмаям. Юк, монда да бик тиз булмаган.

...Германиягә олы кызы гаиләсенә барып төшкән Мәдинә апа. Тел белмәгәч, өйдән әллә ни ерак китеп йөри алмаган: оныкларның берсен мәктәпкә илткән, икенчесен балалар бакчасыннан алып кайткан, ашарга пешергән. Беренче мәлдә, документлар әзер булганчы, хөкүмәт аңа пособие түләп торган, аннан пенсия бирә башлаган. Фатирга чиратка да бастырганнар. Берлин шәһәренең үзәгендә, ике бүлмәле үз фатирында яши ул бүген. Пенсионер буларак, шактый ташламаларга ия, шәһәр транспортында бушлай йөри. Матди яктан балаларына бәйле түгел, пенсиясе барысына да җитә: фатирга, коммуналь хезмәтләр өчен түләргә дә, каядыр барырга, хәтта Россиягә кайтып килергә дә.

Алты елдан соң телне өйрәнәнү курсларына языла ул. Шулай итеп, җитмештән соң, кабат парта артына утыра. «Әле һаман укыйм», – дип көлә. Телне су кебек эчмәсә дә, аңлый: үзенә кирәкне сорый, җавап бирә.

Инде татарларны ничек табуы турында.

– Әле Ульвияләрдә яшәгән чагым иде. Телевизорга русча канал урнаштырырга дип, оста чакырттык. Бер егет килде. Исеме Альберт булып чыкты. Русча сөйләшә, ләкин акцент белән. «Акцентыгыз татарларныкына бик охшаган», – дим моңа. «Ә мин татар!» – димәсенме?! «Татарлар тагын бармы икән монда, белмисезме?» – дим. «Бар, минем апалар да монда яши, – ди. – Эштә Фәрит исемле бер дустым бар. Әле ул яңа гына бер әби белән танышкан. «Бик тәмле итеп пәрәмәч пешергән, исе подъездга ук чыккан иде, – дип сөйләде», – ди. «Телефон номерын сора әле шул әбинең», – дим. Галия апа белән без шулай табыштык. Очраштык, йөрешә башладык. Безнең аша балалар да танышты.

Ә Берлинда татарлар оешмасы барлыгы турында алар интернеттан укып беләләр. «Татарча чәй эчәргә чакырабыз» дигән игъланнарын күрәләр дә, Галия апа белән икәү җыенып китәләр.

Шул көннән башлап Мәдинә апаның чит җирдәге тормышы күпкә кызыклырак, мәгънәлерәккә әйләнә. Германия татарлары оешмасы үткәргән чараның янәсына барган саен яңа танышлары арта: Башкортстаннан, Оренбург өлкәсеннән, Урта Азиядән күчеп килгән татарлар. Җыелышып, дини бәйрәмнәрне уздыралар: Мәдинә апа күптән намазда, Коръән укый. Җәй көне һәммәсе бергә Сабантуй үткәргәннәр. «Бу бәйрәм безне тагын да якынайтты, туганлашып беттек», – ди. Казаннан җырчылар килеп тора, Тинчурин театры гастрольдә булып киткән. «Халык шундый күп булып килде. Телне белмәүчеләр дә байтак иде – тын да алмый тыңладылар», – ди ул.

Мәдинә апаның картлыгы тыныч, бәхетлегә охшаган. Бакудан гаиләсе белән улы кунакка килгәләп тора. Наилнең ике кызы, университет тәмамлагач, Берлинда магистратурада укыганнар. Арзуга өч бүлмәле яңа фатир биргәннәр. Ике оныгының инде үзләренең балалары бар...

Яңа гына Германиядән К. Тинчурин театрының Бонн шәһәрендәге гастрольләре вакытында төшерелгән бер кочак фоторәсем җибәрделәр – Мәдинә апа шунда, яшьләр арасында. Үзгем өзелеп, аның миңа әйткән сүзләрен исемә төшерәм:

– Миңа татар оешмасындагы кешеләр белән аралашу рәхәтрәк...

Әйе, «балаларым белән» дими...

Татарстанга, туган ягы Әлмәткә ул хәзер дә еш кайтып йөри. Монда аның сеңелләре яши.

– Авылга кайтып, туганнарым белән аралашып киткән саен үземә генә түгел, балаларыма да нинди бәхетсез язмыш сайлаганыма кабат-кабат инанам. Аларның ул-кызлары башка: барысы да тәртиплеләр, югары белем алдылар, тормышта күпкә ирештеләр. Менә диган гаилә кордылар. Барысының да кода-кодагыйлары татарлар... Ә мин чит халыкка балалар үстердем. Яшьләргә васыять итеп әйтәм: чит милләт кешесенә өйләнмәсеннәр дә, кияүгә дә чыкмасыннар. Башка халык белән кушылгач, барыбер аларча буласың. Моны теләмисең икән – андый гаилә корма гына...

Васыять ди бит. Ишетсеннәр иде.

Алай да саубуллашканда әйткән соңгы җөмләсе күңелемдә өмет уята:

– Оныкларым татар икәнемне белә. Мин аларның барысына да Татарстанны күрсәттем инде. Һәр кунакка кайтуымда аларның берәрсен үзем белән ияртеп кайтам...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

P. S. Язмада бер тапкыр да Мәдинә апаның фамилиясен телгә алмавыма гаҗәпләнмәгез. Ул моны үзе теләмәде. «Туганнарым читтә ничек гомер кичерүемне белмәде. Үткәннәр инде үткәндә калган, әмма аларга барыбер бәхетсез булып күренәсем килми», – диде. Исемнәр, шәһәрләр, илләр – барысы да үзгәртелде.

2017: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!

Олимпия уеннарында спортның биш төрен берләштергән антик пентатлон ярышы Борынгы Элладаның иң матур кешеләрен күрсәтү өчен уйлап чыгарылган. Конкур (ат спорты), фехтование, ату, йөгерү һәм йөзүне үз эченә алган заманча пентатлон да – спортның иң гармонияле уникаль төре, һәм ул әле дә олимпизм идеалларына хезмәт итә. 2017 елның 27 августында Каһирәдә Гөлназ Гобәйдуллина дөнья чемпионы булды. Яңа Уренгойда туып-үсеп, Россия җыелма командасында Ямал-Ненец автономияле округы һәм Мәскәү өлкәсе өчен чыгыш ясаса да, ул безнеке дә! Борынгы грекларның матурлык идеалын әнә шул җиңүе белән тагын бер кат раслады ул.

Гөлназ, без синең кырыс, шул ук вакытта мул табигатьле Себер ягыннан икәнеңне беләбез. Сине Себер шулай көчле ихтыярлы итеп тәрбияләдеме, гаиләдә спортчылар бармы?

– Әти-әнием – икесе дә спортчылар. Әтием Радик грек-рим көрәше белән, әнием Рәмзилә йөгерү һәм ату белән шөгыльләнәләр. Абыйларым Дамир белән Илнур йөзүне үз итте. Мин дә башта йөзүгә күбрәк игътибар итә идем, әкренләп ату, конкур, фехтованиегә өйрәндем.

Чыгышыбыз белән без Башкортстанның Ишембай районыннан. Балачагыбыз Яңа Уренгойда үтте, анда кышкы салкыннар 50 градуска җиткән чаклар да була иде, ләкин алар безне куркытмады. Җәйләребез Башкортстанда – әби-бабайларда үтә иде.

Җәй көне Дөнья чемпионатында яулаган алтын медальдән соң, ярты ел вакыт үтте. Җиңү тәме ничегрәк сизелә? Яңа җиңүләргә әзерлек тә барадыр инде?

– Әле дә бик күп язалар, шалтыраталар. Кемдер уңыш тели, кемдер киңәшләрен бирә, кемдер сораулар калдыра. Барысына да җавап бирергә тырышам. Өч атна тирәсе ял иткәннән соң, янә эшкә чумдым. Хәзерге вакытта Кисловодскида – тренировкаларда.

Хатын-кыз өчен спорт... Бу җөмләне ничек дәвам иттерәсез?

– Ирек. Грация. Көч. Иң беренче булыйм дисәң, көн саен үз-үзеңне җиңәргә кирәк. Ә хатын-кыз «иң-иңе» булырга ярата. Гомумән, кешеләрнең беренчелеккә омтылуы – табигый хис.



Гөлназ Гобәйдуллина: «Беренчелеккә омтылу – табигый»

Фото: https://ria.ru

PRESSA.RU



МОҢЛЫЙ ДӨНЬЯ ДА БАР ИКӘН...



Лилия
ТИМЕРГАЛИЕВА

КАЗАННАН АРЫ БЕРКАЯ ДА ЧЫККАНЫМ ЮК ИДЕ МИНЕМ. ТУГАННАН БИРЛЕ КАЗАНДА ЯШИМ, ШУШЫНДА УКЫЙМ ҺӘМ... ҖАНЫМНЫҢ БЕРТУКТАУСЫЗ КАЯДЫР ТАЛПЫНУЫН ТОЯ ИДЕМ. ҮЗ-ҮЗЕМНЕ ТАБУ ӨЧЕН ЕРАККА – НОРВЕГИЯГӘ КАДӘР КИТЕП КАРАРГА КИРӘК БУЛГАН ИКӘН...



■ Бергенның туристлар ярата торган өлеше бу. Биредә күбрәк кибетләр, офислар, кечкенә рестораннар урнашкан. Йортларның төрле булуы урамга үзгә бер ямь өсти.

■ Базар мәйданы. Аның уртасында – Норвегиянең талантлы язучысы һәм мәгърифәтчесе Людвиг Хольбергка куелган һәйкәл.



Яңгырлы сынау

Үзем укыган уку йортының студентлар алмашу программасында катнашуын белгәч, мин дә документларымны биреп карарга уйладым. Кайсы илгә барып укыйсың килә дигәнгә, «Норвегия» дип язып куйдым. Бу ил турында бернәрсә дә белмим югыйсә, танышларым арасында да барып күргән кешеләр юк. Шулай да әллә нәрсәсе белән җәлеп итте ул мине. «Норвегия» дип яздым да, Аллага тапшырып, документларымны җибәрдем.

Февраль башы иде бу. Кыш бетте. Карлар эреде, агачлар яфрак ярды. Хәбәр көтә-көтә яз да үтеп китте. Инде җәйнең дә беренче ае үтеп бара иде, кинәт... көтмәгәндә Норвегиядән шалтыраттылар! «Исәнмесез, Лилия! Документларыгыз туры килә, сезне Норвегиягә укырга чакырабыз, киләсезме?» – диделәр. И-и, киләсезме, дип сорап торалармыни инде аны?! Киләм, әлбәттә! Хәзер, тиз генә виза ясатам да, чемоданымны тутырам һәм (иң мөһиме!) әти-әнигә әйтеп, аларның ризалыгын алам да киләм. Көт, Норвегия!

Бер ай дигәндә, виза әзер булды. Чемодан да тутырылды. Әти-әнинең фатихасы белән юлга кузгалдым. Бер елым Норвегиядә узачак!

Юл бик авыр булды. Өч самолет алыштырдым. Прагада 12 сәгать самолет көттем башта, аннан – Копенгагенга, аннан Норвегиянең Берген шәһәренә очтым. Шушы шәһәрдә яшәячәкмен. Төнлә генә килеп төштем мин Бергенга. Мине, ике тәүлек юньләп йокламаган, кая килеп эләккәнен дә аңлап бетерә алмаган кызны, коеп яуган яңгыр каршы алды. Ә Казанда август иде, 30 градус җылы иде. Монда салкын һәм яңгыр... Тоташ өч көн яуды әле ул яңгыр. Туктар дип бер көн көттем, ике көн көттем. Өченче көнне түзмәдем – яңгыр пәрдәсе аша Норвегия белән танышырга чыгып киттем.

Норвегиялеләр сүзенә ышансаң, аларда елның 260 көнендә яңгыр ява икән. Бер мәкальләре дә бар: «Һава торышының үзгәрүен теләсәң, 15 минут көтеп тор». Чыннан да, 15 минут эчендә һава торышы үзгәрә дә куя монда. Өйдән чыкканда кояш булса, тукталышка барып җиткәнче яңгыр коя башлый, баштанаяк чыланып, университетка килеп кенә керәсең – урамда инде кояш көлә. Мин килгәндә өч көн тоташ яңгыр явуын Норвегиянең мине сынап каравыдыр дип фаразладым. Түзәр микән бу кыз, янәсе. Түздем. Түзү генә түгел, яраттым да. Тик анысы бераз соңрак.

Норвегиядә кунакка сыйланыр өчен түгел, сөйләшеп утырыр, яңалыклар белән бүлешер өчен йөриләр.

Норвегия энҗесе

Берген зур шәһәр түгел. 300 мең тирәсе генә кеше яши монда. Шулай да 5 миллион халкы булган Норвегия өчен зур шәһәр санала ул, зурлыгы буенча Ослодан гына калышып, икенче урында тора. Көньякта урнашканга, Бергенда бик салкын түгел, температура 0 градустан да төшми.

Таулар, таулар, таулар... Кышын кар да озак ятмый. Шәһәрнең кайсы ягына гына карасаң да, карашың мәгърур тауларга барып төртелә. Аларның түбәсе – ап-ак кар, болытларга тоташып китә. Норвегиялеләр үзләре, ял җиттеме, шул тауларга ашыга. Гаилә белән тауга менәләр, шунда пикник ясыйлар, спорт белән шөгыльләнәләр. Спорт дигәннән, Норвегиядә аның бар төрен дә үз итәләр. Төньяк шәһәрләрдә чаңгы, биатлон популяр. Кар булмаса да, Берген халкы аптырап калмый: тәгәрмәчле чаңгыларда йөриләр. Яше дә, карты да йөгерә. Хәтта яңгырга да карап тормыйлар. Этләре белән бергә йөгерүчеләр дә күп: үзләре велосипедта элдертә, этләре яннан йөгереп бара.

PRESSA.RU



■ Норвегиягә килгән туристлар фьордларга экскурсиягә бармый калмый. Хәер, дөрес әйтмәдем, Норвегиягә туристлар беренче чиратта шул фьордларны күрергә дип килә дә инде!

■ Норвегиянең милли театры. Осло шәһәре. 1899 елда төзелгән.



Бергеннан 30 минутлык арада гына – диңгез. Ул Атлантик океанга барып тоташа. Тик Норвегия энҗесе булып диңгез дә, океан да түгел, ә серле фьордлар (норвег теленнән «култык» дип тәрҗемә ителә) санала. Соңгы Боз дәверендә, моннан 10-12 мең еллар элек, бозлар кузгалганда барлыкка килгән ул табигать могҗизасы. Тар гына булып әллә ничә чакрымга сузылган су юлы, ә тирә-якта – таулар. Һәр фьордның үз исеме, үзенчәлеге... Гейрангер-фьорд шарлавыклары белән данлыклы. Согнефьорд – дөньядагы иң озын фьорд. Ил эченә 204 километрга кадәр кергән, диңгез тирәли 1308 метрга кадәр сузылган култыкны «фьордлар короле» дип йөртәләр.

Чит илгә андагы гадәтләрне дә өйрәнеп барырга кирәк икән.

Кыйммәтле ил

Норвегиядәге укыту системасын үзебездә дә кертер идем мин. Бездә белгечлек буенча берничә генә фән, ә калган 10-15 фән – башка өлкәдән. Дөресен генә әйткәндә, ул фәннәрнең күбесе сиңа кирәк тә булмаячак. Норвегиядә ике-өч, күп дигәндә биш өстәмә фәнне үзең сайлап аласың, ә калган барлык фәннәр – белгечлегең буенча. Норвегия университетын тәмамлагач, син бөтен өлкәне дә колачлап эшли алмыйсың, әлбәттә, ә менә үз өлкәңдә алыштыргысыз белгеч буласың.

Укытучыларның студентларга карата булган мөнәсәбәте бик ошады. Анда укытучылар үзләрен бик иркен тота. Нинди генә зур профессор булса да, студентны үз күреп, аның белән дустанә сөйләшә. Өстәл читенә дә утырып сөйләргә мөмкин ул, кофе эчә-эчә, кабинетның бер башыннан икенче башына йөреп аңлатырга да мөмкин. Иң мөһиме: темадан читләшми һәм үзен әллә кемгә куймый. Өй эшен сораганда да студентка: «Синнән сорасам, каршы түгелсеңме, аудитория алдында җавап бирә аласыңмы?» – дип мөрәҗәгать итә.

Норвегиядә уку бушлай. Үзләренә генә түгел, бөтен кешегә дә. Тик бөтен кешегә дә стипендия түләнми, шуңа күрә күпләр эшләп укырга мәҗбүр. Ник дигәндә, Норвегия – бик кыйммәтле ил. Мәсәлән, ипинең бәясе ике евродан башлана. Кафеда бер тапкыр ашап чыгу – уртача 150-200 кронга (15-20 евро) төшәчәк. Тулай торакка бер ай өчен түләү безнең акча белән 30 мең сум иде.

Норвегиягә барганда андагы кибетләрнең ял көннәрендә эшләмәвен белми идем. Шуңа күрә баштагы мәлдә шимбә-якшәмбеләрдә ризыксыз утырган чаклар да булды. 25 декабрь – Раштуа. Урамнарда бер кеше калмый, барысы да гаиләләре белән җыелышып, бәйрәм табыны артына утырыша. Мин бу көнне берүзем генә үткәрдем. 28 е көнне кибеткә чыксам... Бәйрәм өч көн дәвам итә, кибетләр дә өч көн буе эшләми икән! Өйгә кайтып, булган ризыклар белән тукланып торырга туры килде.

Норвегия транспортында кондукторлар юк. Һәр тукталышта билет сата торган терминал бар, шуннан билет аласың да, транспортка кергәндә аны автоматка куясың. Йөртүче синең билетыңны карап тормый. Тикшерүчеләр аерым: айга берничә тапкыр махсус киемдәге кешеләр кереп, билетың бармы-юкмы икәнен тикшереп чыгып китә. Берсендә укырга барырга дип чыктым – айлык билетымның вакыты чыккан. Хәзер нишләргә? Мин билетны тукталыштагы терминалдан ала белмим, һәрчак үзәк станциядә кассадан ала идем. Шул станциягә кадәр «куян» булып барыйм да, шуннан алырмын, дигән карарга килеп, курка-курка гына трамвайга кереп утырдым. Казанда да түләмичә беркайчан да йөргәнем юк иде, шуңа күрә бик курыктым. Иртән үк тикшерүчеләр йөрмәс әле, дип тынычлан-



Балык базарына барып карасаң, башларың әйләнә: бездә бик кыйммәт бәягә сатыла торган сирәк балыклар рәт-рәт булып кызыктырып ята. Бәясе дә арзан, чөнки диңгезләре янәшә генә бит.



дырган булам үземне. Бер тукталыш үтүебез булды – ишектә тикшерүчеләр күренде. Әле ярый ишек янына гына утырган идем, тизрәк чыгып киттем. Гадәттә, алар чыкканда да, туктатып, билетны тикшерә. Бәхеткә, мине туктатучы булмады. Билетсыз килеш тотсалар, 700-800 крон штраф түлисе була иде (айлык билет – 470 крон). Шулай итеп, миннән «куян» чыкмады, тиз генә терминалдан билет алырга өйрәнергә туры килде.

Яшәү тәме

Норвегиядә дүрт ай яшәгәч, әтиемнең туган көнен туры китереп, Казанга кайтып килдем. Шунда кибеткә керергә туры килде. «Ә нигә әле кешеләр минем белән исәнләшмәде?» – дип, чүттән генә кычкырып сорамадым. Норвегиядә урамга чыксаң да, кибеткә керсәң дә – кая гына барсаң да, таныш түгел кешеләрнең дә исәнләшүенә, хәлләрне сорашуына, саубуллашканда «килгәнең өчен рәхмәт, тагын кил!» дип озатып калуларына шулхәтле ияләшкәнмен икән! Ә бит килгән генә вакытта норвегиялеләрнең бу кадәр ачык һәм әдәпле булуы бик гаҗәпләндергән иде мине.

Норвеглар белән уртак тел табу авыр булыр, дип кисәттеләр мине. Әллә үзем ачык булдым, әллә миңа шундый кешеләре туры килде – уртак телне бик тиз таптык. Норвегиялеләрнең 95 проценты инглиз телен белә. Алар бик ачык, мөлаемнар. Европада да булдым, бик күп илләр гиздем, бик күп кешеләр белән аралаштым, тик норвеглар кебек ачык күңелле кешеләрне башка очратмадым.

Норвегиядә бер ел яшә дә, чын норвег кешесендә кунакта булма, имеш. Мин дә бардым аларга кунакка. Бездә бер кунак киләсе булса да, туй өстәле әзерлиләр. Аларда андый гадәт юк икән. Берәр пирог ише нәрсә пешерәләр, кабымлыклар куялар. Чәй яки кофе чыгаралар. Шуның белән шул.

Милли кухня дигәннәреннең дә әллә ни ис китәрлеге юк. Бәрәңге салатын норвег милли ризыгы итеп тәкъдим итәләр. Бездәге «Оливье»га охшаган ул, ит белән борчак кына салынмый. Кечкенә шарчык рәвешендә әвәләнгән тефтельләрне дә һәр кафеда очратырга мөмкин. Һәм, әлбәттә, балык.

Норвегиядә диңгез ризыгының нинди генә төре юк!

Төшкә әнинең өчпочмаклары керә башлагач, булмас бу, дип, милли ризыгыбызны үзем пешереп карарга булдым. Казанда вакытта бер дә пешергәнем юк иде. Бик тәмле килеп чыкты өчпочмакларым. Чәй эчәргә норвег кызларын да чакырдым. Аларда күпчелек камыр ризыклары – баллы. Шуңа күрә итле-бәрәңгеле өчпочмак башта аларга сәеррәк тоелды. Шулай да бик яратып ашадылар. Икенче вакыт үзебезчә итеп коймак пешердем – Норвегиядә анысы да тансык. Янә норвег кызларын чәй эчәргә чакырдым. Гаҗәпләнүләрен күрсәгез! «Чынлап та үзең пешердеңме? – диләр. – Кит инде, булмас, шушыны үзең пешереп буламыни?» – дип кат-кат сорыйлар. Норвегиядә яшь кызлар пешеренергә бик яратмый, шуңа күрә минем пешерүем аларга гадәттән тыш хәл кебек күренде.

Мине иң гаҗәпләндергәне – Норвегиядә беркем беркая ашыкмый. Казанда вакытта мин дә гел каядыр ашыгам. Кая ашыкканымны да белмим, тик агымга ияреәм дә, чабам да чабам. Норвегиядә дә беренче мәлдә, инерция буенча, ашыгып йөри башлаган идем. Кешеләрнең, ашыкмыйча гына, бераз елмаеп, үз җайларына атлауларын күрдем дә юл уртасында тукталып калдым. Тукtale, кая ашыгам, нәрсәгә ашыгам соң әле мин дип уйлап куйдым. Ашыкмыйча да яшәп була икән ләбаса! Үз-үзеңне яратып, әйләнә-тирәңә сокланып яшәп була икән. Мондый дөнья да бар икән...

PRESSA.RU

16+

«ХАТЫН ИЛҺАМЧЫМ БУЛСЫН»



Сәгыйть ХӘЙРИ,
«Төркия авазы» радиосының татар редакциясе җитәкчесе (Әнкара);
гаилә стажы – 21 ел;
ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Яшь чакта, әлбәттә, башкача буласың. Буй-сынына да игътибар итәсең, өс-башына да... Тормыш тәҗрибәң арткан саен үзгәрәсең. Ләкин минем өчен һәрвакыт беренче урында күзләр кала. Мине иң элек алар җәлеп итә. Ә аннары, кешене таныган саен, аның күңелен, эчке дөньясын ача барасың. Минем үземә хатын-кыз белән бер аһәңдә, бер дулкында булу бик мөһим.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Авыр сорау... Миңа калса, үзем бөтен сыйфатларын да гафу итәм. Ялган гына сөйләмәсен! Нәрсәгә алдалап, башкаларның башын бутарга? Кеше ихлас булырга тиеш, нәрсә уйлый – шуны әйтсен. Җайлап, күңелгә каты бәрелмәслек итеп тә җиткерергә була сүзне.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә якын, әлбәттә. Әмма комфортны күрдек инде, булдырдык. Хәзерге мизгелдә, бу яшьтә аның илһамландыручы булуы минем өчен мөһимрәк. Җанда катлаулы тормыш биргән арыганлык бар. Стресслар да бик күп. Шушы хәлдә илһамны аннан алмыйча, кемнән алыйм?!

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– 1991 елны мин Төркиягә укырга киттем. Туран Язган фонды аша чит илгә белем алырга баручы яшьләрнең беренче төркеме идек без. Турыдан очкычлар очмый иде әле. Ленар һәм Зөлфия белән башта Сочига бардык, аннан Батуми аша китеп, чикне җәяү чыктык. Кулда турист визасы. Әнкара шәһәренә барып урнашып, тел өйрәнү курсларына йөри башладык. Интернетның да, кесә телефоннарының да әле ни икәнен дә белмибез. Чит илгә киткән кешеләрнең барысы да анда баруга якташларын, кардәшләрен эзли башлый. Мин Кырым татарлары җәмгыятен эзләп таптым. Телләре бездән шактый аерылса да, барыбер якын булдылар... 1992 елда Казаннан Төркиягә яңа студентлар килде. Күңеллерәк була башлады. Алар арасында танышым Ләйлә Гаффарова да бар иде. Ял көннәрендә аның янына тулай торакка барып йөрим. Минем булачак хатыным ул чакта Ләйлә белән күрше бүлмәдә яшәде. Шулай таныштык... Нигәр – төрек кызы. Ул Болгариядә туып-үскән. Алар гаиләсенең дә әле Төркиягә яңа күченеп кенә килгән еллары иде. Танышуга ук йөреп китмәдек әле без. Гашыйк булу шактый соңрак килде. Мин инде укуны тәмамлап, бер шәхси фирмада эшләп йөри идем. Гашыйк чакта кеше бернәрсәне белми, хәтерләми бит ул – болытларда очып йөри. Ә менә үземнең ничек итеп тәкъдим ясаганым бүгенгедәй истә. Кулыннан тоттым да: «Без кайчан өйләнешәбез?» – дидем. Ул аптырап калды. («Миңа кияүгә чыгасыңмы?» – дип тә сорамадың син», – дип, әле дә гел әйтә ул.)

Нигәрнең кулын сорарга берүзем киттем. Аның әтиәнисе Бурсада яшиләр иде. Кызларын миңа бирергә атлыгып тормаганнардыр: аякта нык басып тору турында уйлап та булмый иде бит әле. Әмма Нигәр аларны мәхәббәтебезгә ышандырды, күрәсең – ризалаштылар. Туебыз зур булмады. Әйткәнемчә, матди яктан хәлләр мактанырлык түгел иде әле. Казаннан әти белән әни, сеңлем килде, Әнкарада белем алучы берничә татар студенты, фирмада бергә эшләүче иптәшләрем – бөтен булган кунак шушы. Никах укырга татар мулласы таптым: Финляндиядә имам булып эшләп, лаеклы ялга чыккач, Төркиягә кайткан Әхмәт Атасәвәрне чакырдым. Никахны рәсми теркәү белән исә кызык килеп чыкты. «Киләсе атнага туебыз, язылышырга телибез», – дип барсак, «Илчелектән язу кирәк», – диләр. (Үземнең Төркия өчен чит ил кешесе булуымны онытып җибәргәнмен!) Ә ул кәгазьләр әле берничә айдан гына әзер була икән. Без исә «туй үткәрәбез» дип хәбәр бирергә өлгергән идек инде... Августта туй булды, декабрьдә генә язылыштык.

5 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Кем, кая язган ир-ат кына башлап эндәшә, хисләрен белгертә ала дигән сүзне?! Хатын-кыз

да беренче адымны ясый ала. Әйтергә тели икән – әйтсен. Гашыйк булуның ни гаебе бар? Мин, гомумән, кискен кагыйдәләргә каршы.

6 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?**

– Шулай икән шул, ир кеше үзе дә аңламыйча хатын итеп әнисенә охшаган кызны эзли икән. Әнием үткен, кыю, хәтта усалрак та минем, теләсә кайсы ир-ат эшен эшли ала. Нигәр дә шундый. Әле өйләнешкәнче берсендә карыйм, чүкеч белән стенага тишек тишеп, кадак кагып, шкаф элгән. Аптырап калдым, димәк, моның кулыннан бөтен нәрсә дә килә, дип уйладым шунда. Хатын-кызның тормышта лидер булуы ир-атка кайчак авырлык та тудыра: ул сиңа мөмкинлек калдырмый. Аның артыннан өлгерә алмыйсың. Син эшкә тотынганчы, уйлаганчы, ул аны эшләп тә куя. «Нигә тотындың?!» – дим хәзер кайчак. «Беләсең, холкым шундый бит инде», – ди. «Ярар, ярар, мин катнашмыйм, үзең эшлә», – ди, ә үзе барыбер түзми!

7 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Бәлки... Ләкин минем үземне куркытмый. Мин көчле хатын белән яшим, моңа күнектем инде. Яңа өйләнгән чак булса, мөгаен, башкача җавап бирер идем.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Минем үземнең андый ситуациядә калган булмады. Ләкин гаиләдә андый вазгыять туса, әйбәт кабул итәр идем. Төрек ирләре, әлбәттә: «Ничек инде хатыным миннән күбрәк эшләсен, күбрәк мал таба алсын?» – дияргә мөмкин. Ләкин соңгы вакытта анда да яшьләрнең дөньяга карашлары үзгәрә. Һәрхәлдә, зур шәһәрләрдә шулай.

Акчаны кем табуы гына түгел, аның кем кулында булуы да мөһим бит әле. Гаилә – уртак бер ширкәт кебек инде ул. Бюджетны бергә төзисең, киңәшләшәсең. Башка вакыт исә мин күбрәк сиздермичә генә читтән күзәтүче, контрольдә тотучы бугай. «Ярар, ал, ләкин уйлап бетереп ал, аннары бөтенләй акчасыз калмыйк», – дип, искә төшереп торучы... Нигәр, әлбәттә, тәвәккәл. Йорт салганда да аның бу сыйфаты бик булышты. Мине ул күндерде. Йорт салу кайда да авыр. Осталар белән уртак тел табу үзе бер сәнгать: сүз биреп, вакытында килмиләр, җиренә җиткереп эшләмиләр... Рәсми эшләр, кәгазь тутырулар шактый вакытны алды. Анысы минем өстә булды. Нигәрнең моңа түземлеге җитми.

9 **Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар сезнеңчә бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?**

– Ир-атның логикасы гади, анык, компьютер кебек: ничек бар – шулай. Акны – ак, караны – кара, ди ул... Ә хатын-кызныкы бик катлаулы, урау. Нинди университет тәмамласаң да, аны аңлап бетерү мөмкин түгел.

10 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.**

– Башка хатын-кызлар да шулаймы икән, белмим, Нигәр, кибеткә барса, гел исемлектә булмаган нәрсәләр дә алып кайта. «Нигә алдың?» – дим. «Ә аңа ташлама иде, бәясе арзанга алдым», – дип җавап бирә ул. Арзан дип кирәкмәгән әйбер җыяргамы? Мин үзем алдан төзегән исемлек буенча гына алам әйберне. Тагын бер мин аңламаган сыйфаты бар: өйдә җиһазларның урынын гел алыштыра. Мин моңа ияләштем дә инде хәзер. «Ярый әле мине алыштырмыйсың, рәхмәт», – дип көләм кайчак. Каяндыр укыдым: йорт җиһазларының урынын алыштырып тору кешегә файдалы, ул аңа энергия бирә икән.

11 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Юл кую җиңелрәк! Үз фикеремне үткәрергә тырышып карадым – бу мөмкин түгел. Башны авырттырганчы... Ул хаклы булмаса да килешәм хәзер – сәламәтлек мөһимрәк. Ярар, ялгышын барыбер күрер дип уйлыйм, үземне шулай тынычландырам.

12 **Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.**

– Нәрсә бар, шуны ашыйм! Өйдә генә утырса, бәлки: «Нигә әзерләмәдең?» дияр идем... Хәер, хәтта ул очракта да болай әйтергә хакым юк дип саныйм. Ашарга әзерләү хатын-кызның гына вазыйфасы түгел бит ул. Әгәр кемдер шулай дип уйлый икән, ялгыша. Коръәндә дә алай әйтелмәгән. Киресенчә, гаиләсенең тамагын туйдыру өчен ир-ат җаваплы дигән сүз бар анда. Хатын-кыз эшләсә дә, хезмәт хакын гаиләгә үзе теләсә генә бирә, теләмәсә, үзе өчен генә дә сарыф итә ала.

Студент чакта пешерергә өйрәнгән идем, ләкин хәзер онытып бетердем инде. Лаеклы ялга чыккач, берәр курска йөреп, пешерергә өйрәнермен дип хыялланам менә. Телевизордан аш-су пешерү белән бәйле тапшыруларны карарга яратам. Төркиядә ашчылар күбрәк ир-атлар бит. Без дә өйдә төрек ашлары ашыйбыз. Нигәр, бик тырышып, өчпочмак пешерергә дә өйрәнеп карады анысы. Пилмән яратканымны белә: кәефе яхшы булса, гел ясый.

13 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Бездә киресенчә – күп вакыт аңа мине көтәргә туры килә. Газ сүнгәнме, ут янып калмаганмы, тәрәзәләр ачык түгелме – барысын да бер кат карап чыгам. Ул оныткандыр кебек тоела миңа: үземне үзгәртә алмыйм.

14 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...**

– Монысы да бездә киресенчә: ул кием үлчәмемне дә, ни яратканымны да – барысын да белә, ә минем аңа ошаган бүләк ала алганым юк. Кайсыбызга бәйледер бу, миңамы, аңамы – белмим. Бер тапкыр бүләк алгач: «Нигә бу кадәр кыйммәткә алып кайттың?!» – дип, барып алыштырды. Шуннан бирле авыррак... Чәчәкне яңа өйләнешкән чакта бер-ике тапкыр бирдем. Хәзер юк... Алып кайтсам, шатланыр иде, әлбәттә. Романтика каядыр читкәрәк китте шул. Тормыш бит, яшәгәндә берәү дә: «Мин сине яратам!» – дип кенә тормый.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



ЭТ — ЮМАРТ УЛ!

Эт елыннан ни көтәргә?

Шәрык календаре буенча, 2018 ел – Сары Эт елы. Эт – кешенең дусты, гаилә кыйммәтләрен, дуслык кадерен аңлаучы тугры җан иясе. Шуңа да быел туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр тагын да җылырак булыр, яңа танышларыгыз тора-бара чын дусларыгызга әверелер. Ялгызларның нәкъ менә шушы елда гаилә кору, бала үстерү теләге барлыкка килер. Әмма тормышыгызның үзгәрүен сез әле февральдән генә тоярсыз, тулы вәкаләтенә яңа ел февральнең 16 сында гына керешәчәк.

Елның стихиясе – җир, димәк, ел уңышлы килер, җирдән мул уңыш алу өчен шартлары да уңай булып торыр. Һәрхәлдә, яхшыга өметләник. Әмма эт ялкауларны өнәми. Эленке-салынкы йөрүчеләргә ул акча кытлыгы, күңелсезлекләр белән яный.

Кешелек тарихы Эт елында башланган бер генә зур сугышны да хәтерләми. Киресенчә, Эт елында солыхлар төзелгән, яңа ачышлар ясалган.

2018 ел да тарихка тынычлыкиминлек, мул уңыш, күңелле үзгәрешләр, елы булып кереп калсын.

Табынга ниләр куярга?

Эт – юмарт җан иясе. Исрафны, мактануны яратмый. Шуңа да Яңа ел табынын ризык өелеп калырлык итеп әзерләмәгез. Ризыклар үзләре дә әллә ни катлаулы булмасын. Эт, әлбәттә инде, ит ярата. Кыздырган тавык та, тутырган каз яки үрдәк тә күңеленә хуш аның. Табында ит ризыклары күбрәк булса, оттырмассыз. Иң мөһиме – елкы итеннән әзерләнгәне генә булмасын. Шулай ук эт балыкны да артык өнәп бетерми. Бәлки, быел чөгендерле балык салатын ясамый торырбыз? Алай да кылчыксыз балыкларга каршы булмас ул. Җиләк-җимешкә дә сөенер – баллыны ярата эт.

Исерткеч эчемлекләр турында инде әйтеп тә торасы юк. Этнең сәрхушләрне җене сөйми. Шулай булгач, Яңа ел табынына нинди эчемлекләр куясын үзегез чамалагыз инде.

Ничек киенергә?

Эт – табигать баласы, урамны, киңлекне, иркенлекне ярата. Киемдә артык кычкырып тормаган табигый төсләр, тыйнаклык күркәм күренә. Сары һәм көрән төсләргә өстенлек бирергә тырышыгыз. Хәер, башка төстәге кием кисәгез, сезне Яңа ел хуҗасы кабул итмәс дигән сүз түгел бу. Шулай да артык кычкырып торган җете төсләр бигүк урынлы булмас.

Песи белән этнең үзара дус булмавын истә тотып, песиләр семьялыгына керүче җәнлек тиреләрен хәтерләткән күлмәкләрегезне киләсе елга калдырып торыгыз. Чылбырлар да элмәгез, этнең чылбырга мөнәсәбәтен үзегез беләсез.

Ә менә чын гәрәбәдән ясалган зиннәтле муенсаларыгыз булса, Яңа ел төнендә аларны рәхәтләнеп тага аласыз. Гәрәбә уңыш китерә, хуҗасына сәламәтлек юрый. Алтын да бик урынлы.

Өйне ничек бизәргә?

Җитеннән тегелгән тәрәзә пәрдәләре, киҗе-мамык ашъяулык, тастымаллар – Яңа елга өйне бизәгәндә боларны рәхәтләнеп куллана аласыз. Агач һәм балчыктан эшләнгән сыннар, чыршы уенчыклары да мулдан булсын. Чыршы бизәсәгез, катыргыдан яки юка фанерадан бик матур итеп эт оясы ясап эләргә була. Төсләр, әйткәнебезчә, сары, көрән, алтынсу, сөтле чәй төсе, кызыл-сары...

Табынны исә агач яки балчык савытлар белән бизи аласыз. Мәсәлән, салатлар өчен агач кашык куярга, эчемлекләрне балчык кувшинга салырга мөмкин. Табигыйлек, тагын бер кат табигыйлек!

Этнең традицияләргә тугрылыгын истә тотып, гаиләгезнең кадерле ядкарьләрен, истәлекле бүләкләр, фотографияләрне күренеп тора торган җиргә – ачык киштә яки өстәлгә тезеп куйсагыз була. Яңа ел хуҗасы моны тиешенчә бәяләр. СССРда җитештерелгән әйберләргә быел игътибар аеруча зур булачак. Балкон яки чолан почмагында сакланып калган элеккеге кәстрүл, таба, чәйнекләрегезне әйбәтләп юып, аларны аш-су әзерләгәндә куллана аласыз. Борынгы сәгать, гөл чүлмәге, самавыр, әниләрегезнең сандыгындагы чигүле сөлгеләр – берсе дә читтә калмасын.

Нинди бүләк сайларга?

Дус-ишләргә бүләк сайлаганда да табигый булып калырга кирәк. Агач яки балчык эт сыннары менә дигән бүләк булачак. Шулай ук табигый ташлардан ясалган алка-муенсалар да шәп бүләк.

Хатын-кызлар өчен агач савыт-саба бүләк итү дә отышлы. Бердән матур; икенчедән, ел хуҗасының күңелен күрерсез.

Юраулар

Халык арасында Яңа ел белән бәйле ырым-шырымнар да бар. Әлбәттә, боларга артык ышанырга, җитди итеп кабул итәргә ярамый. Күңеллерәк булсын өчен, җиңелчә шаярту итеп кенә оештырырга кирәк аларны.

Алай да бер-ике ырымны әйтеп китик әле, кызык өчен генә сынап карый аласыз.

Гаилә ныклы булсын өчен, Яңа елны каршылаганда өстәл аякларын бер-берсенә бау белән бәйләп куялар икән.

Яңа елны каршылаган мизгелдә кинәт кенә төчкереп җибәрсәгез – куаныгыз. Киләсе ел сезнең өчен дә, төчкергәнегезне ишеткән башкалар өчен дә уңышлы һәм бәрәкәтле булачак.

Яңа ел гаиләгезгә бәхет, иминлек алып килсен дисәгез, яңа ел иртәсендә, уянуга иң беренче эш итеп, хәләлегезне үбеп алыгыз.

Яңа ел иртәсендә өйгә беренче булып ир-ат керсә, ел уңышлы, бәрәкәтле килә, диләр.

Яңа елның беренче көнендә авыр эшләргә тотынмыйлар, юкса ел буе тормышыгыз авыр барачак, имеш.

Яңа елга кергәндә, кесәгә акча салырга кирәк икән. Кесәң буш булса, ел дәвамында да җилләр уйнап торыр анда дигән ырым бар. Юк-барга колак салмагыз...
Бәйрәмегез күңелле узсын!
Елыгыз матур башлансын!

PRESSA.RU

ЯҢА ЕЛГА – «СЕРЛЕ ТАВЫК»

Илсөя БӘДРЕТДИНОВА исемен татар дөньясында белмәгән кеше бар микән? Кыю, талантлы, тәвәккәл, чибәр, затлы... Кыю – чөнки ул мишәр кызы – Лениногорский районының Иске Шөгер авылыннан. Тәвәккәл – чөнки Зәйнәп әбисе аны бер эштән дә куркып тормаска, кирәк булса, таш тишеп юл сабарга өйрәтеп үстергән. Талантлы – монысы аңа Күкләр бүләге. Без исә бу исемлеккә тагын бер сыйфатны өстәр идек: гаҗәеп уңган да әле ул. Андыйлар турында халкыбызның бик матур бер сүзе бар: «Кулы тәмле!» – диләр. Илсөя Бәдретдинова – тәмле куллы, ачык йөзле хуҗабикә. Яңа ел саныбызга осталык дәресе төшерергә баргач, без аны үзебез өчен өр-яңадан ачып кайттык. Ул пешергән «серле тавык» белән – исеме генә дә ни тора! – сез дә Яңа ел табыныгызны бизәгез әле.



Кирәк:

(4-5 кешелек гаилә өчен)
- 6 тавык боты;
- 200 г шампиньон гөмбәсе;
- 2 баш суган;
- 50 г каты сыр;
- 2-3 аш кашыгы кибет каймагы;
- 1 тырнак сарымсак;
- тоз-борыч;
- үсемлек мае.

Соус өчен:

- 250 г мүк җиләге;
- ярты стакан су;
- 75 г шикәр комы;
- 1 чәй кашыгы тулыр-тулмас крахмал;
- бер чеметем дарчин (корица).





Эш барышы:

■ Тавык ботларын юып, сак кына тиресен салдырабыз. Бик җайлы куба ул, элпәсен үткен пычак белән кискәләп җибәрәсе генә бар. Ботның өске ягына кадәр килеп җиткәч, сеңерләрен кисеп, калынрак пычак белән сөяген өзеп чыгарабыз, өске буыны тире астында калсын.

■ Тавык итен сөягеннән аерып, ваклап турыйбыз. Блендер белән тураклатсаң да була, иттарткычтан чыгарсаң да ярый. Алай да, итне турап кына салсаң матуррак шикелле.

■ Табага үсемлек мае тамызып, башта вак итеп туралган суганны, аннары туралган гөмбәне кыздырып алабыз. Тәменчә тоз, борыч сибәбез.

■ Зуррак җамаякка кыздырылган гөмбәне, туралган итне, эре угычтан уылган сырны салып, яхшылап болгатабыз. Тоз белән борычның таманлыгын тикшерәбез.

■ Тавык тиресенә шушы эчлекне бал кашыгы белән тыгызлап тутырабыз. Тыгыз, йомры булса матур. Тиренең аскы итәген кайтарып, агач таякчыклар белән беркетеп куябыз.

■ Тутырылган тавык ботларын майлы табага тезеп, өстеннән вак угычтан уылган сарымсак кушылган каймак ягабыз да 40–50 минутка 180–200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.

■ Бәйрәм булгач, бәйрәмчә булсын, ул пешкән арада бик тәмле бер соус әзерлик әле.

Юылган мүк җиләген тирән эчле кәстрүлгә салып, ярты стакан су өстибез дә кайнатырга куябыз. Кайнап чыгуга, шикәр комы һәм бер чеметем дарчин өстибез. Крахмалны аз гына салкын суда төерләре калмаслык итеп болгатып, мүк җиләге янына салабыз. Тагын бер кат кайнап чыкканнан соң, утны сүндерәбез.

Чак кына суынып киткән мүк җиләген блендер белән издереп алабыз. Боламык булганчы изәргә кирәкми, җиләкләр бөтен килеш калырга тиеш.



■ Тәлинкәгә салат яфраклары түшәп, тутырган тавык ботларын тезәбез, өстеннән җиңелчә генә соус агызып, петрушка яфраклары белән бизибез. Калган соусны исә матур савытка салып, табынга чыгарабыз.

■ Имин һәм бәрәкәтле еллар телибез сезгә! Киләсе елларда да бергә булыйк, аерылмыйк!

PRESSA.RU

Бүген бәйрәм белән котлап, берберебезгә открыткаларны сирәк юллыйбыз. Ә менә элегрәк һәр бәйрәмгә илнең төрле почмакларыннан «сөенеч хатлары» агылыр иде. Шулкадәр күңелле була торган иде ул! Берсеннән-берсе матуррак бу открыткалар, шул елларның хатирәсе булып, әле дә китап, фотоальбом эчләреннән килеп чыккалый. Төргәк-төргәк булып җыелган ул «сөенеч хатлары»н атлас тасма белән бәйләп, кадерләп саклый да идек әле без. Әй күңелле чаклар! Тукта, ник ямансулыйбыз? Туганнарыбызны бәйрәм белән котлап, «сөенеч хатлары»н бүген дә юлларга була лабаса. Өстәвенә, «Сөембикә»нең бүгенге кунагы – алтын куллы Эльмира ГАЛЛӘМОВА безгә ул открыткаларны үзебезгә ясарга өйрәтәм дип тора. Искиткеч матур, бердәнбер, мәңге кабатланмас итеп! Аларның һәрберсендә берәр Яңа ел әкияте яши сыман. Бик мавыктыргыч, җанга рәхәт шөгыль бу.



«СӨЕНЕЧ ХАТЛАРЫ»



Кирәк:

- кардсток дип аталган бер табак кәгазь (А4 форматында). Без сөт төсендәгесен кулланабыз;
- скрапбукинг өчен ак төстәге акварель кәгазь (җирлегенә төрле рәсемнәр басып төшерелгән). Шулай ук А4 форматлы бер табак кирәк булыр;
- декоратив бизәкләр: котлау сүзләре язылган стикер, тасма, чыршы, бәләкәй генә букет, кәгазьдән кисеп ясалган өй, яшел чыршылар, бияләй, кар бөртекләре, ачкыч бәйләме;
- «Момент кристалл» җилеме;
- ике ягы да ябышкак тасма;
- кайчы, линейка, үткен пычак.

Эш барышы:

■ Кардсток кәгазеннән 15х21 см зурлыгындагы бер кисәк кисеп алабыз (А4 форматының нәкъ яртысы була). Тактага куеп, үткен пычак белән киссәң – яхшырак. Кискән өлешне урталай бөклибез. Бөкләгәнче, берәр очлы әйбер белән бөкләм эзен сызып чыксаң, кулай.

■ Ак төстәге акварель кәгазен 10х14,5 зурлыгында кисәбез. Бу – открытканың алгы бите булачак, бизәкләр шушыңа беркетелә.

■ Ике ягы да ябышкак тасмадан кечкенә дүрт шакмак кисеп алып, алгы битнең арткы ягыннан дүрт почмакка ябыштырып куябыз. Икенче ягын әлегә кубармый торабыз.

■ Иң аскы почмакка «Момент» җилеме белән котлау сүзе язылган



стикерны ябыштырабыз. Аның өстенә киңлеге 0,5 см булган ак бөрчекле яшел тасма ябыштырыла. Тасма читләрен битнең арткы ягына кайтарып ябыштырып куябыз.

■ Тасма өстенә кәгазьдән киселгән өч чыршы ботагы һәм бәләкәй чәчәк бәйләме ябыштырыла. Бәйләмнең әзерен сатып алырга да була, пенопласт шарларын буяп, үзегез дә ясый аласыз. Серкәчләрне исә кибеттән алдык. Букетны яшел тасма белән бәйләп, өстенә кечкенә генә нарат күркәсе куябыз.

■ Әлеге открытканың тагын бер бизәге – шейкер, ягъни тәрәзә. Моның өчен диаметры 6 см булган чипборд (кибетләрдә сатыла), үтә күренмәле папкадан шушындый ук зурлыкта киселгән түгәрәк, алтын төсендәге ялтыравык кәгазь боҗра (аның да диаметры 6 см) кирәк. Ялтыравык боҗраны үтә күренмәле түгәрәк тирәли «Момент» җилеме белән ябыштырабыз. Аннары бу чипбордка ябыштырыла.

■ Шейкерны открыткага ябыштырганчы, эчкә алтын төсендәге каты фольгадан киселгән йолдызлар һәм сәйлән бөртекләре тыгып калдырабыз (алар ябыштырылмый). Түгәрәк уртасына кечкенә генә бер чыршы да ябыштырып куйсаң – матур.

■ «Тәрәзә» өстенә кечкенә алтын түгәрәк ябыштырыла – чыршы уенчыгын хәтерләтсен әле! Бер читенә ак кәгазьдән киселгән бияләйләр «элеп» куябыз. Бу бизәкләрне кибеттән дә алырга була, аларны кисү өчен бигшот дигән махсус җайланма да бар.

■ Открытканың алгы бите әзер. Инде ябышкан тасманың кәгазен кубарып, аны открытканың үзенә ябыштырып куйыйк. Ябышкак тасма урынына җилем генә дә кулланып була, әмма алай открытка ялпак булачак. Безгә исә аның кабарынкы булуы ошый.

■ Эчке якның сул битен ак кар бөртекләре белән бизибез.

■ Икенче открытка да нәкъ шушы тәртиптә ясала. Беренче эш итеп алгы битнең сул кырына җилем ярдәмендә 4 см киңлегендәге көмеш җепле пәрәвез тасма (кибеттә паутинка дип сатыла) ябыштырабыз.

■ Аның өстеннән ике чыршы ябыштырыла. Бу очракта инде ябышкак тасма кулланабыз. Чыршыларның биеклеге – 7 см.

■ Уң як почмакка каты кәгазьдән киселгән өй урнаштырабыз (ябышкак тасма ярдәмендә). Өй ике катлы итеп киселгән. Аскы каты – агач фактурасын хәтерләткән кәгазь. Алар бер-берсенә җилем белән ябыштырыла.

■ Өй кыегын көмеш төсле фольгадан киселгән йолдызлар, түгәрәкләр белән бизибез. Болар – кибеттән сатып алган әзер наклейкалар.

■ Алгы битнең аскы итәгенә рәшәткә «тотабыз».

■ Куе кызыл төстәге каты кәгазьдән 7х5 зурлыгында турыпочмаклык кисеп алабыз. Игътибар: турыпочмаклыкның сыртлары туп-туры түгел, эчкәрәк кереп, уеп алынган. Аның уртасына котлау сүзе язылган стикер ябыштырдык. Безнең очракта бу әзер наклейка иде. Бер-ике җиргә ялтыравык йолдызлар һәм түгәрәкләр «төртеп» чыгабыз.

■ Турыпочмаклыкның аскы почмагына ябышкак тасма белән ачкыч бәйләме беркетәбез. Бәхет ишекләрен ачар ачкычлар булсын алар!

■ Инде моны ябышкак тасма ярдәмендә алгы битнең өстенә ябыштырыйк та, бизәгән битебезнең үзен дә открыткага беркетик.

■ Открытканың эчке ягы кызыл төсле бер пар бияләй белән бизәлә.

■ «Сөенеч хаты»быз әзер! Инде котлау сүзләре язылган битне хат эченә кыстырып, якыннарыбызны сөендерергә ашыгыйк!

Яңа ел белән тәбриклибез сезне!



PRESSA.RU

16 ДЕКАБРЬ

"ПИРАМИДА"

КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕ

17:00



XVIII татар җырлы

БӨТЕН ТАТАР ЭСТРАДАСЫ


Генераль партнер:



VIP-партнер:



Генераль Агро-партнер:



Партнерлар:





6+



TATAR RADIOSI
сеть радиостанций



5 196 196



Кучкар. Карьерагызда активлык көтелә. Тәвәккәллегегез, максатчанлыгыгыз артыр. Әмма бер генә ләкин бар: эш сезне гаиләгездән читләштерергә мөмкин. Ялгыз «Кучкар»ларның яз айларында насыйбын очрату ихтималы зур.



Үгезбозау. Киләсе ел мөһим вакыйгалар алып килер. Тормышка башка күзлектән карарга өйрәнерсез. Күктән бәхет яуганын көтеп утырырга кирәкмәс, уңышның тырышларга гына юлдаш булуын истән чыгармагыз.



Игезәкләр. Нәрсәгә генә тотынсагыз да, җиңел генә башкарып чыгарсыз. Акчалы ел көтелә. Көтмәгәндә генә оештыру эшенә сәләтегез ачылып китәр. Язмыш сезне бик кирәкле кешеләр белән очраштырыр.



Кысла. Үзгәрешләргә бай ел булыр. Көтелмәгән вакыйгалар, очрашуларга әзер булып торыгыз, бигрәк тә җәй айларында. Кайчандыр тормышыгызда мөһим урын тоткан танышыгыз белән күрешерсез.



Арыслан. Хезмәт баскычында үзгәрешләр көтелә. Быел максатларыгызга ирешү өчен уңышлы ел булыр. Сәламәтлеккә дә зарланырлык сәбәпләр күренми. Рәхәтләнеп, дәртләнеп эшләп, тормыштан тәм табып яши торган вакыт.



Сөмбелә. Акчаны сак тотарга тырышыгыз, көзгә таба аның күбрәк кирәк булуы бар. Шәхси тормышыгызда күңелле үзгәрешләр көтелә. Тоткан юлыгыз дөрес, шул юлдан тайпылмыйча барсагыз, уңыш һәм бәхеткә юлыгырсыз.



Бизмән. Юмарт ел килә. Сәламәтлек җәһәтеннән булсынмы, акча ягыннанмы, мәхәббәт өлкәсендәме – бар да яхшы. Бер генә нәрсәдән сакланыгыз – юк-бар нәрсәләргә артык зур игътибар бирүдән.



Чаян. Очрашулар, аралашулар, танышулар елы булып исегездә калыр бу ел. Уйнап кына сөйләшүдән тормышыгызны үзгәртердәй зур эшләр башланырга мөмкин. Нәрсәгәдер ирешү өчен – бик уңышлы чор.

Укчы. Хыялларыгызны тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр ачылыр. Аеруча җәй көне йоклап калмагыз. Яңа эшкә тотынсагыз, отарсыз. Электән үк сөйрәлеп килгән мәсьәләләрне хәл итәргә туры киләчәк.



Кәҗәмөгез. Яңа бурычлар, яңа үрләр елы. Язмышның кайбер борылышларыннан күңелегез канәгать булмаса да, соңыннан шушының өчен аңа рәхмәт әйтерсез. Яңалыклардан курыкмагыз, уңыш – сезнең юлдашыгыз.



Сукояр. Яңа талант, моңарчы тоелмаган сәләтегез ачылыр. Кешеләр нәрсә әйтер, дип борчылмагыз, күңелегезгә буйсыныгыз. Нәрсәгәдер ирешү, яңа эш башлау, тормышны үзгәртү өчен кулай чор.



Балык. Кемнедер яки нәрсәнедер барып күрү турында хыялланган булсагыз, быел ул тормышка ашар. Нининдер яңа шөгыль табарсыз. Ул сезгә рухи яктан да булышыр, матди керем дә китерер.



декабрь *дә кабынган йолдызлар*

Татарстан



Венера Шәрипова (27.12.1927–8.12.1989) – **җырчы, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.**

Үзбәкстанда туа. Әтисе – Әгерҗе районының Уразай, әнисе Чүпрәле районы Мочәли авылыннан булалар. 1930 елдан алар Казанда яши, соңрак Литвага күченә. Әтиләре шунда һәлак була, әниләре кулга алына.

1943 елда Казан музыка училищесына укырга кереп, укуын Мәскәү консерваториясенең татар студиясендә дәвам итә. 1950–1972 елларда Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли, утыздан артык партия башкара. Беренче һәм соңгы башкарганы да – «Мадам Баттерфляй» операсында Чио-Чиосан ариясе була. Татар опера сәнгатенә керткән өлеше бик зур. 1972 елдан филармониядә лекторий бүлеген җитәкли. 1981 елдан гомеренең азагынача үз бригадасы белән илебез буйлап гастрольләрдә йөри.

Россия



Марина Голуб (8.12.1957–9.10.2012) – **Россиянең атказанган артисты.**

Мәскәүдә туып-үсә. Әнисе – Людмила Голуб шулай ук актриса. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1979 елда МХАТның мәктәп-студиясендә Виктор Монюков классында укый. 1979–1981 елларда «Москонцерт»та – сатира һәм юмор өлкәсендә эшләп ала, аннары Аркадий Райкинның миниатюралар театрына күчә. 1987 елдан – «Шалом», 2002 елдан Мәскәүнең А. П. Чехов исемендәге театрында эшли. «Юность Петра» фильмындагы Вера ролен кинодагы беренче мөһим роле дип атый. Күпләр аның Россия-1 каналыннан «Иртәнге почта», «Хәерле иртә!» тапшыруларын алып барганын да хәтерли. Актрисаның гомере вакытсыз – юл һәлакәтендә өзелә.

Чит илләр



Ванесса Паради (22.12.1972) – **актриса, җырчы, фотомодель.**

Франциядә, режиссерлар Андре һәм Коринн Парадилар гаиләсендә туа, кечкенәдән сәнгать белән мавыга. 14 яшендә үк «Таксист Джо» җыры белән бөтен Европага танылa. 1989 елда беренче тапкыр кинода уйный – «Белая свадьба» фильмында төп роль була ул. Берара экраннарда күренми тора, бер-бер артлы җыр альбомнары яздыра, «Шанель» йорты белән килешү төзеп, хушбуй рекламалый. 1995 елда Жерар Депардье белән «Эльза» фильмында уйный. Аннары аның катнашындагы «Колдовская любовь», «Один шанс на двоих», «Девушка на мосту» картиналары дөнья күрә. 2007 елда чираттагы альбомын яздыра. 2012 елда яздырган альбомына аның иң соңгы җырлары кергән.

PRESSA.RU



Лариса МАЛИКОВА

БҮГЕНГЕ ЯШЬЛӘРНЕ БИК ЯРАТАМ, ХӨРМӘТ ИТӘМ. КАЙСЫБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРДӘ АЛАР БЕЗДӘН – ГОМЕР ИТКӘН, ИНДЕ ТОРМЫШ ТӘҖРИБӘСЕ ТУПЛАГАН ӨЛКӘННӘРДӘН ЗИРӘГРӘК ТӘ БУЛА БЕЛӘЛӘР.

ИМТИХАН

Шушы сүзләремне раслап, танышларымнан ишеткән бер очрак турында сөйлисем килә. Ничек булган – барысын да шулай яздым. Исемнәрне генә үзгәрттем.

Никах мәҗлесе, туйлар гөрләп узды. Кунаклар, котлаулар барысы да артта калды.

– Сезнең тормышыгызга кысылмаячакмын… Алдан ук гафу үтенәм, Казанга килгән вакытларда (Фәридәнең иренең әти-әнисе икенче шәһәрдә яшиләр), сездә тукталмаячакмын. Бертуган сеңелләрем шунда бит, аларда кунармын, без шулай ияләшкән инде… – Фәридәнең кайнанасы бу сүзләрне аларны озатырга чыккач әйтте. Яшь килен аның акыллылыгына, зирәклегенә шаккатып тыңлады. «Миңа әйбәт кайнана эләкте бугай!» дип, эчтән генә сөенеп тә куйды әле. Дус кызлары куркытырга өлгергән иде югыйсә…

Кайнанасы сүзендә торды. Нәкъ өч көн торды. Өч көннән соң, телефон шалтырады:

– Фәридуш, хәерле көн! Хәлләрегез ничек? Улыма бүген ниләр пешердең? Беренче ашка, икенчегә? Ә нинди салат әзерләдең?

Менә сиңа кысылмыйм дигән кеше! Түзде Фәридә – сабыр гына сөйләп бирде. Икенче көнне дә шалтыратты ул аңа шул ук сораулар белән, өченче көнне дә… Ә бер атнадан кайнанасы аларга үзе килеп керде. Яңа ел бәйрәмен балалары белән каршыларга уйлаган икән әни кеше… Ә бәйрәмгә чаклы әле әллә



ничә көн бар?! Иң кызыгы – кайнана сеңелләренә китәргә уйламый да.

Кичке ашка яшь килен фольгага төреп ит әзерләргә уйлап куйган иде. Өйгә итнең хуш исе тарала башлауга, кайнана:

– Фәридуш, бу итнең исе сәеррәк түгелме? – дип, киленен гаҗәпкә калдырды.

Кайнанасы, ул пешергән иткә кагылып та карамыйча, кичәге макаронны җылытып ашаганда, бик авыр булса да, түзде Фәридә.

Икенче көнне… барысы да кичәгечә дәвам итте. Кичке аштан калган ит калҗаларын, җылытып ашарбыз әле дип, суыткычка куйган иде Фәридә. Нәрсәдер эзләп, суыткычны ачкан кайнананың күзе шуларга төште:

– Фәридуш, без бит этләргә дигән ризыкны башка савытка җыябыз…

Бу юлы инде, бик теләсә дә, эндәшмичә кала алмады Фәридә:

– Үз өемдә үзем әзерләгән ризыкны ни эшләтәсен беләмдер бит инде мин?!

Кайнанасы әйтерсең аның шушы сүзен генә көтеп торган:

– Менә киленнәр шундый инде алар: башта «әни, әни» дигән булалар, аннары чын йөзләре ачыла…

Бу ямьсез сөйләшү зурга китмәсен дип, Фәридә йокы бүлмәсенә кереп китүне хәерлерәк күрде. Башта үксеп-үксеп елады, аннары тынычланды, күзләренең кызарганы беткәч кенә залга чыкты:

– Оркыя Нуриевна (ул «әни» дип эндәшә башлаган кайнанасына бу очракта, нәкъ шулай итеп мөрәҗәгать итүне дөресрәк булыр дип тапты), сез әле мине белеп бетермисез икән… Мин икейөзле кеше түгел, хәтта ике төрле сөйләшергә дә өйрәнмәгән. Сезгә «әни» дип дәшкәнмен икән, сезгә мөнәсәбәтем, димәк, чыннан да шундый…

Кайнанасы бер сүз дә дәшмичә озак кына аңа карап торды, аннан:

– Мин сине аңладым, – диде һәм… киенеп өйдән чыгып китте.

Фәридәнең эчендә ут иде: аралар шулай бозылды да микәнни, Раббым?! Бәйрәмгә санаулы көннәр калганда бит… Бу нинди Яңа ел була инде хәзер?! «Йа Ходаем, шулай ук каты әйтелдемени соң?» – дип өзгәләнеп йөргәндә, ишек ачкан тавыш ишетелде. Кайнанасы!

Сүзсез генә чишенде дә, сүзсез генә килене янына килде. Һәм… берни әйтми генә аңа кулын сузды. Ә кулында… Кулындагы бәрхет тартмада – төрле төскә кереп җемелдәп, кашлы алка ята… Фәридә имтихан тоткан икән ләбаса! Һәм аны «бишле»гә биргән!

Фото: https://pixabay.com/





АПРЕЛЬ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

МАЙ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	

ИЮНЬ

	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	

ОКТЯБРЬ

1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	
7	14	21	28	

НОЯБРЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	

ДЕКАБРЬ

	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	
2	9	16	23	30	

Татарстанда язылу индексы: П2204
Россия Федерациясендә: 73002
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

Язылһәм телевизор от!

1 **Языл**
31.12.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 **Җибәр**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма): 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2
яки
podpiska@tatmedia.ru

3 **От** Телевизор, фотоаппарат һ. б. бүләкләр!





1–10 декабрь көннәрендә «Почта России»ның барлык почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз.

Акцияне үткәрү вакыты: 25.10.2017 – 20.03.2018
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84. Өстәмә номер – 1261

16+
Реклама